

Рәдиф Сәгъди

# КАНГА БУЯЛГАН АЛТЫННАР

*Роман*
*һәм*
*повестьлар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос = Тат) - 44
С 93

**Сәгъди Рәдиф**

С 93 Канга буялган алтыннар: Роман һәм повестьлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 190 б.

Җыентыкка кергән әсәрләрдә явызлык һәм гаделлек көрәше, чорыбызның коточкыч хәлләре, тетрәндергеч вакыйгалары тасвирлана.

ISBN 5-298-01313-9 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

## УЯУ БУЛ, АДӘМ БАЛАСЫ!

Рәдиф Сәгъдинең әлеге китапка кергән повестьлары, нигездә, 90 нчы еллар башында язылган. Ул еллар — борылыш еллары... Бу җәһәттән шагыйрь Сибгат Хәким сүзләре искә төшә: «Елганың борылган төшендә, бик хәтәр төшендә елганың...» Еллар агышын да елга белән чагыштырсаң, 90 нчы еллар башы да хәтәр чор иде. Болгавыр чор. Сискәндерә торган чор. «Демократия» дип лаф ора-ора, үзебез яшәгән йортны сүтеп ташладык. Ә яңа йортның әлегә нигезе дә күренми. Тәрбия эшендә бушлык. Пионерия юк, комсомол юк. Иске йортны сүтәбез дип, гасырлар буена калыпланган әхлакый кануннарны да чәчеп ташладык. Идеалларны юкка чыгардык.

Бушлык... Бушлык... Иң аянычы: күңелдә бушлык!

Су болганды. Ә болганчык суда балык тотып калырга теләүчеләр җитәрлек. Илдә мал бүлешү китте. Кем көчле, иң зур калҗаны шул эләктерде. Миллионнарча сум акчалар кеше каны белән юылды. Сөйләмебезгә «киллер», «рэкет» дигән яңа сүз-төшенчәләр килеп керде. Җинаятьчеләр тәмам азынды.

Рәдиф Сәгъди җилләрнең кайсы яктан искәнен бик тиз чамалап ала. Үзенең повестьларында нәкъ шул чордагы коточкыч хәлләрне, тетрәндергеч вакыйгаларны сурәтли ул. Рәдиф ул елларда чын мәгънәсендә үҗәтлек күрсәтеп яза. Җәмгыятебездәге тетрәндергеч вакыйгаларны, гыйбрәтле хәлләрне сурәтләп, укучыны да уяу булырга чакырды һәм вакытында кисәтте.

Р.Сәгъди, вакыйгаларны тотып алу белән беррәттән, детектив жанрына тугры калып, мавыктыргыч сюжетка сала. Аның әсәрләре бер сулышта укыла. Укыйсың да: «Бу адәм балаларының җан өшеткеч вәхшилекләр эшләргә ничек куллары бара икән?»— дип уйлап куясың.

Бер караганда, әсәрләрдә сурәтләнгән җинаятьләрнең төп сәбәпчесе — нәфесеңне тыя алмау, байлыкка табыну. Бу җәһәттән «Канга буялган алтыннар» повестеннан лейтенант Симаковның комсызлыгы нәфрәт уята. Автор аның портретын ук гайрәтең чигәрлек итеп сурәтли. «Кече лейтенант Симаков кыска гына буйлы, очланып килгән башы гәүдәсенә караганда зуррак күренә. Кечкенә чепи күзләре арасына урнашкан очлы, озын борыны күзгә ташлана».

Гомере буена үзен кешедән ким-хур санаган, ни гәүдәсе, ни

хәрби дәрәҗәсе үсмәгән шушы этрәк-әләм Әфган сугышында бар дөньядан, кулын канга батырып, үч алырга ниятли. Бер гөнаһсыз әби-бабайларны, хатын-кызларны, бала-чагаларны үтерүне дә бернигә санамый. Нәтиҗәдә, ул зур байлыкны кулга төшерә, хәрби дәрәҗәсе үсә. Ул мур кыргыры (мородер) байлыкны туган илгә ничек алып чыга диген әле... Тутыя табутта! Һәм бу «мәет»не сугышта һәлак булган корбаннар белән бергә алып кайтудан да чирканмый. Башка табутларда ул кан, күз яше, ата-ана өчен мәңгелек хәсрәт алып кайтса, үзенең келәтенә кертеп бикләп куйган табутта — алтын-көмеш. Гәрчә алар да канга буялган...

Каян килә адәм баласына мондый кансызлык, мондый вәхшилек? Автор бу хакта үзе дә уйлана һәм «Каргыш» повестенда җавабын да бирә. Салмак кына башланган бу әсәрдә торабара вакыйгалар шулкадәр куерып китә ки, бер җинаять кысасына кешенең вәхшилеге дә, судьяның сатылуы һәм бер гаепсез кешене нахакка төрмәгә утыртып куюы да, иске «Жигули»-га кызыккан атаның газиз баласы рухына хыянәт итүе, түбәнчелеккә төшүе дә сыйдырылган.

Ә кансызлык, вәхшилекнең каян килүен автор куркыныч җинаятьче Азатның үз авызыннан әйттерә: «Әти, йә, чәрелдәмә әле, зинһар, гарык синең акылсыз фәлсәфәңнән. Үзеңне бел дә телеңне тешлә инде. Акыл сатма, зинһар. Нәкъ үзеңә охшаган инде мин, койган да каплаган.

Син үзеңне бел, карт хайван, әнине кем бетергәнен мин яхшы беләм. Гомереңбуе әни өстеннән йөрдең, 18 яшьлек кызга да бәби ясаганыңны оныттыңмыни, карт шайтан! Без нәрсә күреп үстек соң, без ничек яхшы булырга тиеш соң?! Апа, мескен, синең аркада кияүгә чыкмады. Чөнки ул гаилә төзергә курка. Чөнки ул да синең гаугаларыңны күреп үсте. Син нәрсә теләсәң, шуны эшләдең. Син Казандагы сөяркәңә дә квартира алып бирдең. Хәзер аның кызы буй җиткән. Чат саен синең балалар». Бу сүзләргә ни дә булса өстәп торуның кирәге юктыр.

Повестьның соңгы юлларын укыдым да тәрәзә янына килеп урамга күз салдым. Йөрәгем «жу» итеп китте. Моннан берничә ел элек ике йорт арасындагы буш урынга сыңар куллы Салихҗан бабай агачлар утырткан иде. Ул аларны караптәрбияләп үстерә, җәй буена су ташып сибә. Менә шул гөлбакчаны бер юүньсезе бульдозер белән кырдырып чыккан. Димәк, урыны кирәк. Йә автостоянка ачасылар, йә кибет саласылардыр инде. Мал бүлешү дәвам итә. Бүген агачлар кырыла, иртәгә... Алла сакласын! Колакта Рәдиф Сәгъдинең кисәтүле авазы яңгырый:

— Адәм балалары, уяу булыгыз! Уяу булыгыз. Ник битараф соң сез?!

*Вакыйф Нуриев*

# КЫЙММӘТЛЕ КИЛЕШҮ

*Роман*



## ҮСМЕР ЧАК

Александр эчкече гаиләдә туды, шунда үсте. Ата белән ана бар эшләгәнен аракы һәм закускага тота барганга, балаларны карарга, киендерергә аның бик аз өлеше генә кала иде. Күп вакыт сабыйлар, өлкәннәрдән калган буш шешәләрне тапшырып, шуннан килгән акчага төрле тәм-том алып, үзләренә үзләре бәйрәм ясадылар. Кайчакта, ата-ананың сәрхушлегеннән файдаланып, алар кесәсеннән дә акча урлаштыра иделәр. Чөнки башкача күрше-тирәдәге иптәшләре татыган сыйны алар күрә алмадылар.

Саша кечкенәдән аракы эчәргә, урларга, шәп итеп сүгенергә өйрәнеп үсте. Тирә-юньдә аны бу яктан беркем дә уздыра алмый иде кебек. Аңа 12 яшь тулганда, атасы Владимир Горбатовны сыраханәдә кыйнап үтерделәр. Гомере буе нәниләренә рәхәт күрсәтмәгән әтиләренең үлеме балаларына әллә ни кайгы китермәде дә, чөнки атадан бер файда, бер яхшылык, иманшәфкать күрмәячәкләрен алар яшь булуларына карамастан яхшы аңлаганнар иде инде. Шулай итеп, аналары Мария Васильевна 37 яшендә ике үсмер бала белән тол калды.

Гаилә башын соңгы юлга озатырга бөтен күршеләре, эчкече дуслары җыелды. Монда поселокның күңелең теләгән барлык сәрхушен күрергә була иде. Алар, төрле-төрле төркемнәргә җыелып, мәрхүм белән соңгы мәртәбә кайчан эчкәннәрен, ничек мәрхүмнең соңгы күлмәген сатып баш төзәттергәнен, аның ничек компания җанлы булуын, ничек бергә айныткычта утыруларын һәм башка бик күп шундый хәлләрне искә алдылар. Акыра-бакыра исерек марҗалар елады. Шактый гына төшереп алган тол хатын исә барсын да уздырып: «Ике бала белән кемгә калдырдың син мине?» — дип, карлыккан тавыш белән улый, әле бер исерекне, әле икенче исерекне кочаклап ала иде.

Мәрхүмне күмеп кайткач, кич белән булмаганны бар итеп, тегеннән-моннан бурычка алып, искә алу мәҗлесе үткәрделәр. Монысында күбрәк Володяның иптәшләре генә калды. Мәҗлес төнге икеләргә кадәр дәвам итеп, кайсы кая авып беткәч кенә тукталды. Шушы исерекләр мәҗлесеннән файдаланып, мәрхүмнең шешәдәше Иван Плетнев, аракы эчертеп, Сашаның апасы, унбиш яшьлек Светаны көчләде. Үзе дә шактый гына исерек малай кыз туганына берничек тә ярдәм итә алмады.

Чабып барып Иван Плетневны сөйрәп төшерергә азапланса да, хәле җитмәде. Чөнки айгыр хәтле исерек иргә унике яшьлек малайның көче ничек җитсен. Теге хәшәрәт аяк белән тибеп җибәргәч, Саша идәнгә барып төште. Яңадан торып теге кабахәтнең ботын тешләде. Плетнев, авыртудан акыра-акыра сикереп торып, малайны бар көченә сугып идәнгә аударды. Аңсыз калган малай канга батып идәндә ятканда, исерек ана икенче бүлмәдә ниндидер бүтән бер ир белән йоклый иде. Дөресен генә әйткәндә, тол хатын үзенең ни белән шөгыльләнгәнен дә аңлар дәрәҗәдә түгел иде инде.

Бу тетрәндергеч хәлләрдән соң Александр, бар көченә тырышып, бокс түгәрәгенә йөри башлады. Аның тизрәк үсеп, көчле буласы, апасы өчен Иван Плетневтан үч аласы һәм әнисе белән апасы янына килеп төн кунгалаган, аларны мәсхәрәләгән, санламаган бәндәләрне дөмбәслисе килә иде. Уналты яшендә ул, Татарстан беренчелегендә икенче урын, Казанныкында өченче дәрәҗә дипломнар алып, шактый гына көчле егеткә дә әверелде. Ә көннәрдән бер көнне апасы янына килеп йөри торган Женя атлы оятсыз ир, шактый гына эчеп алгач, апасы белән әнисен төрлечә мыскыл итә, дуңгызлана башлагач, күрше бүлмәдәге малай түзеп-түзеп утырды да, чыдамлыгы беткәч, залга чыгып: «Хәзер үк чыгып кит, югыйсә башыңны ватам!» — дип кычкырды. Теге мөртәт аның бу янавына исе дә китмичә: «Син, уйнаштан туган селәгәй малай, тагын бер авызыңны ачсаң, ботыңнан тотып тәрәзәдән томырам мин сине», — дип акаеп карады. Сашаның, соңгы тапкыр кисәтәм, диюенә теге хайван, торып, өстәлдән буш шешә алды, «Ах, анаңны шулай итим, чебеш!» — дип, малайга каршы юнәлде. Шешә белән малайның башына сугам дип кизәнүе булды, бокс белән шөгыльләнеп, шактый гына осталык алган яшүсмер тегенең шешәле кулына үзенең сул кулы белән блок куеп өлгерде. Шешә, зал тәрәзәсен ватып, тышка очарга өлгермәде, малай Женяны яшен тизлегендә аяктан сугып екты. Әле генә котырган этне хәтерләткән мөртәт, чүп тутырылган капчык кебек, идәндә ята иде. Малай аны ярсый-ярсый типкәләде. Бөтен бите, күлмәкләре канга баткан гәүдәне апасы Света белән соңыннан урамга чыгарып бәрделәр. Икенче көнне, мәгълүм булганча, теге иблиснең ике кабыргасы гына түгел, ияге дә сынган иде. Бу хәл аның әйләнә-тирәдә абруен күтәрде. Шулай итеп, малай исерекләр оясы булып саналган өендә тәртип ясый башлады. Тагын берничә шундый хәлләрдән соң, аларга килеп ни теләсә шуны кылып йөрүчеләр кимеп, адәм рәтлерәкләре генә — кулында бүләге, акчасы булганнары гына кала барды. Малай үзен чын-чынлап кеше итеп тоя башлады. Тик аңа кечкенәдән алган тәрбиясе арттан калмыйча ияреп бара иде.

Егеткә унҗиде яшь тулганда, аның абруе яшьләр арасында

зур булып, күп кенә мәсьәләләрне аның белән киңәшеп хәл итәләр иде. Җәй көннәренең берсендә Саша гомерендә беренче мәртәбә үзенең туган көнен — унҗиде яшен үткәрде. Бу көнне ул, кунаклар сыйлый-сыйлый, үзе дә шактый гына исерде. Мәҗлес бетте. Бар да таралыша, парлысы парлап, ялгызы ялгыз гына китә бардылар. Александрның, туган көне башлануга, Верага күзе төшкән иде, ул аны озата китте. Кыз белән ярты сәгатьләп үбешеп аргач, кайтырга юнәлде. Төнге сәгать бер. Урамда ник бер кеше заты булсын. Кайтып җитәргә дә күп калмады. Ул, Кабан күле яры буйлап РТИ заводы тулай торaклары янына җиткәч, өскә күтәрелде. Менә «Теплоконтроль»-нең ике катлы бараклары. Шунда аңа бер тавыш ишетелде: «Әй, туган, тартырга юкмы синең?» Егеткә бу тавыш нык таныш иде. «Кем соң әле бу?» — дип уйлады ул. Аның күз алдына чәрелдәп кычкырган апасы, күзләре акайган вәхши Иван Плетнев килеп басты. Әйе, бу шул хәшәрәт иде. Сашаның кулы үзеннән-үзе кесәсенә тыгылды. Анда аның яңа гына колониядән кайткан дусты бүләге — Шәрипнең кнопкалы пычагы ята. Егетнең йөрәге дөп-дөп типсә, күзләрен — кан, күңелен нәфрәт баса башлады. Ул теге бәндәгә: «Мә, папирус бар, теләсәң ал!» — дип эндәшкәч, вәхши: «Нәрсә булса да ярый», — дип, аңа якынлашты. Әйе, бу — Иван Плетнев үзе иде. Калган эш яшен тизлегендә эшләнде. Теге килеп җитүгә, Александр, пычагын чыгарып: «Мә, тарт!» — дип, корсагына китереп тә кадады. Пычакның ай яктысында ялтыраган йөзе генә Иванның күз алдында чагылып калды. Ул эчен тотып бөгелүгә, пычак яңадан аның аркасына кадалды. Тагын чыкты, тагын кадалды. Тагын, тагын, тагын...

Канга баткан гәүдә, сузылып ятып, үлем тартышуы белән калтырый башлагач кына, Александр борылып кире Кабан күле ягына йөгерде. Пычакны суга томырып, әллә кайлардан әйләнеп өенә кайтып җиткәндә, таң атып килә, әниләре күптән йоклый иде, тик апасы бүлмәсеннән генә карават шыгырдаган, мышнаган тавышлар ишетелә. «Синең үчне алдым, апа», — дип уйлап куйды ул.

## ҖИТЛЕГҮ

Саша, армиядән туры Казанга кайтмыйча, үз теләге белән Днестр тирәсендә барган сугышларда катнашырга китте. Чөнки өйгә кайтсаң, хәерчелек белән эчкечелектән башка берни көтми. Ә монда исә, завод-фабрикада эшләп алган хезмәт хакына караганда, ун тапкыр күбрәк түлиләр. Гаҗәп ил бу Рәсәй. Җимергән, үтергән өчен акча кызганмыйлар. Эшләгәнгә — юк. Саша бу нәрсәләрне күптән аңлаган иде инде. Өстәвенә монда, ягъни сугыш барган җирдә, череп баерга була икән

дип тә сөйлиләр. Озак көтәргә дә туры килмәде, тормыш аңа бу имеш-мимешләрнең чын икәнен раслады.

Ул хезмәт иткән батальон бер молдаван авылы янына урнашкан. Бу көнне алар көне буе каршы як белән атышсалар, кичкә таба бар да тынып калды. Юра Голиков дигән Ырынбур егете аңа:

— Саша, әйдә, бер туйганчы эчик әле, — дип тәкъдим ясады.

— Ә каян алабыз соң? — дип соравына, Юра, күз кысып:

— Анысын миңа калдыр, бераз караңгы төшсен инде, мин сиңа бер җирне күрсәтәм, үзеңнең дә исең китәр, — дип куйды.

— Яхшы алайса, мин риза. — Александр взводташының кулын кысты. Чыннан да, Юра Голиков аңа караганда күбрәк белә, чөнки ул монда өченче аен хезмәт итә иде.

Кич булды. Тикшерү беткәч, ике егет сакланып кына авыл ягына атладылар. Уен эш түгел. Каршы якта засада булырга мөмкин. Шуңа күрә бик сак барырга кирәк. Авыл якын иде. Ярты сәгатьтән алар йортлар янына килеп җиттеләр. Тирә-як тып-тын. Кайбер йортлар, мина төшеп, янган-җимерелгән. Шундый бер йортка якынлаштылар. Юраның бу җирләрдә элек тә булганы күренеп тора, ул бакча аша алга атлады. Өй ярым җимерек. Чолан аша эчкә үткәч, подвалга төшә торган баскыч күренде. Юра, кесәсеннән фонарь чыгарып, юлны яктыртты. Менә алар аска төшеп тә җиттеләр. Аста агач мичкәләр, зур пыяла банкалар күренде. Базның иң түрендә — өстәл, аның өстендә стаканнар тора. Стенада зур чүмеч эленгән. Юра кулындагы фонарен Сашага сузып: «Син яктыртып тор, мин хәзер банканы тутырып алам», — дип, фонарьны бирде дә, стенадагы теге чүмечкә үрелде. Буйга яткан мичкәдән шәраб тутыргач, аны өстәлгә китереп куйды.

— Әйдә, дустым, утыр, бәйрәм башлана! — Юра урындык күрсәтте. Каяндыр табылган шәмгә ут кабынды. Стаканнар ташыганчы шәраб белән тулды.

Ике стаканнан соң егетләрнең дәрте шактый гына арткач, сүз ияре сүз китеп, бер-берсе белән якыннан таныша башладылар. Юра да Саша кебек эт тормышында үскән икән. Ул әтисенең кем икәнен дә белмәвен, әнисенең сөйрәлгәнен, кечкенә чагы ачлы-туклы, рәнҗетелүләр кичереп үткәнен, әбисе булмаса, бәлкем, исән дә калмавы хакында сөйләде. Тагын берәр стаканны тондырганда, егетләр дуслашып беткәннәр иде инде. Саша яңа дустыннан:

— Карале, Юра, син бит инде монда күптәннән, сиңа кеше үтерергә туры килдеме? — дип сорады.

Юра кулындагы стаканын авызына каплап:

— Шуны онытма, Саша, бу — сугыш. Ә сугышта үтерәләр.

Без монда ни өчен килгәнне беләсеңме соң? Белмәсәң бел! Менә үзең күрәсең, молдаваннар урыс халкына караганда яхшырак яши. Ә аларның тагын да яхшырак яшиселәре килә. Менә үзең күрәсең, бу йортның хуҗасында күпме аракы бар. Күпме яшелчә үстерәләр. Ни өчен соң алар бездән әйбәтрәк яшәргә тиеш? Ә?! Яшәмәсеннәр әле үзләре теләгәнчә! Яшәсеннәр безнең белән! Эчик без аларның аракысын! Әгәр алар аерылып чыксалар, сатып бирәчәкләр безгә аракыларын, аңладыңмы? Ә бу кемгә файдалы, әлбәттә, аларга. Безгә зыян. Менә, брат, ни өчен без биредә. Безнең кебекләр өчен чын тормыш инде бу. Менә, Сашок, үзең уйлап кара әле, — Юра тәмәке кабызды да, тирән итеп суыргач, өреп чыгарды, — әгәр дә без синең белән гражданкада булсак, эшләр идекме, әйт әле?! Юк бит, шулаймы?

Саша, аңа карап:

— Шулай, — дип куйды.

— Шулай булгач, без синең белән урлаша башлар идек, иеме? Урлагач, иртәме-соңмы, утыртачаклар, шулаймы? Шулай шул, туган! Чөнки без эшләп яшәргә өйрәнмәгән! Урлап яшәү безнең геннарда. Ә аларның безнеңчә яшисе килми. Яшәми торсыннар әле «чуркалар». Иң яхшысы, аларны юк итәргә, буйсындырырга! Шулай итсәң, алар әзме-күпме безнең өстәлгә дә аракысын, тәмәкесен, томатын куячак. Менә ни өчен без монда! Безнең тормыш монда, брат! Монда үтерсәң дә, суйсаң да, таласаң да, көчләсәң дә төрмәгә утыртмыйлар!

Юра кесәсеннән бер кечкенә төргәк чыгарды да Кызыл Йолдыз орденын һәм «Батырлык өчен» медален күрсәтте.

— Менә, кара, Саша, бу орденны, аны миңа ни өчен бирделәр соң? Белмисең шул! Тыңла! Молдаваннар авылга кереп урнашып безнең белән атышалар. Алып булмый, югалтулар күп. Шуннан безнең танклар авылны тетеп чыктылар. Исән калганнарын без юкка чыгардык. Шунда мин үзем генә унике кешене олактырдым. Шуның бишесе балалар, дүртесе карткоры, өчесе хатын-кыз иде. Чөнки приказ шундый. Шаһитлар булырга тиеш түгел, диелде. Менә шулай итеп, утызлап дошманны юкка чыгарыр өчен — өч йөз иллеләп мәет. Безгә — орден.

Саша, стаканнарга шәраб тутырып, берсен кулына алды. Юра исә, аны үзенчә аңлап:

— Син хәзер мине күрә алмыйсың инде, шулаймы? — дип сорады. Ул шактый гына кызган иде инде.

— Мин синең бүләкләрең өчен күтәрәм бу стаканны. Алла боерса, миңа да бирерләр әле бер, эшләр уңышлы барса, — дип, Саша стаканын чәкештерергә сузды.

Юра, үз стаканын алып:

— Әле мин бит синең отделение командирың да, мин исән

булсам, синең бөтен нәрсәң булачак, дустым. Бар нәрсәң. Әйдә, шуның өчен! — диде.

Савытлар бушагач, Юра кабат тәмәке кабызып:

— Мин сине инде бер атна күзәтәм, сыныйм, син тәки мин уйлаган егет булып чыктың. Шуңа сиңа үземнең дуслыкны тәкъдим итәм. Әйдә, хәзер инде дуслыкны ныгытыр өчен бер эш эшлибез, телисеңме? — диде.

Саша, аңа бераз карап торгач: «Мин әзер!» — дип, риза булуын белдерде.

Ярты сәгатьтән соң алар авыл уртасындарак урнашкан бер йортның ишеген ватып эчкә уздылар. Өйдәге җан ияләренең, бу ике исерек башкисәрне күреп, өннәре китте. Олы яшьтәге абзый, күрәсең, гаилә башлыгыдыр, эшне аңлап алып, егетләр, зинһар, бөтен әйберне алыгыз, балаларга гына тимәгез, менә, бар байлыгымны бирәм, дип, зур сандыкны ача башлады. Юра аңа автоматын терәде. Карт сандыктан бер тартма чыгарып:

— Менә, егетләр, монда икегезгә дә җитәр, алыгыз, — дип, тартманы сузды. Саша аны ачып, эченә күз салса, савытта алтын-көмеш бизәнү әйберләре, пачка-пачка Рәсәй акчалары һәм башка төрле кәгазьләр иде. Юра түр якка үтә башлады. Абзый аның юлына аркылы төшеп: — Улым, мин бөтен байлыгымны бирдем, зинһар, китегез инде, — дип ялварды. Шунда Юра чаршау артында ике яшь баланы кочаклап утырган матур, кара күзле хатынны күреп алды да:

— Ә бу кемең? — дип, карттан сорады.

Карт, каушап:

— Бу, ни, киленебез инде, — дип куйды.

— Ә малаегыз кая? — дип, Юра аңа автомат көпшәсен терәде.

— Егетләр, ул күрше авылга туганнарыбызга гына киткән иде, озакламый кайтып җитәр инде, Алла боерса.

— Ялганлама, карт хайван, ул безгә каршы сугышадыр, — дип, Юра аңа автомат түтәсе белән китереп сукты, карт, авызындагы тешләре коелып, идәнгә егылды. Түр яктан чыккан карчыгы үз телләрендә нидер сөйли-сөйли елап, карты өстенә капланды. Чаршау артындагы хатынга ияреп балалар кычкырып елап җибәрделәр. Юра, күп уйлап тормастан, карчыкның да башына томырды. Идәндә канга батып яткан гәүдәләр аша эчкә үтеп, аннан дер калтыранган хатынны сөйрәп чыгарды. Сашага хатынны тотып торырга кушып, балалар янына кереп китте. Хатын, аның артыннан барырга теләсә дә, китә алмады, чөнки аны Саша чәченнән урап тоткан иде. Эчке яктан балалар чәрелдәп кычкырган тавышлар ишетелде. Бераздан канга баткан пычак тоткан Юра күренде. Хатын, эш нидә икәнен аңлагач, сыгылып төшеп аңын югалтты. Юра, автоматын иптәшенә тоттырып, хатынның чәчәкле күлмәген буйга ертып ыр-

гытты. Анадан тума шәрә калган аңсыз хатынны мич янынарак сөйрәп илтеп салгач, бүлек командиры эшкә кереште. Хатынның сылу гәүдәсен күреп сокланган Александрда түзеп булмаслык җенси теләк уянды. Хатын ыңгырашып аңына килә башлаган иде, Голиков бар көченә башына китереп суккач, мескен хатын кабат тынып калды. Бераздан чират Казан егетенә дә җитте...

Менә кыргыйлар йоласы бетте. Саша чалбарын күтәреп, төймәләрен эләктереп бетергәч, Юра, аңа канлы пычагын сузып, башы белән хатынга ымлады. Саша, пычакны алып, корбаны өстенә иелде. Тирә-якка кан чәчрәде.

Тагын ярты сәгатьтән «бөек дәүләт сугышчылары» беренче тукталган йортның базында иделәр. Уңышлы үткән операция өчен икешәр стаканны җибәргәч, егерме литрлы канистрга шәраб тутырып, кайтыр юлга кузгалдылар. Ә авыл уртасында мәетләр белән тулган йорт дөрләп янып калды.

## КАЙТУ

Демократик дәүләтләр басымы, молдаваннарның көчле каршылык күрсәтүе Рәсәй гаскәрләренең имансыз сугышын туктатырга мәҗбүр итте. Хәрбиләрнең бер өлеше Днестр буендагы марионет — ясалма дәүләтне сакларга калса, күпчелеген Рәсәйгә кайтардылар.

Сашага бу сугышта «эшләп» алган сиксән мең сум акча Казанга кайтып җитәргә генә җитте. Башта алар Ырынбур егете белән биш көн Мәскәүдә типтерделәр, аннан — өч көн Ырынбурда. Шулай итеп, ярты ел буе җыелган капитал «капут» булды да куйды. Поезд Казан вокзалына туктаганда, аның кесәсендә нибары унбиш-уналты мең акчасы гына калган иде. Тик егетнең бу хәлгә бер дә исе китмәде. Чөнки аның ике кулында мал-мөлкәт, төрле бизәнү әйберләре белән шыплап тутырылган ике зур чемодан бар.

Өйдә аның әнисе берьялгызы калган, апасы Света, кияүгә чыгып, ире фатирына күчкән иде. Мария ханым улын кочаклап алды, исән-сау кайттыңмы, дип, аркасыннан сөйде. Саша әнисенең суырылып калган йөзенә, хәерче киемнәренә карап, кызганып куйды. Өй элеккедән дә шыксыз. Кухняда каткан ипи, суыткычта тозлы кәбестә белән дуңгыз маеннан битәр ризык табылмады. Ана кеше авыр сулап куйды.

— Хәзер, улым, берәрсенә кереп акча сорап карыйм, — дип сүз кузгаткан иде, улы: «Әни, зинһар, теләнеп йөрмә, онытыгыз ул гадәтегезне. Бүгеннән башлап бу йортта туклык булырга тиеш, аңладыңмы?» — дип, анасына карады. Тик Мария ханым юүньләп берни аңлый алмый иде әле. Аның башы «бурычка кем бирер икән» дигән уйлар белән тулган, чөнки соңгы елларда аңа акча биреп торучылар беткән иде.

— Әни, дим, менә сиңа унбиш мең акча, яхшырак колбаса, сыр, аракы ал, үзең кара инде шунда, өстәлгә куярлык әйберләр алып кайт! Аннан өстеңне алмаштыр, йөрмә болай урам хәерчесе кебек. Әнә теге чемоданны ачып, үзеңә ошаган күлмәк-чүпрәкләрне сайла! — дип, Саша анасына кулындагы акчаларын тапшырды. Шулхәтле акчаны ел буена да эшли алмаган ананың шатлыгы эченә сыймады. Искерәк машина алырга җитәрлек иде бу акча!

Унбиш минут та үтмәгәндер, кыйммәтле киемнәр киеп, танымаслык булып үзгәргән ана кухняга керде. Саша, аны бу кыяфәттә күреп, шаккатып калды. Каршында бөтенләй бүтән хатын басып тора иде.

— Ну, әнкәй, менә дигән чибәр хатынга әйләндең дә куйдың. Күршеләрең дә танымас инде үзеңне.

Мария Васильевна көлеп җибәрде. Аның шатлыгы эченә сыймый иде.

Ана кеше эшләр белән чыгып киткәч, егет ванна кереп, кырынып алды, өстен алмаштырды. Өр-яңа костюм-чалбар, кыйммәтле ботинка да кигәч, үзен көзгедән күреп сокланды. «Менә, Саша, синең дә адәмчә яшәр чакларың җитте, Ходай Тәгалә сиңа кечкенә чагында бирмәгәнне хәзер бирә башлады», — дип уйлады ул. Икенче чемоданнан алтыннан ясалган галстук кыстыргыч алып эләктерде, ике бармагына бриллиант ташлы йөзек белән зур алтын балдак киде. Озак та үтми кайтып кергән апасы белән анасы, аның бу кыяфәтенә һушлары китеп карап тордылар. Светаның күз төбе күгәргән иде. Ул, энекәшем минем, дип, егетне кочаклап елый башлады. Александр исә, булды, апа, булды, җитте, дип, кочактан котылырга теләсә дә, апасы аны чалт-чолт үбүендә булды.

— Апа, дим, үбеп бөтен җирне кызартып бетерәсең ич, җитәр инде, ә!

Апа кеше, тагын бер-ике тапкыр суырып үпкәч, «Кайгырма, кызларыңа да калырсың әле, ярамаган икән, бертуган апасы үпкән», — дип шаяртып алды. Егет кабат апасының күгәргән битенә, киеменә күз салды:

— Апа, әнә әни бүлмәсендә сезгә бүләкләр, күңелеңә ошаганнарын сайлап ал әле син. Аннан бу күз төбең нишләп бозылды, кем эше соң ул?! — дип сорады.

Апа кеше, әллә ни булмагандай гына:

— Әй, җизнәң бераз җүләрләнеп алды. Кайсы вакытта бер кирәкмәгәнгә дә көнләшә инде, — дип куйды.

— Үзе кая соң әле ул? — дип сорады Саша.

— Иртән иртүк эшкә урнашам дип чыгып киткән иде, кая йөридер селкенеп, әле яңа заводта эшеннән кудылар, мастерлары белән сугышкан өчен, — дип, авыр сулап куйды апа кеше.

— Нәрсә, көче эченә сыймыймы әллә йә бик тазамы? — дип, Александр апасының күзләренә карады.

— Башкаларга ничектер, миңа җитә инде көче, ярар, баш катырма әле шул эчкече белән, өйдә дә туйган мин аннан! Без аңа язу калдырдык, кайтса, килеп җитәр, менә күрерсең. Сашок, зинһар, үзенә әйтә күрмә тагын миңа сукканын, яхшы түгел. Болай начар кеше дә түгел инде ул, энем. — диде Света көлеп.

— Ярар, — дип мырлап кына куйды Саша. Света белән әниләре икенче бүлмәгә кереп киттеләр. Тагын ярты сәгатьтән алар залда, мул өстәл артында сыйланып утыралар иде. Бу фатир мондый бай табынны үз тарихында да күрмәгәндер. Өстәлдә бар да бар. Икра, кыздырылган тавык, гөмбә, җиләк-җимеш һәм башка күп кенә нигъмәтләр җитәрлек иде.

Ишек кыңгыравы чылтырады. Шактый гына кызып алган Света, бу җизнәң, энем, шулай каты итеп ул гына чылтырата, зинһар, бәйләнә күрмә инде аңа, яме, дип аңа ялварды.

— Күз күрер әле. — Саша, торып, ишек ачарга чыгып китте. Бераздан тегендә ирләр тавышы ишетелгәч, Света үз иренең тавышын танып, килеп җитте теге тинтәк тә, дип куйды. Бүлмәгә башта Александр Владимирович, аның артыннан ябык кына гәүдәле, ике колагы тырпаеп торган, кыяфәте беркатлыга охшаган адәм заты күренде. Өстәл артында утырган хатын-кызларны күргәч, «дөрес кердемме икән соң?» дигәндәй, аптырап, чем-чем итеп күзләрен йомгалады. Ул өстәл артында утырган хәләл җефете белән әбисен таный алмады. Бу хәлне аңлап алган хатын-кызлар чәрелдәшеп көлә башладылар. Света шаркылдап көлә-көлә, кара-кара, теге имгәкне, хатынын танымый, бөтенләй акылдан язган бу, дип, бармак белән төртеп күрсәтте. Соңыннан, ахры, теге адәм дә, хатынын күз төбендәге тамгасыннан танып: «Менә сиңа мә, бу бит Света! Сезне танырлык түгел хәзер. Әллә мин әйтәм, президент хатыннары утырамы дип уйлаган идем. Ә алар әби белән минем хатын булып чыкмасыннармы!» — дип көлә башлады. Шуннан егеткә борылып: «Ну, молодец, каениш, чын туган икәнсең. Шулкадәр бүләк алып кайтмасаң. Менә мин үзем генә синең кайтышны юарга буш кул белән килдем, гафу итәрсең. Эштән киткән идем мин, акча җүнләп түләмиләр. Апаңның язуын укыгач, әллә ничә кешегә кереп акча сорап карадым, бирмиләр хәзер. Ярар, анысы минем өстә кала инде, зинһар, үпкәләмә!» — диде.

Сашага җизнәсе бик үк ошап бетмәде. Клоунга тартым беркатлы адәм, өстәвенә дөньяда үзе генә кебек, икенче төрле әйтсәк, бик күп моторлар эшләп торган цехта сөйләшкән кебек акырып сөйләшә. Саша аңа: «Утыр әйдә, утыр, әнә хатының янына утырсаң да ярый», — дип, урын күрсәтте. Мәҗлес дәвам итте. Җизни кеше эчкән саен кирәксә-кирәкмәсә дә шырык-шырык көлде. Бүтәннәр сүз башласа, килеп кысылып, үзенекен тәкелдәде. Каениш исә, аңа карап: «Әллә бераз тинтәгрәк тә

инде бу», — дип уйлады. Соңрак, шактый гына кызган ирләр балконга тәмәке тартырга чыккач, Саша җизнәсен якасыннан сөйрәп үзенә якын китереп:

— Син, туган кеше, әгәр дә апага тагын бер кул күтәрәсең икән, мин сине менә шушы балконга күкәеңнән асып куям, аңладыңмы? — дип, балконнан аска башы белән бөкте. Җизни кешенең өне китте, ул:

— Соң, мин салган баштан инде, каениш. Аңла инде син, яратам бит мин аны, шуңа көнләшәм дә. Соң, үзе бит күрше мужигы Алексей белән үбешеп утыра иде. Кызып кителде шул, — дип акланды.

— Аның беркайчан да рәхәт күргәне булмады. Шуны аңла, тагын бер кул күтәрсәң, үзеңә үпкәлә. Ә хәзер, әйдә, табын артына. Минем сиңа да бүләгем бар.

Каениш биргән костюм-чалбарны кигәч, япон сәгатен дә кулына таккач, җизни кеше, хатыны Светага карап, елап җибәрде, үзе: «Чын туган икән синең энең, карчык, рәхмәт сиңа, каениш, рәхмәт! Әби, сиңа да зур рәхмәт, шундый кыз белән малай үстергәнегез өчен», — дип мыгырданды.

## ТОРМЫШКА АЯК БАСУ

Саша алып кайткан байлык Мария Васильевна гаиләсенә өч айга да җитмәде. Сатыласы сатылып, эчеләсе эчеп бетерелде. Егет кеше берничә җиргә эшкә урнашып караса да, эшенең рәте булмады. Алган хезмәт хакы аңа ике-өч көнгә генә җитә иде. Шулай каңгырап йөргән көннәрнең берсендә, аның элеккеге дусты Шәрип төрмәдән кайтып төшмәсенме. Аның чыгуын төне буе юганнан соң, Шәрип озата чыкты. Киләчәктә ничек яшәргә, ничек көн күрергә дигән темага бик озак сөйләштеләр. Һәрберсе үз планын уйлап килергә һәм иртәгә кич «Казан» ресторанында очрашырга килешеп аерылыштылар.

Икенче көнне ресторанда күрешеп киңәшкәч, кибет басып эләккән Шәрип планы — фатирлар чистарту планы уңышлы дип табылды. Бу план Сашага да ошады. Иң мөһиме, бай фатирларны таба белергә, күбрәк кеше гайбәтләрен тыңларга, алар аша кайда нәрсә ятканын ачыкларга гына кала. Айга бер-ике операция эшләгәч, югалып торырга, соңыннан бөтенләй икенче җирдә эш итәргә булдылар. Чөнки болай эшләү тиешле органнарның башын бутау өчен кирәк иде.

Шәрип кечкенәдән төрле йозак-бикләвечләр ачарга хирыс иде. Ул, тәҗрибә туплый-туплый, бу эшнең остасына әйләнде. Димәк, фатирларга үтеп керер өчен артык кеше дә кирәкмәячәк. Иң авыры: таланган малны ничек акчага әйләндерү. Шунда Саша апасы белән җизнәсенең эшсез ятуын, кирәк булса алар аша саттырып булачагын әйтте. Шәрип башта бу фикер-

гә каршы килсә дә, соңыннан: «Ничек сатарга, сак булырга өйрәтергә кирәк булачак, Казанда алынган малны бөтенләй башка шәһәргә җибәрергә кирәк», — дип разый булды. Эш тизрәк барсын өчен, бәяләрен бераз төшерергә кирәк икәне дә килешенде. Светага сатылганнан кергән керемнең ун процентын түләргә булдылар.

Шулай итеп, егетләр уйланган планнарын тормышка ашыра башладылар. Җирле матбугат, үзәк матбугат тегендә-монда фатирлар басылуын, тикшерү органнарының бу җинаятьчеләргә каршы эш алып баруларын, инде хәтта каракларның эзләренә төшүләре, бүгенме-иртәгәме кулга алыначакларын язсалар да, егетләр үз эшләрен оста башкардылар. Бу хәбәрләрне һәрвакыт күзәтеп барган Шәрип Сашага: «Кара әле, инде ничә ел безне эләктерә яздык дип мактанышалар, билләһи, милициядән дә ялганчырак идарәне белмим мин!» — дип сөйләп көлә иде.

Чыннан да, бу ике егетнең эше әйбәт барды. Инде күпме фатирларны чистартсалар да, алар үзләренә бәйләнерлек эз калдырмадылар. Хәзер Шәрип тугызынчы маркалы «Жигули»-да йөрсә, Сашага өр-яңа УАЗ алдылар. Бу машина аларга алынган әйберләрне төрле урыннарга илткәндә, начар юллардан үткәндә ышанычлы иде. Апасы Света да күзгә карап үзгәрде. Яңа мебель, алтын-көмеш, бәллүр савыт-саба белән өе тулды. Тик җизни кеше генә әллә ни майтара алмады. Аны берничә мәртәбә эштә сынап караганнар иде дә, бер-ике мәртәбә эчеп, акчаларын югалткач, ике колагын тырпайтып, өйдә генә утыра башлады. Хәзер ул, хатыны чит шәһәрләргә китеп сату иткәндә, өй каравылчысы да. Шуннан артыгы ул иләс-миләскә кирәкми дә иде. Ашарга — ике суыткыч тулы, эчәргә җитәрлек, яшә дә яшә! Сораган кешеләргә җизни кеше: «Эшләп кем баеган, җүләрләр эшләсен», — дип кенә җибәрә иде. Өйдәге муллыктан файдаланып, хатынның ясалып җитмәгән тормыш иптәше көннән-көн аза, акылсызлана барды. Хатынының эшкә киткәнен генә көтеп тора да, үзе кебекләрне җыеп, өйнең астыөскә килгәнче типтерәләр. Ә беркөнне аның шушы тинтәклегеннән файдаланып, ниндидер очраклы кешеләр аларның үзләрен дә чистартып чыктылар.

Эш исә болай булды. Бервакыт ул, кибеткә аракыга кергәч, ниндидер чит кешеләр белән танышып китеп, мактанырга өенә алып кайтты. Тегеләр, аның саен моның иләс-миләс икәнен сизеп алып, мактадылар, үсендерделәр, соңрак аракысына йоклаткыч дару салып, фатирны чистартып чыктылар. Теге тинтәк уянып киткәндә, шыр фатирда ята иде.

Хуҗа хатын кайтып буш фатирын күргәч, үзен куркыныч астына куеп, кышкы салкында, көзге пычракларда тырышыптырмашып җыйган малының күккә очканын аңлады. Ул тиз генә энесенә хәбәр итте. Саша озак көттерми килеп тә җитте.

Аның чыгырыннан чыкканлыгы йөзеннән күренеп тора иде. Кереп җитәр-җитмәс, ул: «Кая соң әле ул сарыгың, асып куярга кирәк аны!» — дип залга ук узды. Җизнәсенең өйдә юклыгын аңлагач, кухняга кереп су алып эчте. Аның артыннан ияреп йөргән апасы: «Бәлкем, куалап кына чыгарыргадыр, Саша?» — дип әйтеп бетермәде, ишектә кыңгырау чылтырады. Саша, апасына карап: «Минем мондалыкны әйтмә, ни сөйләр икән, мин качып торам», — дип, йокы бүлмәсенә кереп китте. Һәрвакыттагыча салмыш, ике колагы тагы да тырпайган җизни кеше күренде. Кергән мәлдә үк ул хатынына: «Кайгырма, карчык, мин аларны җир астыннан булса да табам, менә күрерсең, син әле мине тулысынча белмисең генә. Мин аларның яшәрлекләрен калдырмыйм, менә күрерсең, ант итәм», — диде.

Света ханым, бер сүз дәшмичә, сигарет чыгарып кабызды да, соңыннан залда торган чемоданны алып чыгып:

— Ә хәзер ычкын моннан, эзең булмасын, — дип кычкырды.

Ире башта аптырап калды, соңыннан:

— Соң, мин аларны барыбер табам, кайтарам әйберләрне, — дип ялынды.

Хатын, шашынып:

— Хәзер үк әйберләреңне ал да ычкын моннан, дуңгыз, ясалып җитмәгән нәрсә, — дип акырды.

— Яхшы, мине үз фатирымнан куасызмы, яхшы, ләкин үзеңә үпкәлә! Сезнең апалы-энеле нинди бизнес белән шөгыльләнгәнегезне тиешле җиргә җиткерәм, — дип, ире ишеккә юнәлде. Шунда йокы бүлмәсеннән көчкә үзен тыеп торган Александр атылып чыгып, җизнәсенең юлына аркылы төште.

— Кемне барып сатасың инде син, козел вонючий, безнеме?! Ашап-эчеп, без эшләгәнгә типтереп яттың.

Җизни кеше агарып чыкты.

Каенише аны тыңлап тора дип башына да китермәгән иде ул.

— Энекәш, мин бит ни, уйнап кына, хатынны куркытыр өчен генә әйттем. Теге малны кайтарам мин, курыкмагыз, барысы да әйбәт була, Алла боерса, — дип сөйләнде. Каенише аңа акланып бетерергә бирмәде, иягенә китереп сукты, җизни кеше аңын югалтып, идәнгә егылды. Аннары катып калган апасына:

— Бар, тиз бул, берәр бау табып китер, — дип ырылдады.

Эшнең ни белән бетәчәген аңлый башлаган Света, энесенә ялварулы карап:

— Бәлкем, кирәкмәс, ә, Саша?! — дип үтенде.

— Нәрсә, безнең белән бер камерада утырасың киләме әллә?! Бүген сатмаса, иртәгә сөйләячәк бит ул берәрсенә. Сиңа да әйтер идем инде, апа, тапкансың ир! Бар, тиз бул, торма аптырап.

Света каяндыр капрон бау тартып чыгарды да энесенә суз-ды. Саша идәндә яткан җизнәсенең муенына бауны әйләндереп алгач, аның ике очын кулына чорнап, ике якка тарта башлады. Теге мескен бер-ике мәртәбә бәргәләнеп алды да җан бирде. Хәзер мәетне юкка чыгарырга кирәк иде...

Света каушаудан бертуктаусыз тәмәке тартты. Әле аның моңа кадәр кеше үтерүдә катнашканы юк иде. Саша апасының бу халәтен күреп: «Җебеп торма әле! Бар, тиз бул, балта белән целлофан пленкалар китер. Кисәкләргә бүлеп машинага ташырга кирәк. Гәүдәсе белән алып чыксак, кеше күреп калуы бар», — диде.

Света бөтен гәүдәсе белән дер калтырап, балконга балта эзләргә чыгып китте.

Гәүдәне кисәкләргә бүлгәләгәч, целлофан пленкаларга төреп, әрҗәләргә салдылар. Эш беткәч, егет апасына: «Тиз бул, идән белән стеналардагы кан эзләрен яхшылап юып ал», — дип кычкырды. Света исә бу вакытта туалетта укшып маташа иде.

Ике сәгать ярым дигәндә, төрәсе төрелеп, бәйлисе бәйләнеп, төргәкләрне машинага ташый башладылар. Бар да әзер булгач, машина «Теплоконтроль» ягына кузгалды. Мәетне, ташлар бәйләп, Кабан күленә ташладылар. Апасын әниләрендә төшереп калдыргач, Саша хезмәттәше Шәрип янына китте. Эшнең ничек булганын тыңлап бетергән дусты: «Дөрес эшләгәнсез, югыйсә ул алкаш безне барыбер сата иде», — дип куйды.

Хәзер алар өчәү генә калдылар. Эш алып бару да көннән-көн авырая. Чөнки эшләмичә ашарга теләүчеләр көтелгәннән дә күбрәк булып чыкты. Шул сәбәпле кайбер ачы телле журналистлар Сталинны да яхшы яктан искә алдылар. Имеш, Рәсәй халкын чыбыркы белән ул гына эшләтә алган.

Эш, чыннан да, кыенга китте. Кешеләр үзләренең мал-мөлкәтен саклап калыр өчен фатирларына тимер ишекләр, төрле сигналлар куйдырдылар, усал этләр асрый башладылар. Биктәр мастеры Шәрип үз гомерендә беренче мәртәбә ишек биген ача алмады. Икенче юлы фатирны ачып керсәләр, бозау хәтле ике дог каршы алды. Кире чыгып качудан башка юл калмады. Уңга-сулга акча туздырырга өйрәнгән егетләрнең соңгы вакытта хәлләре шәптән түгел иде. Каян күп итеп урларга, нәрсә эшләргә дигән уйлар белән йөргән көннәрнең берсендә, Шәрип Сашаның өенә килде. Аның ниндидер яңа эш тәкъдим итәсе сизелеп тора иде. Ул керә-керешкә: «Өйдә читләр юкмы, икәү генә сөйләшәсе сүз бар», — дип, бүлмәгә узды. Хуҗа егет аңа: «Борчылма, әни күршеләргә кереп китте, тиз генә чыкмас әле», — дип җавап бирде.

Саша залдагы журнал өстәленә табын әзерләде. Икесе дә өстәл артына утыргач, Александр кунагына: «Йә, ни булды, сөй-

лә», — дип, эшне ашыктырды. Шәрип, ашыкмый гына ярты стакан аракыны авызына ташлагач:

— Шәп акчалы эш бар, син күз алдыңа да китерә алмыйсың күпме икәнен, — диде.

— Күпме инде ул синең өчен күп акчалы эш?

— Яле, үзең чамалап кара, дөреслеккә якын килерсең микән. Югыйсә миндә сиземләү көчле, дип мактанасың.

— Ну, күпме булырга мөмкин инде, синең өчен зур акча. Иң зур акча синең өчен ун-унбиш миллион инде, дустым. Бу акча өчен син чукынырга да мөмкинсең.

— Якын да килмәдең, кадерлем! — дип, Шәрип авызын ерып куйды. Торып, тәрәзә каршына килеп баскач:

— Синең мылтыктан ату ягың ничек? — дип сорады.

— Нәрсә, берәрсен атарга кирәкме әллә? Батальонда иң яхшы атучылар арасына керә идем. Йә, шуннан, кемне манчырга кирәк инде?

Шәрип тиз генә чишелергә теләмәде, ахры. Өстәл артына килеп утырды, стаканнарның яртысына кадәр аракы тутыргач, берсен Сашага, икенчесен үз кулына алды.

— Бик җитди, бик зур эш бар. Бик зур, бик абруйлы кешеләргә бер эш эшләргә кирәк. Хәзер үк әйтеп куям, эш зур табышлы булачак. Без аласы кеше дә бик зур, бик абруйлы. Ләкин эшнең бәясе, хәвеф-хәтәрле булса да, эшләтә торган бәя! Андый бәяне йөз квартир бассаң да алып булмый. Бер эш һәм син гомер буена тәэмин ителгән дигән сүз.

— Күпме була соң инде ул сумма?

— Күп! Йә, ризамы инде?!

Шәрип уйга калган дустына карады, тик тегесе җавап бирергә ашыкмады. Бераздан борылып:

— Шулай да күпме тора теге кеше? — дип кабатлап сорады.

— Биш йөз миллион җитәме?

— Биш йөз миллион?! Тукта, син бутамыйсыңмы, бер кеше гомере өчен биш йөз миллион. Мин аларны сугышта дистәләп үтердем, сукыр бер тиен бирүче булмады. Монда берәр мәкер ятмасын. Ул биш йөз миллион өчен мин үзем йөз кешене суяр идем. Нишләп үзләре эшләми соң аны? Кеше үтерү хәзер чебен үтергән кебек кенә.

— Беренчедән, бу эшне минем белән утырып чыккан малай тәкъдим итте. Икенчедән, акчаны кулга төшерү ягын төптән уйлау безгә кала. Башта — акча, аннан — эш. Шуңа күрә уйларга кирәк!

— Анысын да бик яхшы аңлыйм, тик шуны әйт: нишләп әле алар бу эшне безгә тәкъдим итәләр, профессионал үтерүчеләр беткәнмени? Сәер эш бу.

— Бөтен эш шунда да шул. Бу нәрсәне элек күзгә ташлан-

маган, шик астына алынмаганнар эшләргә тиеш, — дип, Шәрип урыннан торды. — Йә, нишлибез, мондый мөмкинлек кеше гомерендә бер генә була. Биш йөз миллион! Төшкә дә кермәгән акча.

Саша урынынннан кузгалды. «Биш йөз миллион. Бер кеше өчен. Кем икән ул?! Шулай да сәер, шикле эш бу.» Шәрип, аның уйларын аңлагандай: «Әйдә, башта үзләрен күреп сөйләшик, ничек, нәрсә, кайчан эшләргә һәм акчасын ничек аласын. Аннан үзең карарсың инде. Тик бу эшне тәкъдим иткән кеше — минем бик яхшы танышым. Ике мәртәбә бергә утырдык. Ышанычлы малай», — диде.

Александр уйга калды. «Биш йөз миллион сум акча. Ярый, ике йөз илле миллионы Шәрипкә китсен ди. Калганына — Идел ярыннан коттедж, чит ил машинасы. Артып калганын долларга әйләндереп, процентка салсаң, бер ун ел рәхәтләнеп яшәргә була. Бәлкем, чит илгә сызаргадыр. Хәзер бер доллар биш сум тора, димәк, долларга әйләндерсәк, бер миллион була. Бу бит коточкыч зур акча! Миңа биш йөз мең доллары калса да рәхәтләнеп яшәргә була.

Аннан өйләнеп җибәрер, балалар туар. Алла сакласын аларга да минем тормышта яшәргә! Аталары ничек үскәнне, яшәгәнне алар төшләрендә дә күрергә тиеш түгелләр». Аның күз алдыннан кечкенә чаклары, атасының иман такталары белән сүгенүе, көн саен үткән исерекләр бәйрәме, апасы белән йокы бүлмәсенә кереп, почмакка посып дерелдәп утырулары... Тәненә каз тиреләре бәреп чыкты. «Ничек тә булса чокырдан чыгарга кирәк. Чы-гар-га!» — дип уйлады ул.

Шәрип, дустына карап:

— Акчаны кулга алгач кына эш итәргә туры киләчәк. Барысын да яхшылап уйларга туры килер. Эш төгәлләнгәч, бер-ике елга республикадан юкка чыгарбыз. Шунсыз ярамый. Ул арада Рәсәйдә дөнья егерме тапкыр үзгәрер әле! Бар да шулай эшли, — диде.

Саша, шешәдәге калган аракыны стаканнарга салгач:

— Әйдә, яхшылап уйлыйк та, соңыннан заказчыларны тыңлап карарбыз, — диде. — Барысын да яңабаштан уйларга, үлчәргә, кисәргә кирәк!

## КАПИТАН ФАЯЗ МӨКМИНОВ ПЛАНЫ

Капитан Фаяз Мөкминов махмыр сусавыннан уянып китте. Кичә дежурствоны икенче кешегә тапшыргач, тагын ике милиционер белән эчләре сыекланганчы эчкәннәр иде. Ул барып кранны ачты, бераздан суга бармагын тыгып, суыклыгын тикшерде. Шуннан артык суынмаячагын чамалагач, бер литрлы банкага су тутырып, аңа бераз карлыган вареньесы бутап

эчте. Бөтен тәненә салкын тир бәреп чыкты. «Ух, чукынган, тагын дуңгыз урынына эчелгән», — дип уйлап куйды. Ул кичә үзләренең кайларда булганнарын искә төшереп караса да, файдасы булмады.

Фаяз Мөкминов милиционер булып егерме елга якын эшли. Гаиләсе белән биш ел элек аерылышты. Бер баласы бар, хатыны белән аралары үзе аркасында, эчеп өйгә кайтмыйча башка хатыннар белән, элеккеге хәләл җефете әйтмешли, «себерелеп» йөрүе аркасында өзелде. Эчеп эшкә бармый кала торган гадәтләре дә булганга, капитаннан ары күтәрелә дә алмады. Шулай да, аңа кисәтүләр ясасалар да, эштән кумадылар. Чөнки аның уңай яклары да күп иде. Кайсы өлкәнрәк офицер эшкә чакырмасын, ул кире какмады. Дачасын да, гаражын да салышты, кирәк икән бәрәңгесен дә алышты. Шуңа күрә аны бар начальнигы да белә, күп нәрсәсен кичерәләр иде.

Бер бүлмәле «хрущевка» аңа өч бүлмәлесен бүлешкәннән калды. Өйдә рәтле мебель дә, җиһаз да юк. Иске бер софа да, Сталин заманында эшләнгән имән өстәл һәм дүрт урындык. Сул як стенада — сервант.

Кухняда да тәртипсезлек күзгә бәрелеп тора. Юылмаган савыт-саба, буш шешәләр, ризык кисәкләре, тәмәке төпчекләре чәчелгән. Тагын иске «Свияга» суыткычы, бер озын ак шкаф, кечкенә генә өстәл дә ике урындык. Бу йортка күптән хатынкыз кулы тимәгәне күренеп тора. Чөнки соңгы вакытта Фаяз өйгә хатын-кызлар алып кайтмый, ә үзе аларга барып куну ягын карый. Шулай файдалырак иде аңа, чөнки ашаталар, эчертәләр, йоклаталар.

Фаяз, кичә эчкәннән берәр нәрсә калмады микән дип, өстәлдәге шешәләрне тикшереп чыкты. Аларда тамчы да хәмер калмаган. «Нишләргә икән?» — дип уйлап куйды ул. Аның шундый кыен чакларда йөгертә торган кешесе каршы йортта гына яши иде. Алар өйдә микән соң, дип тәрәзәгә күз салса, төнге 12 ләр булса да, утлары бар иде. Ул кесәләреннән акча җыйды. «Мишаны киоскка җибәрергә кирәк. Бер яртыга әз генә җитми, ярар, үзеннән өстәр әле», — дип куйды.

Ул кабат тәрәзәдән каршы йортка күз салды. Аста Мишалар подъезды төбендә Сашаның «девятка»сы тора. Озак та үтмәде, Света белән энесе, ашыга-ашыга, багажникка ниндидер төргәкләр ташый башладылар. «Ну, урлап та карыйлар инде болар. Нишләп Миша үзе күренми әле, каенише белән хатынына булышмый?! Бәлкем, өйдә төргәкләр биреп торадыр», — дип уйлап куйды Фаяз.

Ул яңадан тәрәзәдән күз салганда, теге машина юк иде инде. Шулай да тәрәзәдә ут бар. Фаяз софада яткан кителен алып киде дә чыгып китте.

Мишалар фатирының кыңгырау төймәсенә берничә мәртә-

бә басып караса да, ишек ачучы булмады. Капитанның күзе ишек төбенә төште: анда бер-ике кызыл тамчы күренә иде. Ул иелеп бармагы белән берсен сөртеп алып яхшылап караса — кан тамчысы! Ул, баскычтан түбән төшеп, урамга чыкты. Бая машина торган урынны ныклап тикшерде, анда да кан тамчыларына тап булды. «Аңлашылды, димәк, монда нидер булган», — дип уйлады ул. Асфальттагы кан тамчыларын кулъяулыгына сеңдерде.

Икенче көнне лабораториядә тикшертеп алгач, аның кеше каны икәне ачыкланды. Берничә көннән исә ул Мишаның бөтенләй якты дөньяда юклыгына төшенде. Тик моны ачыклыйсы гына калган иде. «Нәрсә эшләргә? Җинаять эше ачтырыргамы?! Ярый, шуннан теге ике мөртәтне утыртырлар. Алар, акчалары булса, төрмәдән котылырлар, хәзер кесәң калын булса — төрле хәлдән чыгарга була. Аларны утыртудан ни файда? Дөрес, мине мактарлар, премия дә бирерләр. Акчамы инде ул! Ни эшләргә?! Тукта, башта, чыннан да, төгәл белергә кирәк. Миша каны микән ул, юкмы? Соңыннан күз күрер», — дип уйлады.

Миша бер атнадан да, ике атнадан да күренмәде, эзсез юкка чыкты. Фаяз икенче көнне дусты майор Гәрәевкә эшнең нидә икәнен сөйләп бирде, киңәш сорады. Тегесе исә: «Үзеңә кара. Теләсәң ач, теләмәсәң юк», — дип кенә әйтте.

Ике көннән капитанның башында план өлгереп җиткән иде. Башта ул, Светаның өйдә икәнен белгәч, аларга кереп чыгарга булды. Ишекне хуҗабикә үзе ачты. Милиция формасындагы Фаязны күргәч, хатын бераз югалып калгандай булды. Мөкминовның: «Сәлам, күрше, хуҗа өйдәме соң?» — дип соравына, Света: «Кем белгән инде аның кая йөргәнен, алкаш алкаш инде, минем белән талашты да, Архангельскидагы туганнарыма китәм, дип чыгып киткән иде, менә айга якын ни хәбәре, ни үзе юк. Әй, ярар әйдә, чәнчелеп китсен, ни эше, ни ашы булмады. Тукта, нишләп ишек төбендә totам соң әле мин сезне, Фаяз Гыймранович, зинһар, керегез, әйдәгез, әйдә!» — диде.

Капитан түргә үтте. Өйдә элеккеге муллыктан берни калмаган диярлек. Дөрес, залда буш булса да яңа стенка — сары төстәге «Шатлык» тора. Хуҗа хатын Фаязның уйларын аңлап алды, ахры:

— Менә үзең күрәсең, Фаяз Гыймранович, бөтен әйберне эчеп бетерде. Өстәвенә дуслары бөтен өйне чистартып чыктылар. Әйдә, Архангельскиенда гына яшәсен шунда. Гомер буе эшләп җыйган малны юкка чыгарды да куйды паразит. Мине ялыныр, артыннан барыр, дигәндер. Кирәге бар иде тинтәкнең, — дип зарланды.

«Димәк, фатирны талаткан өчен үтергәннәр,» — дип уйлады капитан. Ул Мишаларның фатирлары басылуын болай да

ишеткән иде, әле аптырап та йөрде, нишләп болар милициягә хәбәр итмиләр икән, өстәвенә миңа да әйтмиләр, дип. Ул, уйларыннан аерылып, Светага күз салды. Сары чәчле, төз буйлы чибәр бу ханымга элек тә кызыгып йөри иде Фаяз. Бүген дә моның белән йоклап карасаң, начар булмас иде, дип уйлады.

— Фаяз, нишләп чит кеше кебек басып торасың, кухняга үт, әйдә. Инде син дә безне онытып бетердең, күптән кергәнең юк дим! Әйдә, әйдә, тизрәк үт, — дип, хатын аны кулыннан тотып кухняга алып керде. Өстәлгә суыткычтан «Ак бөркет» аракысы, колбаса, тавык, тозлы кыяр, кызыл икра, ниндидер чит ил консервасы алып куйды. Света, өстәл әзерли-әзерли:

— Күршене сыйларга әллә ни дә юк инде, гаеп итмәгез, зинһар, бүтән сыйлар нәрсәм юк» — дип сөйләнде. Чәйнек кайнап чыккач, торып чәй пешерә башлады. — Фаяз Гыймранович, үзегез өстәлгә хуҗа булыгыз әле, әнә рюмкалар, сала торыгыз. Инде адәм рәтле кеше белән утырып аракы эчмәгәнгә дә бишбылтыр. Мин хәзер чәй генә пешерәм дә... Бәлкем, сезгә кофедыр?

— Юк, юк! Чәй дә ярый.

Капитан «Ак бөркет»не ачып, рюмкаларга аракы тутырды. Үзе һаман хатынның шома, матур ботларын күзләде. «Монда тауар бар», — дип уйлады. Хатын исә чәй пешерде, ипи турады, үзе бертуктаусыз елмаеп, нидер сөйләде. Имеш, ире кадерен белмәде, бар булганын эчте, беркайда да эшләмәде. Ирдән бәхете булмаганына зарланды. Ә Фаязның исә уйлары бөтенләй башкада иде. Аңарда бу хатын белән бергә булу теләге көчәйгәннән-көчәйде.

— Иптәш капитан, нишләп уйга баттыгыз, әйдәгез әле, тотыйк!

Фаяз үзенең уйларыннан айнып китте.

— Ә, гафу итегез, ничектер эш турында уйлап, оеп киткәнмен, — дип алдады.

Хатын аны бертуктаусыз сыйлады да сыйлады. Чираттагы рюмка да бушагач, Света күршесеннән:

— Миша нәрсәгә кирәк иде соң, әллә сиңа бурычы бармы? — дип сорады.

Капитан:

— Әйе, — дип ычкындырды да куйды.

— Күпме соң, Фаяз?

— Ә, ни, күп түгел, бер илле мең алды, икенче юлы егерме биш мең иде бугай. Ерунда, вообщем. Акча түгел...

Дөрес, бер бик нык салып алган чагында, капитан Мишага унбиш мең биргән иде, тик анысын да бергә эчеп бетерделәр. Хатын залга кереп чыкты, аның кулында 100 меңлек акча иде.

— Фаяз дус, зинһар, үпкәләмә инде ул мөртәт өчен, ул бит биш минут элек нишләгәнен дә оныта. Мә, алыгыз, менә бир-

мичә йөрткәне өчен сезгә компенсация булыр. Сдачасын бирсәгез дә алмыйм, уйлый да күрмәгез, — дип, акчаны аның кесәсенә тыкты. Капитанның үзендә сукыр бер тиен дә булмау өстенә, кешеләргә дә илле меңләп бурычы бар иде. «Илле мең кала, хезмәт хакы алганчы яшәргә дә, бурычларны түләргә дә җитә», — дип уйлап алды ул.

Өченче рюмкадан соң, аларның иреннәре бергә кушылды. Әллә аракы ярдәм итте инде, әллә икесенең дә уртак теләкләре булуы — алар караватка барып яттылар. Светаның ыңгырашуы, аратирә кычкырып-кычкырып алуы Фаязның дәртен арттыра иде...

Фаяз Светалардан иртәнге алтыда чыгып китте. Аның колагында әле һаман: «Син чын ир, Фаяз, чын ир, мин сине яратам, синең кебек ирне минем әле күргәнем юк иде», — дигән сүзләр яңгырый иде. Хатынның кайнар үбүләреннән аның әле һаман иреннәре яна. Ул хатыннан, бигрәк тә үзеннән канәгать иде. «Шәп хатын. Ну, үзенә күрсәттем инде чын ирләрнең нинди булганын! Күптән болай рәхәтләнгән юк иде. Нишләргә? Бәлкем, Света белән бергә генә яшәргәдер. Чибәр, ашарга бар, эчәргә җитәрлек булачак. Юк, булмый, әгәр дә алай-болай эш ачыла калса, миңа тап төшерүе бар. Пенсиягә дә ике генә ел калды. Алла сакласын!» — дип уйлады ул. Инде әллә кайчан әнисе янына кайтмаганы, салынып бетмәгән дачасы исенә төште. «Юк, план үзгәрми. Элеккечә калачак», — дигән карарга килде.

Бар да җентекләп үлчәнгәч, кат-кат уйлангач, тикшерелгәч кенә Фаяз планын тормышка ашырырга булды.

Света, өенә кайтып ишекне ачып керүгә, идәндә яткан язуга тап булды. Аны ишек ярыгыннан төртеп керткәннәр. Анда «Мин Мишаның үтерелүен беләм, «девятка»га тутырып алып китеп, юкка чыгарылуын да. Тавыш чыгармаячакмын, бүтән беркем белми, белмәячәк тә. Әгәр сез миңа егерме биш миллион бирсәгез. Акчаны кая китерергә икәнен телефоннан хәбәр итәрмен. Кирәкмәгән ниятләр турында уйламагыз да, файда булмаячак! Миндә Мишаның кан анализлары бар. Хәбәр көтегез» дип язылган иде. Светаны аяз көнне яшен суккан кебек булды. «Кем күреп калды икән? Кайда хата китте? Нишләргә? Тукта, Сашага хәбәр итәргә кирәк!» — дип уйлады.

Фаяз зур тюльпан букеты алды. Аның Светаларга кереп, язуның ничек тәэсир иткәнен, ни кылырга уйлаганнарын беләсе килә иде. Кичке сәгать уннар тирәсендә ул, урамда кешемазар сирәкләнгәч, күршеләренә юл тотты. Өй каршында таныш «девятка» тора. «Әһә, киңәшмәгә җыелганнар тегеләр», — дип уйлады ул. Һәм ялгышмады.

Ишекне хуҗабикә үзе ачты, йөзендә ниндидер борчылганлык күренә, шулай да ханым, елмаеп:

— Фаяз Гыймранович! Әйдәгез, әйдә, түрдән узыгыз, рәхим итегез, ой, нинди матур чәчәкләр! — дип каршы алды.

Капитан чәчәкләрне сузды:

— Бу сезгә, рәхим итеп алыгыз!

— Нинди матур тюльпаннар, рәхмәт сезгә, әле дә чын ирләр бетмәгән икән дөньяда, узыгыз, әйдә, узыгыз, — дип, хатын Фаязга юл бирде. Залда Саша белән Шәрип утыра. Капитан аларга да кул биреп күрешкәч:

— Мин вакытсызрак кердем, ахры, сездә кунаклар бар икән, гафу итегез, мин икенче юлы керермен, — дип, чыгарга борылды.

Хатын исә тагын елмаеп:

— Юк, юк, нинди чыгу ул. Болар бит чит кешеләр түгел, монысын беләсең инде, минем энем, бусы — аның иң якын дусты, иптәш малае. Утырыгыз, утыр! Хәзер генә кичке аш өлгерде. Кухняда кысанрак булачак, ашны залга кертәм. Саша, әйдә, миңа булыш әле.

Света белән энесе чыгып киттеләр. Залда Шәрип белән капитан гына калды. Телевизордан ниндидер концерт бара иде. Фаяз алдарак утырган Шәрипкә күз салып алды. Кыска чәчле түгәрәк баш, аның нәкъ түбәсендә шрам ярылып ята. Киң, таза муен. Капитан бераз сүзсез утыргач: «Кем җырлый моны?» — дип сорады. Шәрип, аңа таба борылып: «Исемен белмим, җырлавына караганда, бер сөйрәлчек инде шунда», — дип, кире телевизорга текәлде. Егетнең иягендә дә шрам эзе бар. Борын кәкрәйгән, күзләр явыз иде. «Бу бәндә дөньяны күп пычраткан ерткычка охшаган, Алла сакласын, сак булырга кирәк болар белән», — дип уйлады Фаяз. Залда күңелсез тынлык дәвам итте. Экранда икенче бер артист җырлый башлады. Шәрипкә җыр нык ошаган, ахры, борылып: «Шәп манчый бу, үзе гомикка охшаса да, җыры шәп, яздырып алырга кирәк әле моны», — дип куйды. Ниһаять, залдагы киеренкелекне бозып, Света килеп керде. Капитан алдына аш куеп:

— Нишләп телсез калып утырасыз, егетләр? — дип сорады. Фаяз белән Шәрип: «Менә концерт тыңлыйбыз әле», — дип, икесе берьюлы җавап кайтардылар. Бу сүзләрнең шулай икесенең авызыннан да бергә чыгуына аптырап, бер-берсенә карашып алдылар. Яңа гына килеп кергән Александр, көлеп:

— Сез, егетләр, нәкъ армиядәге кебек җавап бирәсез, бик шәп, форманы югалтмагансыз икән! — диде.

«Шулай да Шәрипнең сөйләшүе ачулы, әллә Светаны көнли, әллә миннән шикләнә инде», — дип уйлады Фаяз. Чыннан да, Шәрип капитанны өнәп бетермәде. Кешеләрне яхшы аера иде ул. Башта колония, аннан төрмә, соңыннан кабат төрмә тормышы аны сак булырга өйрәтте. Гомумән, ул милиция халкын яратмый иде. Шуңа өстәп, чыннан да, Светаны да көнли. Чөнки алар бу хатын белән күптән, ире исән чакта ук бергә булгаладылар. Мишага күп кирәкми, бер яртыны сала да исе-

реп ава иде мәрхүм, хет соңыннан үзен тотып эшкәрт, типкәләп йөрт, бомба шартлат, берни сизми иде, авыр туфрагы җиңел булгыры...

— Шәрип, нишләп уйга баттың, әйдә, проблемаларыңны онытып тор, әйдә, сал рюмкаларга. Мә, кәбестә шулпасы, яраткан ашың бит, — дип, Саша дусты алдына тәлинкә китереп куйды.

Капитан, бу компаниядә тагын бер сәгатьләп утыргач, чыгып китте. Шәрип, җиңел сулап: «Уф, козел, тапкан керер вакыт. Ошамый ул миңа, ант итеп әйтәм, акча сораучы ул булуы да мөмкин», — дип, Светага сынаулы караш ташлады. Хатын исә бу басымның аңа ясалуын сизсә дә, берни аңламаган кебек ашавын дәвам итте, эчтән: «Көнләшәсеңмени, көнләш әйдә, көнләш, бераз көнләшүдән зыян юк», — дип уйлады.

Бераздан Света:

— Ул эчкечедән булмас, җүнләп эшләгәне дә юк бугай аның. Миша белән бик еш салгалыйлар иде алар. Шул иске гадәт белән кергәли бугай, — дигәч, торып, бушап калган савыт-сабаларны җыярга тотынды.

Шәрип исә тагын да нервыланып:

— Аның шундыйлары эшли дә инде, җүнлесе күптән кулга алган булыр иде. Иң яхшысы, хәзер акча сораучыдан ничек котылу турында уйларга кирәк!

— Бәлкем, акча җыеп бирергә дә, котылырга кирәктер, — дип, Света егетләргә карады.

— Ул хәзер бер сорар, беткәч тагын, — диде Шәрип. — Иң яхшысы, чирне вакытында дәваларга кирәк. Света, телефоннан хәбәр килүгә, безгә белдер. Ә без Саша белән берәр нәрсә уйлап куярбыз.

Тагын ярты сәгатьтән фатирда Света белән Шәрип кенә калды. Йокы бүлмәсеннән хатынның ухылдаган, ыңгырашкан, кычкырган, «Уф, не могу, миңа рәхәт синең белән, Шәрип. Син чын ир, мин әле синең кебек ирне күргәнем булмады», дигән тавышлар гына ишетелә иде.

## КАПИТАН ФАЯЗ МӨКМИНОВНЫҢ ПЛАНЫ ТОРМЫШКА АША

Телефон тагын өч көннән соң, төнге бердә шылтырады. Света, трубканы күтәргәч, аңа һәрбер сүзгә басым ясап: «Тагын өч сәгатьтән, — диде калын тавыш. — Ягъни сәгать дүрттә. Югары Ослан районы, аңладыңмы. Шура авылы янында юл төзүчеләр вагоны тора, шуның астына теге төргәкне калдырып китәсез. Көтеп тормыйсыз, акчаны аска куюга, кире борылып китеп барасыз. Шикле әйбер сизелсә, шундук тиешле органнарга хәбәр ителәчәк. Тагын өч сәгатьтән!»

Капитан Фаяз Мөкминовның планы әйбәт иде. Җинаятьчеләр килгәндә, ул юл кырыендагы урман эчендәге агач башына менеп, тирә-якны күзәтә. Шикле әйбер сизелсә, машинасына утырып, урман эчендәге сазлы юлдан ычкына. Әгәр инде барысы да әйбәт икән, вагонга кадәр йөз метр, тиз генә чабып чыгып төргәкне ала да урман эченә качырылган УАЗга утырып, икенче урыннан үзәк юлга килеп чыгачак.

Света бу хакта энесенә шылтыратып әйткәч, Саша, хәзер Шәрип янына китәм, дип трубканы куйды. Чөнки өч сәгать кенә вакыт бар иде. Күрсәтелгән урынга бер сәгатьлек юл. Шулай да алданрак барырга кирәк. Юлда әле ГАИ туктатып тикшерер. Анда күпмедер вакыт үтәр. Шәрип озак көттермәде. Унбиш-егерме минуттан машинада иде. Шәһәрдә әле транспорт аз, чөнки иртәнге өченче ярты гына. Туктатып тикшерделәр. Алай бәйләнер нәрсә тапмагач, сержант:

— Кая юл тоттыгыз болай иртә? — дип сорады.

Шәрип аңа:

— Апаска, туганнарга кунакка кайтабыз әле, — диде.

— Хәерле юл сезгә, — дип, ГАИ хезмәткәре честь биреп калды. Машина кузгалып алга ыргылды. Тирә-якта нарат урманы. Иртәнге кошлар сайрый. Кызарып таң ата. Каршыга сирәк-мирәк кенә машиналар да очрый. «Их, нинди матур көн, рәхәтләнеп бер ял итәсе иде дә, юк бит, ниндидер козел эш чыгарды», — дип уйлап куйды Шәрип. Аннан, Сашага карап:

— Соң, ничек инде кан тамчылары калдырырга була, аңлатыгыз әле шуны миңа?! Сөртергә була иде бит инде аны. Әйттем бит апаң белән җизнәңә бирмик ул эшне дип, аңламадың. Сез нәкъ беренче мәртәбә кияүгә чыккан кебек кыланасыз, анагызны шулай итимнәр, — дип, канәгатьсезлек белдерде. Ул бик каты нервылана иде.

Саша, аклангандай итеп:

— Кайчан егылып үләсен беркем дә белми, әйтмәдем түгел, әйттем Светага, яхшылап сөрт, җыештыр, дип. Өйне чистарткан, подъезддагысын күрмәгән, ахры. Урамда да, бәлкем, тамгандыр.

Шәрип тавышын күтәрде:

— Соң, егерме алтыга җиттең, арт ягыңны сөртергә тәки өйрәнә алмадың. Алда нинди акчалы операция тора, ә син бөтен эшне җимереп ташларга маташасың. Әйттем бит мин сиңа!..

Саша, аңа йомшак кына:

— Нәрсә, әллә тауарны базарда үзең сатмакчы идеңме? — дип әйтеп салды. Шәрип берни дәшмәде. Чөнки дусты хаклы иде. Алып кайткан малны сатарга кеше барыбер кирәк булачак.

Шәрип, бераз йомшарып: — Анысы шулай инде аның. Син шулай да теге эш турында да төпле җавап бирмәдең, — диде.

Саша, бераз дәшми торгач:

— Тукта, бу эшкә нокта куйыйк әле, аннан күз күрер, — дип җавап кайтарды.

Машина Залесный поселогына килеп керде. Егетләр тынып калдылар. Менә зур күпер. Анда ГАИ туктатып тормады. Тагын ун минуттан машина Югары Ослан борылышына җитеп, Апас ягына чапты. Шәрип бу якларны яхшы белә. Тиздән Шеланга борылышы, шул юлга кергәч, тагын җиде-сигез чакрымнан Нур Вахит авылы, аннан Шура авылы терәлеп тора. Димәк, иң күбе тагын унбиш минут вакыт кирәк. Юл яхшы, яңа салынган. Уң якта Нур Вахит авылы да калды. Авыл әле уянып бетмәгән, каядыр сыер мөгрәгән, әтәчләр кычкырган тавышлар гына килә. Күктә яңа аэропортка таба самолет очып үтте. Алда Шура урманнары күренде.

Фаяз Мөкминов, телефоннан хәбәр бирүгә, эштәге УАЗ машинасын алып, иптәшләренә:

— Бер мәткә белән дачага гына барам, ике сәгатьтән кайтам, егетләр, — диде.

Хезмәттәшләре:

— Илле чакрым туда-сюда йөргәнче, Казанда урын беткәнме әллә? — диештеләр.

— Юк, егетләр, табигатьтә ятуларга җитми инде ул, анда һавасы гына да ни тора, — дип җавап бирде Фаяз.

Тиешле урынга килеп җиткәндә, өч туларга биш минут калган иде. Капитан бу җирләрне кичә карап, ныклап өйрәнеп кайтты. Ул УАЗигы белән урман эченә керде. Тирә-юньнән төрле үсемлек, чәчәк, черегән агач исләре килә. Кошлар сайрый. Җәйнең иң матур вакыты, дип уйлап алды Фаяз. Их, авылга кайтып ял итәсе иде. Тизрәк бу акчаны аласы да әнкәй янына сызасы. Бу акчага өйгә видеодвойка, бер стенка, берәр келәм алырга кирәк. Өйне бераз рәткә кертергә күптән вакыт инде. Югыйсә бөтен әйбер теге сукага калды. Йә, ярый, анысы бала хакы инде. Тик шулай да үзем турында да уйларга вакыт. Хөкүмәт түләгәнгә генә яшәп булмый. Хөкүмәт кешеләре әнә үзләрен генә кайгырта. Аларның аппетиты ачылганнан-ачыла. Кая карама ун гаилә әгъзасы сыярлык коттеджлар, дачалар, мунчалар салына. Кем акчасына, әлбәттә, эшче халык акчасына. Шуңа күрә, Фаяз әфәнде, үзеңне-үзең кайгыртмасаң, түрәләр биргән хәер акчасына гына яшәп булмый ул.

Фаяз үзенчә шулай фикер йөртте. Бу аңа үзе кылачак гамәлен аклар өчен кирәк иде.

Олы юлда машина тавышы ишетелде. Фаяз тиз генә агач башына үрмәләде. Анда Казан ягыннан бер ЗИЛ машинасы килә иде. Ул вагон янына туктап тормады, ничек килсә, шул тизлек белән юлын дәвам итте. Ахры, берәр колхоз машинасыдыр. Капитан сәгатенә күз салды. Әле иртәрәк булганга, агач башыннан төшеп, пычракка баткан машинасы янына килде.

Аның эче поша иде. Шушы бер сәгатьне ничек тә үткәрергә кирәк. Бер сәгать! Бу бер сәгать күп нәрсәләргә ачыклык кертәчәк. Алла боерса, әни янына да кайтып килергә булыр. Кайтмаганга да ярты ел була торгандыр инде. Кайтам дисәң, акча юк, акчасы булса, эчеп бетерелә. Юк, бу юлы, һичшиксез, кайтырга кирәк. Базардан икешәр кило чикләвек, кара җимеш, лимон алырга туры килер. Аннан бер өч кило җүнлерәк конфет. Шатлансын әле карчык! Күрше, ахирәтләрен дә сыйласын әле, улым күчтәнәче, дип. Мактансын әле бер картаймыш көнендә. Тукта, тагын нәрсә алырга? Ә, хәлвә! Әнкәй бит хәлвә ярата! Онытып җибәргәнмен. Анысын да бер биш кило алырга кирәк. Рәхәтләнсен әле хәлвәгә. Хәзер хәлвә дефицит микән соң? Нишләп дефицит булсын ди! Хәзер бит кесәңдә акчаң гына булсын, бар да бар. Әйе шул, әлеге дә баягы, акча кирәк. Акча боза шул кешене. Күпме булса да җитми. Җитмәде дә, җитми дә. Хотя, булса да тота белмәдең инде син аны, Фаяз. Хәзер акыл керергә вакыт җитте. Егерме биш миллионны әрәм итәргә ярамый. Шәп сумма! Күп көтәргә калмады. Тагын ярты сәгать кенә. «Уф, көтүләре ничек авыр», — дип уйлады ул.

Тирә-юньдә кеше заты күренми, әле көтү куарга да вакыт җитмәгән. Машина нәкъ вагон алдына килеп туктады. Шәрип төшеп, тирә-якка күз салды. Аның карашы авыл ягына, анда кызыксындырырлык әйбер күренмәгәч, каршы яктагы урманга төбәлде. «Каяндыр теге падло безне күзәтә инде», — дип уйлады ул. Урман авызына бер мизгел карап торгач, борылып вагон янына килде. Куеныннан төргәкне чыгарды. Аннан соң, иелеп, куяр урын эзләде. Иң ошаган урын арткы көпчәкнең эчке ягы иде. Вагон астында тагын асфальт тарата торган берничә көрәк, калын табанлы аяк киемнәре ята. Шәрип, аларны бераз читкәрәк этеп, урын җайлады да, төргәкне куеп, чалбарына кунган тузанны каккалагач, машина янына китте.

Фаяз, «девятка» тавышын ишетүгә, агач башына менеп боларны күзәтә иде. Бу юлы ул ялгышмады. Нәкъ ул көткән машина булып чыкты. Ишектән чыккан Шәрипне дә яхшы таныды ул. Төргәкне куеп, кире машинага киткәнен дә күрде. Шикләнерлек әйбер сизмәде.

Яңа килгән машина алга-артка бер-ике тапкыр чикте дә, борылып Казан ягына чапты. Асфальт юл булуга карамастан, тузан өермәсе күтәрелеп калды. Машина китеп күздән югалгач, Фаяз, агач башыннан төшеп, юл кырыена чабып чыкты. Шикләнерлек нәрсә юк. Бар көченә чабып юл өстенә менгәч, тиз генә иелеп теге төргәкне сөйрәп чыгарды да, ялт итеп куенына тыкты. Як-ягына карап алды да, кире урманга чапты. Машинасын кабызып, үкертеп газ биргәч, кузгалып китте. УАЗ сазлы-чокырлы урыннарга төшеп чумгаласа да, батып калмыйча алга баруын дәвам итте. Тиздән урман бетеп, кыр башланды,

каршыда бер чакрым-чакрым ярым ераклыкта олы юл күренә иде. Ул куеныннан теге төргәкне тартып чыгарды. Төргәк исә шактый гына күренә. Вак купюралар күп, ахры, дип уйлап алды капитан.

Бу вакытта Шәрипләр машинасы Нур Вахит авылын әз генә үтеп, юл кырыена төшеп туктап калган иде. Озак та үтмәде, Шура урманының арткы ягында каты шартлау яңгырады. Соңрак тагын бер шартлау. Бусы, ахры, бензин багы. Егетләргә хәзер бер генә нәрсәне — акча таләп итүченең исәнме-юкмы икәнлеген генә ачыклыйсы калды. Шәрип, иптәшенә карап: «Коралың болай әйбәт эшләде, нәтиҗәсе генә ничек икән?» — диде. «Мин ясаган коралның әлегә кадәр нәтиҗәсе булмый калганы юк иде», — дип куйды Саша.

Алар килеп җиткәндә, шартлау булган җирдә берничә машина туктап, пассажирлары кыр эченә үк кереп яна торган УАЗикны күзәтәләр иде. Бер кеше: «Милиция машинасы булган, әнә фуражкасы да ята», — дип куйды. Шәрип, алгарак үтеп: «Ә кешесе исән түгел микән соң?» — дип сорады. Берәү: «Кая исән булсын инде, әнә ич, өзелгән кулы кая барып төшкән», — дип куйды.

Чыннан да, анда кеше кулы ята иде. Тирә-юньдә башка ит кисәкләре дә, яралы гәүдә дә күренмәде. Саша иптәшенә күз кысып алды, ярый, әйдә, китик, без монда бернәрсә белән дә ярдәм итә алмыйбыз, юлда очрасалар, органнарга да хәбәр итәрбез, дип, юлга таба юнәлделәр. Аларга хәзер янып үлгән милиционерның Фаяз Гыймрановичмы, түгелме икәнен генә ачыклыйсы калды. Миша турында тагын берәрсе белми микән дигән уй да тынгы бирмәде. Тагын берничә көннән бар да ачыкланыр, көтәргә генә кирәк. Егетләрнең икесенең дә башына шундый уй керде. Шәрип түзмәде, тезеп китте: «Әйттем бит мин сезгә акча сораучының кем икәнлеген, ә сез ышанмаган идегез. Киләчәктә сак булырга кирәк. Светага да әйтергә, кешеләр белән аралашмаска, һәр кылган эшен безнең белән киңәшләшеп эшләсен!»

Саша елмаеп кына куйды. Тагын ярты сәгатьтән алар Югары Ослан пристане янында, бар дөньяларын онытып, уйный-чума су коеналар иде.

Менә шулай итеп, Фаяз Мөкминовның планы аянычлы тәмамланды.

## БЕРДӘМ ФИКЕРГӘ КИЛҮ

Капитанны олылап күмделәр. Бер-бер артлы тезелгән милиция машиналары мәрхүмнең көлен күтәреп баручы кешеләргә иярде. Фаяз Гыймрановичны соңгы юлга озатырга хатыны белән баласы да килде. Авылдан карт әнисе генә килә ал-

мады, бу хәлне ишетеп, ана аяктан егылган иде. Озату процессын каршы йорт тәрәзәсеннән тагын өч кеше күзәтеп тора иде. Аның берсе, әлеге дә баягы, Света ханым булса, калган икесе төп геройлар — Шәрип белән Саша дуслар иде. Шәрип, бераз тәрәзәдән карап торгач, кесәсеннән гәҗит чыгарды да: «Мә, укыгыз, менә нәрсә язалар бу вакыйга турында», — дип, үзе үк укый да башлады. «Милиция капитаны, алдынгы хезмәткәр Фаяз Гыймранович Мөкминов явызларча үтерелде. Хәзерге көндә тикшерү эшләре алып барыла, инде органнар җинаятьчеләрнең эзенә төште. Тиздән алар кулга алыначаклар...»

Тыштан тыныч күренсәләр дә, егетләрнең эче тулы борчылу сизелә. Өч көн үтсә дә, тынычланырга әле иртәрәк икәнен алар өчесе дә белә иде. Света, тынып калган егетләргә борылып:

— Әйдәгез әле, булмаса, бүген ресторанга барып күңелне күтәрәбез. Егерме биш миллион янда калган икән, нигә аның бер миллионын җәлләргә. Аннан гына зыян килмәс.

Шәрип тә күтәреп алды:

— Начар фикер түгел бу. Хәзер инде буласы эш булган, борын салындырып утырмыйк. Миңа калса, «Казан» рестораны кулай булыр. Чөнки анда яхшы хезмәт күрсәтәләр, шәп әзерлиләр! Саша, син теге Маринаңны да ал. Бергә-бергә күңеллерәк булыр.

— Юк. Миннән башка тагын әллә кемнәр белән чуала икән ул. Өстәвенә бертуктаусыз бүләкләр сорый. Туйдырды.

Света энесенә карады:

— Видео белән телевизор алып бирдең ич инде, әллә шул җитмәгәнме аңа? Инде чүпрәк-чапракларыңны санап та тормыйм. Үзе бит ул сукыр тиен дә тормый. Үзең аздырып бетердең син аны! Ташла син аны, беткән ди рәтлерәкләре. Аннан, җыен себеркене баетканчы, өйләнергә кирәк сиңа. Әни берүзе. Син тегендә-монда йөргәндә, хет иптәш булыр иде, ичмасам.

Саша урыныннан ук торды, апасының сүзләре аның авырткан җиренә үк тиде бугай:

— Нәрсә, беренче эләккән әнчек эткә өйләнимме әллә?! Кая соң аның рәтлерәкләре, өй белән бала багып ятучылары? Күрсәт берәрсен? Ник дәшмисең? Шулай шул, җаным, барыгыз да бер, — диде.

— Соң, энем, үзең беләсең бит, мин, Аллага шөкер, җизнәң исән чакта чит кешеләргә борылып та карамадым.

Саша мыскыллы көлде:

— Синме, кит инде, апа, хет миңа ялганлама, җизни исереп егылган саен, син Шәрип кочагында идең. Кемне алдамакчы буласың син?

Апа белән энекәш бәрелешен Шәрип тик елмаеп тыңлап утыра иде. Светаның күзләрен кан басты:

— Булса соң, ул булдыра алмаган җизнәң белән яшәгәнгә рәхмәт әйтегез әле миңа. Бар белгән эше эчеп егылу иде. Ә Шәрипкә рәхмәтле мин, ул миннән чын хатын-кыз ясады. Һәм яратам мин аны, ул булмаса, мин ирләр күрмичә үлә идем, — дип, хатын өстәлгә капланып үкси үк башлады.

Саша исә көлеп җибәрде:

— Мин каршы түгел, ярата бир, теләсәң нишлә, тик мине генә алдап маташуың ошамый.

Бу хәлне карап утырган Шәрипкә Светаның «яратам» дигән сүзләре ошады, ахры, ул да сүзгә кысылырга булды.

— Ярар инде, Саша, бәйләнмә апаңа, бер юктан сүз куертасыз, елки-палки. Ну, апаң белән без бер-беребезне ошатышабыз икән, шуннан ни? Бәлкем, мин дә аны ярата торганмындыр...

Света тагын да катырак үкси башлады. Ни генә булмасын, ул барыбер хатын-кыз иде шул. Аның да матур сүзләр ишетәсе, бүләккә чәчәкләр аласы, яраттырасы килә иде. Ул торып Шәрип янына килде, егетнең муеныннан кочаклап алып, җилкәсенә башын салды, Шәрип исә, үзенең тупас куллары белән хатынны тынычландырырга теләгәндәй, аркасыннан каккалады. Саша, өстәлдә яткан тәмәке пачкасын алып, кесәсенә тыкты да, ярый, мин машинада көтәм сезне, дип чыгып китте. Шәрип белән Света икәү генә калдылар. Света, егетнең кочагыннан чыгып, көзге каршында күзләрен сөртте, массаж тарагы белән чәчләрен рәткә китергәч, Шәрипкә борылып:

— Минем сиңа әйтәсе бер серем бар иде, — диде. — Әйтергә микән, юк микән, белмим инде, нишләргәдер, — дип, сәер елмайды.

— Нинди сер икән инде ул тагын, кызык. Йә, әйтеп кара, — дип, гаҗәпләнеп хатынга карады.

Света, аның күзләренә текәлеп:

— Шәрип, минем балам булачак, ул үзен яңа гына белгертте, — диде.

Шәрип, аптырап:

— Балаң? Ничек? Кемнән? — дип сорады.

— Синнән инде, кемнән булсын.

— Миннән? Алдыйсың. Ничек миннән?!

Ул хатынга карап катты. Чөнки бу көтелмәгән хәлдән аптырабрак калган иде. Ничек инде аның баласы була?! Һич көтмәгәндә, уйламаганда. Балалар шулай тиз һәм көтелмәгәндә була микәнни?! Аның өчен башта өйләнергә кирәк түгелме соң? Света аның күзләренә карады.

— Әйе, Шәрип, безнең балабыз булачак. Син телисеңме, теләмисеңме, мин аны табачакмын. Чөнки мин сине яратам, чөнки минем яшем утызга җитеп килә. Берьялгызым каласым килми минем, Шәрип...

Шәрип, аптырап калса да, бу яңалык аның өчен күңелсез

хәбәр түгел иде. Димәк, аның баласы булачак. Ул үзен бәби күтәргән килеш күз алдына китерде. Ничек итеп арбага салып йөргәнен, кулыннан тотып йөрергә өйрәткәнен. Төрле-төрле уенчыклар алып бирәчәген, машинага утыртып йөртәчәкләрен уйлады. Үзенең берни күрмичә үсүе, исерек ата-ананың бертуктаусыз кычкырышулары, бер-берсен мәсхәрә итешүләре, үзенең чит балалардан, аларның уенчыкларыннан, киемнәреннән көнләшүе, үзенең акылсыз вә тотнаксыз өлкәннәрдән оялулары күз алдына килеп басты. Мәктәптә укыганда иң тузган, таушалган кием аныкы булыр иде. Һәрвакыт ярым ач килер иде. Шуңа күрә ул бик иртә үз көнен үзе күрә башлады. Башта классташларының әйберләрен чәлдергәләсә, тора-бара транспортта кесә чистартырга, кибет басарга кереште... Колониядә, төрмәдә утырып чыкты. Аның күз алдыннан үткән тормышы куркыныч бер төш кебек үтте. Юк, ул баласын андый тормышка калдырмаячак. Ул күргәнне аның газиз баласы күрмәячәк. Нарасыена ул хәленнән килгәннең барысын да эшләячәк! Барысын да!

Шәрип, уйларыннан аерылып, Светага карады, аның күзләренә мөлдерәп яшь тулган иде: «Света, рәхмәт сиңа. Шушындый борчулы, күңелсез көннәрдә миңа шатлыклы хәбәр әйткәнең өчен. Сакла син аны, тап. Мин исән булсам, аның өчен барысын да эшләячәкмен», — дип, хатынны кочаклап, битләреннән үпте. Булачак ананың шатлыгы эченә сыймады. Бу хәтлесен Света көтмәгән иде. Шәрипне каршы килер, баланы төшерергә өндәр, гомумән, риза булмас дип уйлаган иде. Ә киресе килде дә чыкты. Аның кәефе күтәрелде. Ничек күтәрелмәсен ди, беренчедән, күптән хыялланган балага узды, икенчедән, Шәрип туачак баладан баш тартмады...

Аларны Саша гына:

— Күпме көтәргә була инде сезне, — дип, ачулы каршы алды. — Тагын бераз торсагыз, билләһи, китә дә бара идем.

Шәрип исә, авызын ерып:

— Китсәң соң, бик исебез китә иде. Тотар идек тә такси яллап теләгән җиребезгә очар идек. Шулай бит, Света? — диде.

Света шаркылдап көлеп җибәрде.

— Әйе шул, Шәрип, теләгән җиребезгә бара идек. Синең кыегайган авызыңа карап утырганчы...

Саша сәерсенеп аларга карады, тегеләр, бер-берсенә сыенышып, кочаклашканнар иде. «Ни булган соң боларга, әллә бер йөз илле грамм тартканнармы, аңлашылмый», — дип уйлап куйды. Бая гына елап калган апасының авызы чабата кебек ерылган. Сашаның аптырап каравы тегеләргә эчләрен тота-тота көләргә сәбәп булды. Алар тәгәри-тәгәри көлделәр. Сашаның кәефе күтәрелергә исәбе юк иде. Ул:

— Әллә бөтенләй ычкындыгыз инде, — дип мырлап куйды.

Шәрип, көлүен көчкә тыя-тыя:

— Мин сиңа бер яңалык әйтсәм, астыңа җибәрәсең, билләһи, — диде. — Ну, әлегә әйтмим, бераз тилмер әле!

Саша, исе китмичә генә:

— Эчегезне тырный башласа, әйтерсең әле, — дип кенә куйды. Бераздан аларның машинасы әкрен генә кузгалып, ресторанга юл алды.

Ресторанда, әле көндез булу сәбәпле, кеше күп түгел иде. Алар Бауман урамына караган тәрәзә янындагы өстәлне сайладылар. Официант озак көттермәде. Чибәр генә, сары чәчле егерме биш яшьләрендәге бер кыз иде ул. Саша, аңа карап, әллә бүген аны гына алырга микән, төскә-биткә дә куркыныч түгел, дип уйлап куйды. Шәрип заказ бирде. Озак та үтмәде, өстәлгә пилмән, шампан шәрабе, виски, тутырылган тавык, балык, җиләк-җимеш, шифалы су куелды. Ярты сәгатьтән компаниянең кәефе шактый күтәрелгән иде. Шәрип белән Света биергә чыгып киттеләр. Александр үзе генә утырып калды. «Нәрсә икән боларның миңа әйтми калган серләре? Берәр килде-китте әйбердер инде...» — дип уйлады ул.

Ресторанга ниндидер бомж килеп керде. Ул, кулларын сузып, юлында очраган беренче өстәл янына туктады. Ә өстәл артында зур гына бүксәле, үз-үзен тотышына караганда начальникка охшаган бер бәндә белән бер чибәр генә яшь кыз утыра иде. Юан бу ир-атның хәер сораган әлеге пычрак бәндәгә ачуы чыгып:

— Яле, ычкын әле моннан, шакшы хайван! Нәрсә, бу сиңа дуңгыз абзарымы йә булмаса ресторанмы? — дип кычкырды.

Бу тавышка эчке яктан берничә официант һәм тагын бер хатын килеп чыкты. Кыяфәтенә караганда, ул дежур администратор булырга тиеш. Алар җыйнаулашып теге бәндәне залдан этеп чыгара башладылар. Үзен залда утырган кешеләр янында да акларга тырышып, ахры, администратор хатын официантларга: «Күптән әйткән идем бит инде шул Иван Петровичны каравылдан алыгыз, дип. Аның көне булдымы, берәр хәл килеп чыкканын көт тә тор! Тагын берәр җиргә кереп, эчеп ята торгандыр инде, хайван!» — диде.

Теге юан ир-ат ярсуын дәвам итте. Администратор хатын килеп гафу үтенгәч кенә, тынычланып калды. Өстәл артында берүзе калган Саша залны күзәтә башлады. Түрдәрәк дүрт хатын-кыз тамак ялгап утыра. Болары сатучылар булырга тиеш. Алар арасында да үзенә ошаганын тапмагач, егетнең күзе икенче өстәлгә күчте. Анда бер яшь егет белән бер кыз тәмәке тартып, аракы эчеп кәеф-сафа корып утыралар. Өстәлләре бай түгел, графин белән аракы да ике салат алганнар. Болары студентлар, ахры. Шулчак ресторанга ап-ак чәчле, озын буйлы, ту-

лы күкрәкле, зәп-зәңгәр күзле бер кыз керде. Залдагы ирләрнең барысы берьюлы борылып аңа карадылар. Кызның өстенә кигән ромашкалар сурәте төшерелгән күлмәге генә дә сылу гәүдәсенең бер өлеше кебек, ямь өстенә ямь өстәп, килешеп тора. Кыз түргә узды. Сашаның күзләрен алмыйча үзенә карап торуын күргәч, елмаеп җибәрде. Егет аның бу елмаюыннан бөтенләй югалып калды. Туташ каршы яктагы өстәл артына килеп утырды. Аның йөрешендә, һәр хәрәкәтендә ниндидер нәфислек бар. Шундук официант пәйда булды. Озак та үтмәде, кызга салат, шампан шәрабе, шоколад китерделәр. Ул ашыкмый гына ашый башлады. Музыка туктагач, Шәрип белән Света да килеп утырдылар. Света, энесенең уйларын аңлап:

— Шәп нәрсә. Менә, ичмасам, кыз! — дип куйды.

Егет сер бирмәде.

— Таптыгыз чибәр нәрсә. Бөтен җирен буяган-ниткәндер әле. Бер артык җире юк.

— Әйдә, бөгештермә инде, ошый бит ул сиңа. Бар, чакыр үзен биергә, монда күкәй салып утырганчы, — диде Света.

— Чыгар микән соң ул?

— Чыгар, чыкмый кая китсен ул, — дип җавап бирде апа кеше. Шул сүзләрне генә көткән кебек, музыка да башланды. Александр, торып, теге туташ утырган өстәлгә юнәлде.

Рөхсәт сорап, кызны биергә чакырды. Егетнең борынына кыйммәтле хушбуй исе килеп бәрелгәч, башы әйләнеп китте. Туташ, чыннан да, искитмәле иде. Алар сөйләшми генә биюләрен дәвам иттеләр. Музыка бетеп, кызны өстәленә хәтле озатып куйгач, егет: «Сезнең белән миңа рәхәт булды», — дип, үз өстәленә китте.

Шәрип аны көтеп утыра иде.

— Нишләп безнең өстәлгә чакырмадың, берүзе утыра бит.

— Әллә ничек, уңайсыз, әле җүнләп танышырга да өлгермәдек. Килер микән соң?!

— Нишләп килмәсен, йөгерә-йөгерә килер бушлай тыгарга, — дип, Света гына тавышланып алды.

Энесе, аңа ачулы караш ташлап:

— Тыкса, синекен тыкмас, аңладыңмы, — дип куйды.

Апа кеше чәрелдәп көлеп җибәрде.

— Ха-ха-ха, минем кадерле энем гашыйк булган. Гомердә күрмәгән, булмаган хәл. Менә шулай була ул, дустым. Көтмәгәндә сихерләнәсең дә куясың!

— Җитте, апа! — дип, ырылдап куйды Саша. Чыннан да, башы-аягы белән гашыйк булып маташа иде ул.

Шәрип, аңа карап:

— Йә, йә, ярый, кайгырма, икенче мәртәбә биергә чыккач, безнең табынга чакыр үзен, соңыннан күз күрер, — диде.

Менә кабат музыка башланды. Саша яңа танышы Луизаны

тагын барып биергә чакырырга гына җыенып утыра иде, теге юан бәндә кыз өстәле янына килеп, аны биергә чакыра башлады. Хәрәкәтләренә караганда, шактый кызган күренә. Тик кыз чыгарга теләмәде. Абзый кызны кулыннан ук тотып сөйри башлагач, Саша түзмәде, торып, теге өстәлгә таба китте. Аңа Шәрип тә иярде. Син нәрсә эшлисең, картлач, дип, Александр абзыйны этеп җибәрсә дә, теге юан Луизаның кулын ычкындырмады. Егет абзыйның якасыннан ук тотып алды. Абзый алай сыек кеше булып чыкмады, Сашаны кулы белән этеп җибәргәч, борылып кызга да берне тартты. Луиза бию мәйданына барып төште. Абзый Сашага тагын бер селтәнгән иде, егет башын артка алып калып, уң кулы белән аның борынына томырды. Абзыйның ике күзеннән яшь бәреп чыкты. Александрга шул гына кирәк иде, башта ул абзыйның корсагына берне тибеп, уртага бөкләде, аннан уңлап-суллап яннан ике тапкыр бәрде. Юан бәндә, бәрәңге капчыгы кебек, идәнгә ауды. Ул арада абзый белән килгән теге яшь кыз, аның дипломатыннан ике йөзәр меңлекне алып, залдан чыгып сызды. Бу хәл булган җиргә ресторан эшчеләре, залда утырганнар җыелды. Саша, кулын биреп Луизаны күтәреп торгызгач: «Әйдәгез, әгәр теләсәгез, безнең өстәлгә утырыгыз», — дип, кызга тәкъдим ясады. Луизаның күз төбе бераз күгәреп чыккан, борыны канаган. Егет кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, кызның борынын сөртте. Аннан, биленнән тотып, үз өстәлләренә алып килеп, буш урындыкларның берсенә утырткач, кызга шифалы су салып бирде. Тегендә администратор хатын абзыйга мамык белән нашатырь иснәтә иде, ахры, абзый селкенгәли башлады. Бераздан, ул әкрен генә үрмәләп торып аягына басты, олы, авыр гәүдәсен сөйрәп ишеккә таба китте.

Яшьләр өстәлендә мәҗлес дәвам итте. Башта кыз белән танышу хөрмәтенә, аннары киләчәктәге уңышлар өчен эчтеләр. Инде теге күңелсез хәл онытылып бетеп, күңелләр күтәрелгәндә генә, ишектә ике милиционер күренде. Алар артыннан ук теге юан бәндә дә пәйда булды. Ул, егетләр утырган өстәлгә төртеп күрсәткәч, милиционерларның берсе, лейтенант погонлысы, өстәл янына килеп:

— Сез барыгыз да вакытлыча кулга алынасыз, минем арттан бүлекчәгә рәхим итегез, — дип, кулындагы резина таягын сул кулының учына бәргәләп тора башлады. Шунда Луиза торып басты:

— Иптәш лейтенант, бәлкем, ни өчен икәнен дә аңлатырсыз?!

— Менә бу иптәшне шушы егетләр кыйнап ыргытканнар. Бүлекчәдә ачыкларбыз, хәзер барыгыз да безнең арттан!

Луиза, матур гына итеп: «Иптәш лейтенант, алайса, хәзер үк миннән дә гариза алыгыз, — диде. — Сезнең монда килүегез яхшы булган. Менә бу хөрмәтле абзый мине көчли башлады.

Әгәр дә шушы егетләр булмаса, белмим, эш ни белән беткән булыр иде».

Әңгәмәне тыңлап торган юан бәндә ярсый башлады: «Көчләргә?! Мин бит сине биергә генә чакырган идем!» — дип гаҗәпләнде.

Луиза, аңа якынрак килеп: «Биергә генә чакырган идегез? Биергә генә чакырганнан шулай буламы?» — дип, күз төбен, борынын, күлмәк төймәләрен ычкындырып тәнендәге каралып чыккан урыннарны күрсәтте.

Кыз бар җирләрен дә күрсәтеп бетергәч, юан бәндә янына якынрак килде:

— Сез мине биергә чакырмадыгыз, сез мине көчли башладыгыз. Ә үзегезнең кызларыгызны шулай эшләтсәләр, нишләр идегез икән? Кабахәт! — дип, уңлап-суллап, тегенең яңагына сугып җибәрде. — Ә хәзер, егетләр, Бауман районының милиция начальнигы исеменә гариза язабыз. Ул бүген мине көчләсә, иртәгә бүтән кызларны, берсекөнгә мәктәп яшендәге балаларны көчләр. Аны вакытында туктатырга кирәк. Бәхетең, абзый, бөтенләй көчли алмадың. Сиңа кимендә унбиш-егерме ел чәпиләр иде. Бәлкем, атып та үтергән булырлар иде. Ярар, әлегә сиңа көчләп азапланган өчен, дип бирелә торган сигез елы да җитеп торыр. Ну, ул сигез ел сиңа сиксән ел тәмугта утырган кебек булачак, — дип, кыз сумкасыннан дәфтәр белән ручка чыгарды. Бер бит кәгазьне тартып алып, гариза да яза башлады. Өстәл янына бинада булган бар халык җыелды. Хәтта кухня эшчеләренә кадәр чыккан иде. Кыз язып бетергәч: «Егетләр, кулларыгызны куегыз әле», — дип, Сашага авторучкасын сузды. Сашадан соң Шәрип, Света, аннан кыз үзе куйды. Луиза каршыда басып торган теге администратор хатынга: «Надежда Михайловна, сез бит ни кылынганын үз күзләрегез белән күрдегез, кулыгызны шаһит буларак куйсагыз, әйбәт булыр иде», — диде.

Администратор хатын өстәл янына килеп, милиционерлар белән исәнләште дә:

— Мин барысын да башыннан ахырына хәтле күрә алмадым, шулай да менә бу адәмнең шушы гүзәл туташны кулыннан сөйрәп маташканын күрдем. Шуны дәлилләп кулымны куям! — диде.

Өстәлләрнең берсендә утырган парлар да биредә иде әле, яшь кыз лейтенантка: «Бу кеше әллә нинди ямьсез сүзләр әйтте, — диде. — Кулын боргалады, сугып идәнгә екты. Вәхши. Ярый әле, шушы егетләр яклап калды. Кирәк булса, без шаһитлар булып барабыз, шулай бит, Альберт?» — дип, егетенә карады. Тегесенең бу эшкә бер дә кысыласы килми иде бугай. Тагын берничә кеше кул куйгач, Луиза янә телгә килеп: «Егетләр, берәрегез машина белән түгелме, хәзер үк барып, экспертиза анализлары алырга кирәк», — диде.

Буксәле белән эш тагын өч сәгатькә сузылды. Ул, чыннан да, бер ПМК начальнигы иде. Ниһаять, бар да арып-талып милиция бүлегеннән чыктылар. Саша бөтенләй кызга гашыйк булып беткән иде. «Бу кыз теләгән илендә шпионка булып эшли ала. Җитмәсә, чибәр, акыллы, теләсә нинди авыр хәлдән җиңел чыга. Өстәвенә финанс-икътисад институтында укый икән», дип уйлады ул.

Урамга чыккач, бар да аптырап калды. Чөнки хәзер аерылыр вакыт та җиткән. Яңадан ресторанга кайту мәгънәсезлек булыр иде. Тик Александрның гына кыздан бер дә аерыласы килми. Аның бергә булу вакытын озайтасы килә. Шәрип, аның ни теләгәнен аңлап:

— Җәмәгать, әйдәгез әле, бу җиңүне Светаларга кайтып юабыз. Синең өйдә капкаларга берәр нәрсә бармы соң, булмаса, хәзер магазиннан алабыз. Рәхәтләнеп бер утырыйк әле, — диде.

— Мин бик утырыр идем дә, өйдә әйтелмәгән бит, — диде Луиза.

— Ә өегездә телефон юкмыни? — дип сорады Света.

Кыз:

— Бар да, ничектер минем соңга калып кайткан юк шул, белмим инде, нишләргә дә, — дип туктап калды.

— Луиза, ышаныгыз миңа, сезгә беркем бармак белән дә кагылмаячак. Кагылсалар, минем мәет аша гына. Әти-әниләрегезгә үзем иртәгә исән-сау илтеп тапшырырга сүз бирәм, — дип, Света кызга өмет белән карады.

— Яхшы алайса, мин синең сүзеңә ышанам, хәзер берәр якындагы телефоннан шалтыратып, өйдәгеләрне генә тынычландырып киләм, — дип, кыз елмаеп китеп барды.

Төнге сәгать икеләр булгандыр, ишек кыңгыравы шалтырады. Света барып ачса, анда теге бәйләнчек абзый басып тора иде. Кулында роза чәчәкләре. Конфет тартмасы һәм кыйммәтле коньяк тоткан. Башта өйдәгеләр аны күреп аптырап калсалар да, абзыйның, зинһар, бер ун-унбиш минут кына сөйләшеп алыйк инде, дигән ялварулы тавышы аның ни өчен килгәнен ачыклады. Ул эшне җайларга дип кергән иде. Бар да абзыйга юл бирделәр. Өстәл янына утыргач, абзый телгә килде:

— Зинһар, бүгенге өчен гафу итегез инде. Әллә ничек җүләрләнеп кителгән. Ахры, начар аракы эләккәндер инде. Шул харап итә, зараза. Әйдәгез әле, шушында гына бетерик эшне, милиция белән сөйләшүне мин үз өстемә алам. Сез үзегезгә зыян китергән сумманы әйтегез дә, эш бетә.

— Элегрәк нәрсә уйладыгыз соң сез, без бит сезнең авызыгызга көчләп аракы коймадык, — диде Луиза. — Аннан килеп, сезне мыскыл да итмәдек. Ә сез безнең күңелләребезгә мәңге төзәлмәс яра салдыгыз. Күпме нервылар бетте!

— Сеңлем, мин барысын да аңлыйм. Әйдәгез инде, төпле бер сумманы әйтегез дә, сез мине, мин сезне белмим. Чөнки өйдә хатын, буй җиткән ике кыз, карт анай бар. Алар алдында оят! Өстәвенә эшләгән җирдә ни әйтерләр?!

— Соң инде, абый. Сез мине нык рәнҗеттегез. Мин үземне бернинди акчага да мыскыл иттертмим, — дип, Луиза чәчәк букетын алып абзыйның кулына тоттырды. Өстәлнең икенче башында утырган Шәрип: «Нишләп кылана инде бу кыз, бер биш миллион каерып калырга менә дигән мөмкинлек бар, ә ул кәҗәләнгән булып маташа. Ну, җүләр дә инде бу хатын-кыз. Бу абзыйны утыртып ни файда инде? Ә монда акча кирәргә тора...» — дип уйлады.

Абзый торып басты:

— Зинһар, харап итмә инде, кызым. Мине утыртып ни файда инде сиңа? — Аның күз яшьләре тама башлады.

— Абзый, мине елап кызгандыра алмыйсыз, миңа сез кызганыч түгел, миңа сезнең гаиләгез генә жәл. Яхшы, сезнеңчә булсын, сез иртәгә иртүк миңа утыз миллион китерәсез. Шуннан мин гаризамны кире алам. Менә үзегез сайлагыз. Йә сигез ел утырып чыгасыз, йә утыз миллион.

— Утыз миллион?! — Абзыйның авызы зур булып ачылды. Ул бу хәлендә бугазына әйбер тыгылып, сулый алмый торган бульдогка охшап калган иде. — Ул кадәр акчаны каян алыйм соң мин?

— Анысы сезнең эш, абзый. Кеше мыскыл иткәнче, башта күпме акчаң бар икәнне санарга кирәк иде сезгә. Ә хәзер сау булыгыз, — дип, кыз аңа конфет тартмасы белән коньяк шешәсен тоттырды. Абзый кеше, бар әйберен кочаклап, чыгу юлына атлады. Өйдәгеләр кызның шулай оста эш итүенә сокланып торалар иде. Шәрип, эчтән: «Бу мин уйлаганча гади кыз булып чыкмады, бу көчле кыз бит, елки-палки. Саша моның колына әйләнергә мөмкин. Менә сиңа мә! Мин биш миллион алуны күп дип торам, ә ул утыз миллион каерды, яңа машина бәясе! Елки-палки!» — дип уйлады.

Абзый, ишек төбендә туктап:

— Соң, иртәнге унга кадәр каян җыеп бетерим мин ул кадәр акчаны?! — дип, үзен озатучыларга карап катты.

— Абзый, сиңа аңлаттылар бит инде, әйберләрегезне сатыгыз, дусларыгыздан алып торыгыз, анысы сезнең проблема! — диде Света.

— Минем ике ел гына йөргән «Нива» машинасы бар, — дип тукталды абзый. — Бөтенләй йөрелмәгән, мин эш машинасы белән йөрим. Унике мең километр гына үткән, 1994 елгы. Буявы да купмаган. Бәлкем, акча урынына шуны гына алырсыз. Зинһар, үтенеп сорыйм.

— Менә болай, алайса, хөрмәтле әфәнде, иртәгә иртүк без

бөтенебез Үзәк ГАИда очрашабыз, — диде Луиза. — Сез машинагызны минем исемгә күчерәсез, шуңа өстәп тагын ике миллион да вәссәлам! Менә шул! Үзегезгә карагыз!

Абзый башына күсәк белән сукканнан соң аңына килеп бетмәгән кешегә охшап калган иде. Ул риза булып чыгып китте. Икенче көнне абзый аларны ГАИ бинасы янында көтеп тора иде инде, үзе белән ике шаһит та алып килгән. Алар алыш-биреш беткәнне дәлилләячәкләр икән.

Шулай итеп, Луиза тик торганнан гына машиналы булды да куйды. Соңрак, ике миллионны да кесәсенә салып куйгач, егетләргә күз кысып елмайды. Саша аңа карап туя алмый иде. «Их, шушы матур, зәңгәр, тирән күзләренә кереп чумасы иде дә, бөтен дөньяларны онытасы иде», — дип уйлады ул.

Саша Луизаны иртән укырга илтә, кич алып кайтып куя иде. Кыз аны тулысынча сихерләде дә куйды. Егетнең бөтен уе чибәр туташта иде. Ләкин кесәдәге акчаның көннән-көн кимүе генә егетне борчуга салды. Өстәвенә кызның тиздән җәйге каникуллары башлана. Аның белән диңгез буенда ял итеп кайтырга уйлаган иде ул.

Луиза, һич уйламаганча, тыйнак кыз булып чыкты. Алар айдан артык очрашып йөрсәләр дә, егетне бик якын җибәрмәде. Бергә кочаклашып, үбешеп йокласалар да, шуннан артыгы булмады. Егет аңа берничә мәртәбә тәкъдим ясаса да, кыз аны тиз туктатты.

— Саша, мин сиңа әйтеп куям, өйләнешмичә андый нәрсә булмаячак. Әгәр тагын шундый ниятең була икән, без күрешмәячәкбез.

Кызның үзен шулай тотышы бәясен тагын да күтәрде. Ниһаять, ул кызга үзенең өйләнергә теләгәнен белгертте. Луиза аңа сынап карап торды да:

— Мин каршы түгел, Саша, тик мин — студент, син беркайда да эшләмисең, ничек яшәрбез икән соң без? — дип сорады. — Аннан, мин сездә яшәргә җыенмыйм. Чөнки анда әниеңнең тынычлыгын аласым килми. Яшьләр белән өлкәннәр барыбер тыныша алмаячакларын беләсең ич. Шуңа күрә кияүгә чыксам, мин үземнең картлардан да, синекеләрдән дә аерым яшәячәкмен. Ничек инде шулай яшәп булсын: бергә аша, бергә йокла. Ваннага чират көт. Кеше күрмәсен дип, киенеп йөр. Юк, алай булмый ул. Минем үзем теләгәнне ашыйсым, үзем теләгәнчә йоклыйсым килә, — дип, сүзен бетерде.

Егет аңа:

— Булыр, аерым йортыбыз да булыр, акчабыз да җитәрлек булыр, — дип ышандырды.

Шәрип кенә көннән-көн тузына башлады:

— Ташла инде шул мәткәңне, бөтен вакытың шуңа китә. Берәр эш эшләп алырга кирәк.

— Соң, безнең Луиза белән мөнәсәбәтләр җитди, — дип карышты Саша. — Без өйләнешергә җыенабыз.

— Хисләр җитди дип инде, көне-төне аңа тагылып йөрмәсәң дә була. Бөтенләй башыңны югалтып барасың ич. Котың очкан икән, ташлап качар дип уйлыйсыңмы әллә?

— Минем кем белән йөрүемдә сезнең ни эшегез бар?! Инде хәзер Света белән икәү миңа ничек яшәргә икәнен генә өйрәтәсегез калды. Акыл сатканчы, ничек акча эшләү юлын эзләр идең. Теге күп акчалы эшең дә ишетелми. Буламы соң инде ул, юкмы? Шул эш булыр дип, башкаларына тотынган да юк, — дип дулады Саша.

— Менә шул турыда сөйләшү була да инде бүген, шуны әйтергә килү. Сукыр бер тиен акчабыз калмады, ә син мәткәләр артыннан чабасың, шулай булмый ич инде!

— Шәрип, мин сиңа соңгы тапкыр әйтәм, мәткә түгел ул, аңлыйсыңмы, минем булачак хәләл җефетем, — дип, Саша сикереп үк торды.

— Хет әллә кем булсын, башта эш, аннары хәләл җефетләр. Бүген әйттем бит инде мин сиңа, кичке сәгать сигездә «Казан утлары» ресторанында заказчылар белән очрашу була. Сигез тулганда шунда очрашабыз. Пока, — дип, Шәрип чыгып китте. Саша үзе генә калды. Ул, бүген кич Луизаны озатып куйгач, туры очрашуга барырга ниятләде.

Кич белән Шәрип аны көтеп тора иде, Сашаны күргәч: «Әйдә, тизрәк, алар көтәләр. Син бик кызып китә күрмә, яхшылап сөйләш. Акчаны алу мәсьәләсен дә конкретно куй!» — диде.

Тегеләр кеше әз булган урында утыралар иде. Икесе дә кара күзлектән. Берсенең иренендә иске яра эзе сызылып калган. Кул бирешеп күрешкәч, егетләргә урын тәкъдим иттеләр. Күзлеклеләрнең берсе Шәриптән:

— Безнең күрешәсе кеше шушыдыр бит инде? — дип сорады.

— Әйе, сүзне башласак та була, — диде Шәрип.

Күзлеклеләрнең икенчесе:

— Егетләр, эшнең нидән торганын яңадан аңлатып тормыйм, аны сез үзегез дә беләсез инде. Куркыныч эш! Ни өчен сезгә тәкъдим ителүен дә аңлатам, сезнең әле органнарның күзенә чалынганыгыз юк. Бу плюс! Шуңа күрә сездән шикләнмәячәкләр, аңлашылдымы?! Эш бик җитди, хәлегез җитәрлек булмаса, хәзер үк кире кагыгыз! — диде.

— Аңлыйм, алайса, бу эшкә бик җентекләп, ныклап әзерләнергә кирәк икән. Тагын шунысы бар, без сезнең белән алышбирешне ничек ясыйбыз соң? Без башта акчаны алып, соңыннан эшне башкарырга риза. Ышанмыйсыз икән, контрольдә тота аласыз! — дип, Шәрип сүзгә кушылды.

— Яхшы, шефка җиткерербез. Иртәгә җавап көтегез!

Шул вакыт каяндыр тегеләрнең өченче кешесе пәйда бул-

ды. Ул, иелеп, ярык иренлегә: «Китәргә кирәк, аста тегеләрнең кешесе күренде. Безнең монда икәнне белгән, ахры», — диде. Ярык ирен: «Безнең монда бергә утырганны ул күрергә тиеш түгел, югыйсә сез дә күзәтү астына алынасыз. Шуңа күрә без киттек.

Шәрипләргә: «Иртәгә кичке алтыда сезне алырга машина киләчәк, көтегез», — дип, тиз-тиз атлап чыгып китте. Аңа башкалары да иярде. Заказчылар чыгып киткәч, Шәрип:

— Йә, ни уйлыйсың? — дип сорады.

Саша:

— Берни дә уйламыйм, башта акча, аннары эш, — дип җавап бирде.

Икенче көнне алар артыннан икмәк ташу машинасы килде. Саша кабинага гына утырырга җыена иде, шофер аңа: «Икегез дә будкага утырасыз, сез кая барганыгызны белергә тиеш түгел. Миңа шундый приказ булды», — дип, будка ишеген ачты. Алар менеп утыруга, ишек ябылып, караңгылык чорнап алды. Тышта шоферның ишекне йозакка бикләгәне ишетелде.

Машина ярты сәгатьләп баргач, ниндидер зур склад кебек җиргә кереп туктады. Шофер егетләргә юл күрсәткәч, алар баскычтан аска таба төшеп киттеләр. Төшеп җиткәч, тирә-ягында ишекләр белән тулган озын коридор күренде. Бер ишек яныннан үткәндә, эчтә кешеләр тавышы, штанга тимерләре шалтыраган тавышлар килде. Димәк, монда спорт залы да бар. Икенче бер бүлмәдә кемнедер азаплыйлар, ахры: «Әйтәсеңме, юкмы, падло, әйтәсеңме, диләр сиңа», — дип, кемнеңдер кычкырганы ишетелә иде. Егетләрнең эченә бераз шом керде. Кая эләктек икән без, дип уйлыйлар иде алар. Ниһаять, каршыда коридор бетеп, тимер ишек күренде. Аларны көтеп торганнар бугай, базык кына гәүдәле, кыска чәчле, киң җилкәле берәү, ишекне ачып, эчкә үткәрде. Бүлмә уртасында озын өстәл тора. Түрдәге креслода берәү утыра, аның кырыенда тагын икәү басып тора иде. Егетләр аның берсен танып алдылар. Ул, әлеге дә баягы, кичә ресторанда күрешкән кешеләрнең берсе булып чыкты. Креслода утырган бәндә егетләргә: «Утырыгыз, дуслар, — дип, урын тәкъдим итте. — Эшләр болайрак, егетләр. Бик җитди эш. Без акчадан тормаячакбыз, тик барысын да җиренә җиткереп эшләргә кирәк булачак. Хаталар кичерелмәячәк! Акчаны без сезгә шул көнне операция алдыннан бирәбез. Тик качарга уйлап та карамагыз, сезне күзәтәчәкләр. Әгәр дә койрыкны борырга уйлыйсыз икән, үзегезгә үпкәләгез», — диде. Шул вакыт каршыдагы пәрдә ачылып китте, анда бер кеше ике ботын ике якка каерып, башы белән аска каратып асылган иде. Егетләр шулай да үзләренә бу күренешнең начар тәэсир иткәнен сиздермәскә тырыштылар. Пәрдә кире ябылды. Креслода утырган кеше:

— Хәзер сезгә кирәкле клиентны күрсәтәбез, игътибар белән карагыз! — дигәч, залда ут сүнеп, ян стенада экран кабынды.

Экранда башта зур итеп салынган коттеджның ишегалдында котырынып өргән ике зур овчарка, аннан баскычта бозау хәтле дог белән басып торучы хуҗа кеше күренде. «Карап калыгыз, «объект» шушы булыр», — дип куйды креслода утырган адәм. Аннан «объект»ның «джип»ка шкаф кебек ике тән сакчысы белән утырып китүен күрсәттеләр. Сашага бу кеше таныш кебек иде. Кая күргәнем бар соң минем моны, дип исенә төшереп азапланса да, булмады. Соңыннан клиентның дачасы белән таныштылар. Фильм бетте. Ут кабынды. Өстәл артындагы адәм: «Менә шулай, егетләр. Хәзер сезгә клиентның адресын һәм вак-төяк чыгымнарга ике миллион акча бирерләр. Өч атнадан кабат күрешәбез, сезнең шул арада төгәл планыгыз булырга тиеш», — дип сүзен бетерде. Егетләрне ничек алып килсәләр, шулай илтеп тә куйдылар. Ничек кенә баш ватсалар да, алар кая барганнарын, нинди җирдә булганнарын чамалый алмадылар.

Эшкә әзерлек икенче көнне үк башланды. Башта ике көн буена клиентның өен күзәттеләр. Керү-чыгу юллары өйрәнелде. Башкарыласы эш шактый катлаулы иде. Ерак түгел генә милиция участогы. Үзе һәрвакыт тән сакчылары белән йөри. Машинага шартлаткыч куеп булмый, шофер аннан бер дә аерылмый. Өстәвенә урамда кеше күп йөри. Күреп калулары шиксез. Коттеджны өч көн күзәттеләр. Ике котырган эт, бөтен җирдә сигнализация, тирә-якта төзү эшләре күп бара. Шулай итеп, иң кулай урын дача булып чыкты. Аңа бер яктан гына машина белән кереп булса, калган якларында су иде. Клиентның бакчасы су буеннан йөз адым. Димәк, машинаны яр буенда калдырып, моторлы көймә белән керергә туры киләчәк. Хәзер клиентның дачасына кайчан килә, кайчан китәсен генә ачыклыйсы калды. Беренче тапкыр ул анда атна уртасында, чәршәмбе көнне күренде. Үзе белән бер ир кеше, тагын ике яшь хатын-кыз да бар иде. Икенче атнада нәкъ шул ук көнне тагын, тик икенче кунаклар белән. Нәкъ элеккечә мунча кереп, шашлык ашап, катерда йөреп, иртән генә кайтып киттеләр. Димәк, бакчасына ул төгәл чәршәмбе көнне килә!

## КРАН КЫСЫЛГАЧ

Группировканың эше 1995 елның язына кадәр яхшы барды. Алар зур бер химкомбинатны кул асларында тоталар иде. Шуңа өстәп алар зонасына кергән яшелчә базалары, төзү-монтаж идарәләре, тагын күп кенә шуңа охшашлы учреждениеләр булса да, алар комбинат биргән табышның меңнән берен дә бирмәделәр. Ә комбинат исә бөтен БДБ илләренә берме, икеме

генә икән. Аның җитештергән продукциясенә сорау зур булып, чит илләрдә дә кызыксыну арта барды. Ә продукциянең күп өлеше группировка егетләре ачкан кече предприятие аша китә иде. Алар комбинаттан әзер чималны түбән бәягә алып, тагын үз процентларын да өстәп саталар. Өстәвенә бернинди исәп-хисапка кермәгән урланган продукция чиста керем китерә. Эшләр шәп бара иде. Дөрес, баштарак бу учреждениенең эшенә каршы төшеп маташучылар да, комбинатның табышын үзенә ала, бу аның бөлүенә китерә, диючеләр булгалады. Тик аларның авызларын тиз томаладылар. Сез үзгәртеп коруга каршы, дип, кайсын куркыту, кайсын кыйнау, кайсына бераз акча төртү дә җитте. Имеш-мимешләргә караганда, кайбер үҗәтрәкләре арасында якты дөнья белән саубуллашканнары да булган, диләр.

Кече предприятие, кече саналса да, зур-зур коттеджлар, фатирлар сатып алырга, салырга, чит ил машиналарында йөрергә мөмкинлекләр ачты. Аның җитәкче даирәләре чын үзгәртеп коруның җылы җилләрен тойдылар. Алар бар да Мәскәү түрәләре төзегән демократияне хуплады. Бу демократия чын Рәсәйнеке иде. Урларга бөтен мөмкинлекләр бирелде. Кем нәрсә булдыра ала, шуның хәтле урлады. Ә гомере буе химкомбинатта эшләп бөкреләрен чыгарган кешеләр тагын да хәерчеләнә барды. Яңа оешма комбинатның бар продукциясен үзе аша үткәрә барып, бәяләрне күтәргәннән-күтәрде. Бәя күтәрелгән саен, алучы кимеде. Алучы кимегән саен, комбинатның хәле мөшкелләнде. Комбинат гомере буе үзендә эшләгән кешеләрен административ ялга, лаеклы ялга, кыскартып эштән җибәрә башлады. Иң алдынгы эшчеләр, инженерлар китте. Фабрика продукциясенә исә сорау элеккечә зур иде. Ә теге предприятиенең җавабы бер генә, кирәк булса — ал, кирәкмәсә юк! Чөнки яңа коммерсантларга кергән табыш җырлап яшәргә болай да җитә. Аларга җитсә, комбинатның кереме исә хезмәт хакы түләргә дә, налоглар, уты-суы һәм башка шундый нәрсәләрне капларга да җитмәде. Кайбер цехлар ябылды, продукция элеккегә караганда 10 мәртәбә кимрәк җитештерелә башлады.

Тик һәрнәрсәгә чик булган кебек, кече предприятиенең дә хәле начарланды. Комбинатның эше бармавын хөкүмәт җитәкчеләре дә төшенде. Чөнки республикага валюта китерүче комбинат бөлеп бара, зыянга эшли иде. Озакламый аның генераль директорын эштән алдылар.

Яңа директор кече предприятиене бөтенләй үк япмаса да, чимал бәясен комбинатка файдалы итеп куйды. Урлап өйрәнгән хезмәткәрләрне шундук куды. Төп урыннарга ышанычлы үз кешеләрен утыртып, группировка кешеләреннән азат итте. Шулай итеп, кыска гына вакытта химкомбинатка җан керә башлады, кече предприятиенең сулышы кысылды. Алар шок хәлендә иделәр. Эшләми генә балда-майда йөзәргә өйрәнеп кит-

кән «үткен егетләр» өчен бу хәл түзеп тормаслык нәрсә иде. Чөнки кулларыннан миллиардлар китә. Тора-бара яңа хуҗага басым ясап карасалар да, тегенең җавабы бер генә, күрә торып комбинатны таркаттырмаячакмын, әгәр дә сезнең эшлекле тәкъдимнәр бар икән, рәхим итегез, тыңлыйм сезне, дип кире бора барды. Өстәвенә Эчке эшләр министрлыгында дуслары күп булу да комачаулады.

Яңа генеральный ярты ел да эшләмәгәндер, кече предприятиенең комбинатка бернәрсәгә дә кирәге калмады, ул зыян гына китерә, дип таркатырга карар бирде. Бу хәл инде тегеләрне бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Шулай да соңгы тапкыр директор белән сөйләшеп карарга булдылар. Башта ул егетләрне кешем күп, дип кабул итмәде, соңыннан, шулай да күрешкәч, егетләр, мин сезгә аңлаттым бит инде, тагын нәрсә кирәк, бу бит сезгә «проходной двор» түгел дип, сүзен бетерде. Алар шунда комбинатның кулдан китеп баруын аңладылар. Әйе, яңа директор төпле утыра башлады. Аның башы шәп эшли иде. Ул орган кешеләре белән дус яши, республиканың гайрәтле мафия башлыклары белән дә элемтәне өзми. Чөнки бу эш аңа башкаларны куркытып тору өчен кирәк.

Оешма әгъзалары тиз генә киңәшмәгә җыелды. Ни эшләргә?! Кече предприятие ябылырга тора. Башта алар элек җыеп калган продукцияне комбинат бәясеннән түбәнрәккә сатарга кирәк дигән фикергә килделәр. Бусы тагын комбинат кесәсенә сугар өчен иде. Булган продукция өч ай сатарга җитәчәк. Ул арада директордан котылу юлларын эзләргә.

Тик яңа директор да йоклап ятмады, кече предприятие өстенә налог инспекциясен, полициясен җибәргәләп кенә торды. «Үткен егетләр»нең чыгымнары күбәйде. Алар бер тикшерүчеләрдән котылып өлгермиләр, икенчеләре килеп төшә. Бу эшләр ике арадагы дошманлыкны соңгы чиккә җиткерде. Директорны юк итәргә дигән карар кабул ителде. Ә бу эшне бөтенләй чит кешеләрдән эшләтү кирәк иде. Чөнки иң беренче аларны кулга алачаклар. Ә ул көнне өйдә утырудан да яхшысы юк. Менә шуннан соң очына чыгып карасыннар!

## ОПЕРАЦИЯ

Шәрип белән Саша, үз фикерләрен заказчыларга җиткергәч, тегеләр дә алар планын ошаттылар. Эш бетүгә, егетләргә республикадан чыгып китүләрен сорадылар. Һәм, Ходай Тәгалә үзе сакласын, йөзегезне беркем күреп калырга тиеш түгел, үзегез аңлыйсыз, бу сезгә кыйммәткә төшәчәк, дип кисәттеләр.

Икенче көнне Саша кара базардан оптик приборлы карабин сатып алды. Ул оста атучы булса да, эшне куркыныч астына куярга ярамаганлыкны аңлап, мылтыкның яхшысын, кыйм-

мәтлесен алды. Чөнки, бер атуда тидерә алмасаң, Алла сакласын... Кичен, шәһәрдән читкә китеп, тыныч урында карабинны сынап карады. Каршысына куйган буш шешә, шырпы тартмаларына аткан саен тидерүенә канәгать булып: «Әле синдә күкерт бетмәгән икән, Саша», — дип куйды.

Кич белән Шәрип килгәч, акчаны ничек алырга да, кая урнаштырырга икән, дип баш ваттылар. Светаны бу эшкә катнаштырмаска булдылар. Чөнки бер мәртәбә аның белән яна башлаганнар иде инде. Нишләргә? Бәлкем, берәр җиргә күмеп торыргадыр? Бу вариант та үтмәде. Берәрсе күреп калса, йә булмаса очраклы гына тапса, шуның хәтле акчадан колак кагып булмый ич инде. Шунда Саша Луизаны искә төшерде. Тик Шәрип каршы чыкты. Әле аны бер айлап та белмисең, аңа ышанасың, дип туктатты. Егетләр тагын бер сәгатьләп баш ваткач, барыбер шул Луиза вариантын сайладылар. Шәрипнең Чистое озеро ягында, инде күптән каралмаган булса да, дачасы бар иде. Кыз аларны үз машинасы белән барып, шунда көтеп тора. Акчаны Шәрип Сашага тапшыра. Ә ул, байлыкны туптуры бакчага илтеп, кызга калдыра. Шуннан кире кайтып, Сашалар янында күрешеп, төп эшкә китәләр. Заказчылар исә акчаның кая киткәнен сизми дә калачак.

...Саруханов Аркадий Николаевичның соңгы көннәрдә кәефе начар түгел иде. Эшләр яхшыга бара. Комбинат өчен мактадылар үзен. Акча буа буарлык. Оешмага паразит булып торган караклар көтүенә «кранны япты». Инде бөтенләй нокта куясы гына калган иде. Менә бүген шул турыда да сөйләшермен, яхшылап ял да итәрбез дип, берничә иптәше белән мәдәният институтында укып йөри торган өч кызны да чакырды. Директорның бер урынбасары иртүк бакчада мунча ягып, табын әзерли торырга китте. Башта кызлар белән мунча кереп чыгалар да, Казанка буйлап катерда чабачаклар. Яхшы яшәргә ярата Саруханов.

Кичкә таба аның бер шоферы теге кызларны алып килде. Саруханов кызларны яхшылап күзләп чыккач, зәңгәр күзле, матур гәүдәле, сөйкемле Тамараны ошатты. Бусы миңа булса, теге икесен Исаев белән Шапиро үзләре сайларлар әле. Башта кызлар белән беренче машина, арттан хуҗа белән тән сакчылары утырган «джип» кузгалды.

Алар килеп җиткәндә, сигезенче унбиш минутлар иде. Озак та үтмәде, кунаклар да күренде. Саруханов, үзенең урынбасарыннан мунчаның әзер икәнен белгәч, кунакларын чабынырга алып китте. Урынбасарының теләге булса да, аны мунчага чакырмадылар. Ул тагын рәнҗеп калды.

Гали Шәрәбәнович, 1964 елда Казанга килеп, техникум тәмамлагач, шушы химкомбинатта гомере буе эшләде. Үз көче белән урынбасар дәрәҗәсенә күтәрелде. Гомере буе, их, җүнләп урысча белсәм, мин әллә кем булачак идем, дип уйлый иде.

Шуңа күрә өйләнеп балалары булуга, хатыны Бибиҗамалны кисәтеп, өйдә урысча гына сөйләшә торган булдылар. Кайсы вакыт авылдан туганнары, яшьтәшләре килеп төшеп, аларның «чыктым аркылы күпер»ләр ясап, белмәгән сүзләрне татарча әйтеп сөйләшүләре килгәннәрне сәерсендерә иде. Кайбер акыллыраклары аларның шушы кыланмышларыннан әчтән көлеп китә торган булды. Болай урыс теленең танымаслыгын калдырып сөйләшкәнче, әйбәтләп кенә татарча гәпләшик дигәннәргә алар нык үпкәлиләр, икенче юлы алар белән күрешмәскә тырышалар иде. Ата белән ананың тырышлыгы бушка китмәде, балалар татарча бер сүз белмәсәләр белмәде, ну урысчаны тәтелдәп торалар иде инде. Бу грамоталарын онытмасыннар дип, каникулда аларны авылга да җибәрми иделәр, ә исә авылдан килгән туган-тумача балаларын, Гали Шәрәбәновичныкылар үртәп, мыскыл итәләр, «авыл бишмәтләре», «гыйбадлары», «бабайка» дип көләләр иде. Бу балаларның лексиконында шуннан ары татар сүзләре булмады. Дөрес, элегрәк мәктәптә үзләрен урыс балалары котыртып әйткән сүзләрнең мәгънәсен өлкәннәрдән кайтып сорыйлар иде. Шулай да аларны кешеләр яратмады. Туганнары, дуслары читләште. Гали Шәрәбәнович үзе исә бу хәлне аларның наданлыкларыннан, культурасызлыгыннан күрде. Минем нинди начарлык эшләгәнем бар инде аларга, дип уйлый иде. Бәхете булмады Гали Шәрәбәновичның. Яхшы булсын дип тырышты, урламады, җимермәде. Әллә нәрсә шунда. Гел киресе килә дә чыга. Инде үзгәртеп кору башлангач, бер җиргә начальник итеп тә куеп маташканнар иде, бер генә тел белә, урысча гына, дип, аның кандидатурасы төшеп калды. Ә ул урынга татарча, урысча, яһүдчә белгән Шарон Иван Львовичны үткәрделәр. Ә бит бу эшне аннан да яхшырак белүче юк иде. Ә балалары. Теге күршедәге итек басучы Сәләхинең егермегә җиткәнче җүнләп урысча белмәүче селәгәй малайларының берсе, очучылыкка укып чыгып, хәзер майор булды, икенчесе тарих фәннәре кандидаты. Ә авылдашларының кызмалайлары кайсы укытучы, кайсы табиб, берсе хәтта муллалыкка укып кайткан. Ә аныкылар кем?! Малае кая эләкте, шунда эчеп йөри. Кызы нindидер училищега кереп укып караган иде, хәзер ресторан-барларда гына сөйрәлә, йа Ходა. Әйтеп карасаң, чәтердәп: Не твое дело, папан, вы не хрена не понимаете, ладно, хватит, а, мамань, бросьте вы свои деревенские выходки» — дип кенә җибәрәләр. Гали Шәрәбәнович яшьләнгән күзләрен сөртеп алды. Йа Алла, дип куйды ул саф татар телендә.

Мунча эченнән кемнеңдер чәрелдәп көлгәне, себерке белән чабынган тавышлар ишетелде. Әнә кайсыдыр чыгып бассейнга чумды. Ул, өлгереп җиткән шашлыкларны алып, яңаларын мангалга куйды. Үзе куя, үзе уйлый иде. «Шунда үзләре белән утырырга чакырса була иде бит инде, хайван. Бу итләрне

кыздырырга тән сакчыларына да әйтә ала иде бит. Бер дә санга сукмый инде шакшы сионист. Инде табынын әзерлим, мунчасын ягам, кая кушса, шунда барам, миңа да бер студентка алып килеп ял иттергән булсалар, үлгән булырлар идеме? Дуңгыз!»

Шунда ишекне ачып кычкырган Саруханов тавышы килде: «Әй, Гали Шәрәбәнович, нәрсә анда, шашлык ни хәлдә, менә монда дамаларның ит ашыйсылары килгән, безгә берәр таяк китер әле, стакан астына», — дип, эчкә кереп китте. Шәрәбәнович, яхшырак итлеләрен сайлый башлады. Ояла да белми инде, хайван, бөтен нәрсәсен күрсәтеп чыгып баскан. Хет кешенеке кебек фигурасы булса иде. Бегемотныкы кебек корсак та, салам юанлыгы булып күренгән аяклар. Хет көзгедән карасын иде инде үзен. Ул, алты таяк шашлыкны тотып, мунчага атлады. Аннан нидер исенә төшереп, борылып, ишек төбендә утырган тән сакчысына: «Серега, итне карый тор әле, көймәсен, яме», — диде. Ярдәмче кергәндә кунакларның берсе анекдотмы, кызык хәлме сөйли иде. Бар да шырык-шырык көлә. Сарухановның алдында теге зәңгәр күзле сукасы утырган. Ул, кызның матур имиләренә кызыгып, төкерекләрен йотып куйды. «Нәрсә терәлеп каттың, Гали Шәрәбәнович, әллә Тамараның «пирамидалары» ошадымы?» — дигәч, бар да шаркылдап көлә башлады. Бу сүз бигрәк тә зәңгәр күзле сучкага ошады, ахры. Ул: «Ой, не могу, ой, не могу» , — дип хихылдый иде. Замга бу көлү ошамаса да, ул да көлгәнди итте, үзе: «Ничек инде ошамасын, Аркадий Николаевич, шундый матур әйбер ошамыймыни инде», — дип, авызын ерды. Ул үзенчә, мин дә ир кеше бит, хатын-кыз миңа да чит нәрсә түгел, дип әйтәсе килгән иде.Теге зәңгәр күзгә имиләре матур дигән нәрсә ошады, ахры, күзләрен тутырып замга карап алды. Аның бу карашы: «Син начальник булсаң, мин сиңа да бирер идем. Ну, әлегә син зам гына», — дия иде кебек.

Шулай да Гали Шәрәбәновичның хуҗасына ачуы чыкты, эчтән, әйдә, көлеп кал инде, мыскыл ит, кылан, бер синнән дә көлгән чаклар булыр әле, дип уйлады. Саруханов, Тамараны алдыннан торгызып, стаканнарга аракы өстәп чыкты да, Шәрәбәновичның басып торуын күреп: «Гали Шәрәбәнович, сез Серега белән Аликка әйтегез әле, катерга моторын куя торсыннар», — диде. Ул, яхшы, дип чыгып китте. Аның үзенә шундый мөнәсәбәттән җен ачуы чыкты. Эчтән, бик ачуны чыгарсаң, ташлап кайтып китәрмен әле, козел, дип куйды. Эчтәгеләр шаркылдап көлеп җибәрделәр. Замга бу үзеннән көлгән кебек тәэсир итте. Итләрне боргалап маташкан Серега янына килеп җиткәч, хуҗа катерны әзерләргә кушты, хәзер чыгалар, диде. Теге әзмәвер ике таяк шашлыкны алды да, ярар, дип, өйгә юнәлде. Шәрәбәнович сорамыйча ит алган тән сакчысына ачуы ки-

леп, сорап кына да ала белми бит, аңгыра, дип куйды. Бераздан, өйдән көймә моторы күтәреп чыгып, Алик белән Серега су буена төшеп киттеләр. Инде караңгы төшеп килә. Бер унбиш минуттан тән сакчылары кире кайтты. Серега, яңадан мангал янына килеп, өлгергән өч таякны алгач, Гали Шәрәбәновичның түземлеге бетте, кая аласың инде тагын, кунакларга җитмәсә, дип авызын ачкан иде, теге борылып: «Да пошел ты...» — дип китеп барды. Инде тән сакчыларына кадәр мыскыл итә, тәмам симерүләре җитте. Йа Хода, җыен ясалып җитмәгән малай санламасын инде үзеңне.

Мунчадан, Саруханов белән кочаклашып, Тамара килеп чыкты. Кыз аның барган җирдән ими төймәләрен үбә. Зам, ничек инде шушы корсаклы сыерның, җирәнгеч хайванның имиләрен яларга була, хет бераз матурлыгы булса иде, дип уйлады. Мунчадан башка кунаклар да чыкты. Хуҗа шашлык ашап утырган Серегадан: «Нәрсә, катер әзерме?» — дип сорады. Тегенең, әйе, дигән җавабын ишеткәч: «Киттек, дуслар, бер су кереп кайтыйк әле», — дип, алга атлады.

...Саша яраткан кызы белән озак тарткалашты. Луизаның бер дә алар эшенә кысыласы килми иде.

— Зинһар, мине акча эшләрегезгә кыстырмагыз әле, Аллам сакласын, дөрес чыкмаса, — дип карышып маташты.

Егет:

— Ну, зинһар өчен, бер генә мәртәбә тыңла инде, — дип ялынды. — Ул бит синең белән минем өчен дә кирәк. Анда безгә рәхәтләнеп яшәрлек сумма, әгәр мине яратсаң, тыңла инде.

Кыз, ниһаять, соңгы мәртәбә, киләчәктә мине үз эшләреңә кыстырма, дип риза булды, егетнең муеныннан кочаклап алып, иреннәреннән үпте.

— Син мине ташламассың бит, Сашок, — дигәч, егет:

— Мин сине үлеп яратам, Луиза, мин сине беркайчан да ташламам, — дип, кызны каты итеп күкрәгенә кысты, аннан, кызның күзләренә карап, — мин кайтырмын, көт мине, — диде.

Луизаның күзләреннән яшь атылып чыкты.

— Мин көтәрмен сине, Саша, — дип пышылдады аның иреннәре.

Акчаны алып, дачага озату әллә ни авыр булмады. Шәрип, йортның арткы ягына чыгып, Сашага акчаны тапшырды, купюраларның чынлыгына ышангач: «Ярый, мин теге якка чыгам, югыйсә койрыктагылар сагынганнардыр инде», — дип китеп барды. Саша да кузгалды. Шәрип машинасы янына чыкты, теге арттан ияреп йөри торган ак «Волга» үз урынында иде. Шәрип ашыгырга уйламады. Сигарет кабызып, аны озак кына итеп тартты, багажниктан гәҗит чыгарып укып алгач кына кузгалып китте. ЦУМ янындагы ресторанга кереп капкалап чыккач,

кибетләр карап йөрде. Тагын ике сәгатьтән алар Саша белән күрештеләр. Хәзер төп эшне генә үтисе бар иде. Сәгать көндезге ике. Саша диван астыннан фанер тартма тартып чыгарды. Анда теге карабин иде. Элек әзерләп куелган, чаңгыда йөри торган баш киеменнән ясалган масканы да сумкага салдылар. Ярты сәгатьтән бар нәрсә дә әзер иде. Ике егет чыгып әйберләрне урнаштыргач, машина үкереп кузгалып китте.

Мылтык аткан тавыш бөтен Казанка буен яңгыратты. Саруханов Аркадий Николаевичка балык тоткан булып көймәдән аттылар. Тимер ядрә аның нәкъ йөрәгенә эләкте.

Эш эшләнүгә, көймәдәгеләр тиз генә моторны кабызып китеп тә бардылар. Югалып калган тән сакчылары, аңнарына килеп, пистолетларыннан качып баручыларга ут ачсалар да, үтерүчеләр ерагайганнан-ерагая бардылар. Канга баткан Саруханов янында теге кызлар елаша, ике зур кунак та югалып калган иде.

Саша мылтыгын суга ташлады, кесәсендәге запас патроннар да мылтык артыннан су төбенә киттеләр. Сарухановның сакчылары катерны суга этеп төшергәндә, качучылар еракта бер нокта кебек кенә күренәләр иде. Шулай да көчле моторлы катер аны куып җитәргә тиеш. Катерны кабызып, ике йөз метр узмадылар, аңа су тула башлады, идән өстендә яткан резина коврикны күтәреп карасалар, анда дүрт тишек ыржаеп тора иде. Катер кирегә борылды.

Качак көймә камышлар арасына килеп керде. Шунда әзерләнеп куелган лом белән двигательне алгач, Саша, ашыга-ашыга, көймәне тишкәләргә тотынды. Аны кире этеп кертеп ломы белән бергә суга батыргач, кабат мотор янына килеп, аны ике ягыннан тотып сөйрәп алып киттеләр. Өч йөз метрлап чапкач, сазлык башланды. Ике егет, чайкап, кулындагы йөкләрен сазлык эченә томырдылар. Тимер батып күздән югалгач, тизрәк ычкыныйк бу тирәдән дип, машина калган якка чаптылар.

Тагын ярты сәгатьтән «девятка» Казан урамына килеп керде. Каршыга сирена кычкыртып килүче ике «Жигули» очрады. Теге хәл булган урынга ашыгучылар иде, ахры.

## ВӨҖДАН БОРЧУЫ

Майор Гәрәевнең күңеле тыныч түгел, вөҗданы борчый. Фаяз Гыймранович үтерелгәнгә берничә ай үтсә дә, җинаятьчеләр табылмады. Дөресен генә әйткәндә, аларны юньләп эзләүче дә юк иде. Шушы хәл аны бик борчый. Алар бер-берсе белән шактый дус яшәделәр. Үләренә бер атна кала Фаяз аңа нидер әйтеп маташкан иде бит. Ә аның әллә ни исе китмәде. Нинди эш ачу турында сораган иде соң әле ул?! Кемгә ачарга кирәк диде? Ниндидер Света дигән хатын исемен телгә алды

түгелме?! Каршы йортта торалар, диде. Миша! Әйе, әйе, Миша диде бугай! Юкка чыктымы, үтерделәр дидеме?! Тукта, монда ябышыр әйбер бар түгелме соң?! Хәзер шул Миша аша, бәлкем, үтерүчеләрнең эзенә төшеп булыр. Фаязны шул Миша эшендә казынуы өчен юкка чыгарган булулары мөмкин. Хәзер шул кешене эзләргә кирәк.

Икенче көнне ул формасыз гына Фаяз торган йортка китте. Ике биш катлы «хрущевка» капма-каршы тора. Алар арасында каен, тополь агачлары үсә. Майор балалар уйный торган мәйданчык янындагы эскәмиягә килеп утырды. Анда бер әби оныгын уйната. Гәрәев, бераз утыргач, әбигә:

— Монда минем бер танышым тора иде, кайсы фатирда икәнен оныттым, исеме Миша, сез аны белмисезме, әби? — дип, кечкенә малайның тәгәрәп киткән тубын алып бирде.

— Кайсысы булыр икән соң инде ул? — дип сүз башлады әби. — Алар икәү бит, берсе аның институтта укый, әнә теге подъездда тора, аннан менә дүртенче подъездда бар иде берәү, инде күптән күренми, йә төрмәдә, йә бәреп үтергәннәрдер инде анысын. Җыен килде-китте шунда җыелып ятты. Үткән елны менә тегендә эленгән керемне урлап саттылар, муены астына килгерләре. Шул Миша эше генә инде ул. Хәзер, Аллага шөкер, җыелмыйлар, шул түгелдер ич Миша дигәнең? Хатыны Света атлы...

— Юк, ул да булып чыкмады, аның хатынының исеме Света түгел шул, ахры, мин йортларның номерын бутаганмын, — дип, майор урыныннан торып, әбигә рәхмәт әйтеп китеп барды. Әйе, бу шул, Фаяз әйткән фатир булып чыкты. «Фаяз, мин сине үтерүчеләрнең эзенә төшә башладым. Алла боерса, алар тиешлесен алачаклар! Шуның өчен мин барысын да эшләячәкмен!» — дип уйлады ул. Аның бераз күңеле күтәрелеп китте.

Икенче көнне ул, яңадан килеп, теге йортны күзәтте. Тагын берничә көннән Светаны да, Шәрип белән Сашаны да таный башлады. Тик аларны кулга алырга иртәрәк әле, ябышыр әйбер кирәк иде. Югыйсә уңайсыз хәлдә калуыңны көт тә тор! Соңрак яңа кеше — Луиза пәйда булды. Әлегә күзгә ташланырлык эш күренми. Көннәрнең берсендә егетләр кинәт уянып киткән кебек булдылар, хәрәкәтләре тизләнде. Болар нидер эшләргә җыеналар, дип уйлады майор.

Саруханов үтерелгән көнне, ул, җинаятьчеләргә ияреп килеп, аларны яр буеннан күзәтте. Егетләр көймә белән дачалар ягына кереп киткәч, ул машинасы белән дачалар зонасына керде, «Жигули»ын бер кырыйга куеп, камышлар арасыннан көймә торган җиргә якынлашты. Тегеләр балык тоткан булып утыралар. Эшнең ни белән бетәчәген ул башына да китерми иде. Мылтык тавышы яңгырап, хатын-кызлар чәрелдәшә башлагач кына эшнең нидә икәнен аңлады. Тән сакчылары ата башлагач,

ул камышлар арасына ныграк иелде, чөнки күрсәләр, бандитларның берсе, дип аңа да ата башлаулары бар иде бит. Ул, кача-поса юлга чыгып, Казанга ашыкты. Үтерүчеләрнең кемнәр икәнлеген белсә дә, үтерелүче аның өчен билгеле түгел иде әле.

Шәрипнең «девятка»сы Чистое озеро ягына ашыкты. Тизрәк акчаларны алырга да сызарга кирәк. Акчаларны запас көпчәккә тутырырга булдылар. Егерме биш чакрымлап киткәч, аларны ГАИ белән ОМОН туктатып тикшерде. Шикләнер нәрсә күренмәгәч, аларны җибәрделәр. Димәк, алар эшләгән эш бөтен җиргә хәбәр ителгән.

Сашаның уенда бары тик Луиза гына. Тизрәк Белоруссиягә барып җитеп, фатир алырга да, кызны чакыртырга. Ул ансыз бер генә минут та тора алмый. Соңыннан ял итәргә Кырымга алып барыр. Кыз каникулын аның белән шунда үткәрәчәк, ике ай бергә булачаклар. Бәлкем, ул арада бу эшләр тынып калыр. Ул кызны күз алдына китерде. Аның матур елмаюларын, ап-ак вак тешләрен, зәңгәр күзләрен күрде. Чәчләреннән сыйпады. Ничек итеп диңгездә коенганнарын уйлады. Менә кояшта кызынып яталар. Ул матур итеп комга сузылып яткан кызга йөзем җимешләре каптыра. Аннан аквалангистлар маскасы киеп, су астындагы табигатьнең матурлыгын күзәтәләр. Анда төрле-төрле диңгез балыклары, ташка ябышкан моллюсклар, зонтик кебек медузалар күренә... Аның исенә тагын Кырым, Симеиз поселогындагы Дева кыясы төште. Кызны шул кыя башына алып менәчәк. Каршыда иксез-чиксез диңгез җәелгән. Яр буенда урнашкан берәр, икешәр, өчәр катлы йортлар җиләк-җимеш агачларына күмелеп утыралар. Алар арасыннан тауга таба таш баскычлар сузылган. Ә иң өстә, түбәләрен ап-ак кар каплаган таулар. Кызның әле мондый гүзәллекне төшендә дә күргәне юктыр. Кырым татарлары пешергән, авыз суларын китерерлек чебуреки ашап, яр буйлап йөрерләр. Нинди чибәр кызны эләктергән бу дип, үткән-барган көнләшеп калачак. Ә берәр көнне алар Ялтага барып кайтырлар, тау трамваена утырып өскә күтәрелерләр. Аннан, күренмәсә, Төркия генә күренмидер! Икенче көнне — Севастопольгә экскурсиягә. Аның күз алдына хәрби корабльләр, диңгез бухталары килде. Тау сыртында үсеп утырган кып-кызыл җимешле кизил куаклары...

— Кая соң синең подругаң, ул машинасы белән калды, дигән идең ич. Кая соң монда машина? — дип, Шәрип аны татлы хыялларыннан аерды.

Саша әле үзенең хисләреннән айнып бетмичә: «Нәрсә, килеп тә җиттекмени?» — дип сорады. «Килеп җитүен җиттек, кая соң синең Луизаң?! Тәрәзәдә ут та юк», — дип, Шәрип Сашага карады. Саша, машинадан төшеп, өйгә йөгерде, кереп утны кабызды. Кыз бүлмәдә юк иде. Икенче катка менсәләр

дә — беркем юк. Кыздан җилләр искән. Кая, язып калдырмадымы икән дип, кәгазь кисәге дә эзләделәр, юк! Акча да бер җирдән чыкмады. Нәрсә соң бу?! «Кая соң акчалар, кая теге сукаң? Мин синнән сорыйм, падло? Нәрсә, мине икәүләп шудырмакчы идегезме, барып чыкмас. Мин буш кесә белән калыр өчен кеше үтердеммени, әйт, мин синнән сорыйм, кая акчалар?!» — дип үкерде Шәрип.

Саша бөтенләй югалып калды. Ул берни аңлый алмас булды. Кая китәргә мөмкин соң ул? Бәлкем, заказчылар күзәтеп йөреп, аны алып киткәннәрдер? Хәзер аларны каян табарга?! Нишләргә? Аның күз алдына теге ярык иренле бәндә килде. Рестораннан чыгып барганда Ярык ирен официантка, хәлләр ничек, Әсхәт, дигәч, тегесе, Аллага шөкер, Кощей, дигән иде. Кощей, димәк, кушаматы шулай. Теге Әсхәт аша эзләп табарга кирәк!

— Кая теге проституткаң дим мин сиңа, тварь вонючий, кая акчалар, гад?! Мин сиңа әйтәм, миңа үземнең өлешне бирегез дә чәнчелеп китегез!

Ул, куен кесәсеннән финка чыгарып, Сашага килә башлады. Саша артка чигенә-чигенә:

— Син нәрсә, әллә ычкындыңмы, ал пычагыңны дим. Әгәр сине шудырырга теләсәм, мин монда килеп тормас идем, — дип, Шәрипнең финкалы кулына карады.

— Юк, козел, син мине шудыра алмассың, исән китмисең, хайван, мин сине хәзер шушы пычак белән стенага эләм дә, теге сукаңны эзләп табам. Мин аның бот арасына шушы финканы, авызыннан чыкканчы тыгачакмын! — дип, Шәрип Сашага якынайды. Шәрип китереп кадаганда, ул, әз генә кырыйга тайпылып, тегенең өстенә өстәлне әйләндереп каплады. Шәрип, янга чыгып калып, Сашаның өстенә килә башлады. Чигенүче Сашаны стена туктатты. Качарга юл калмады. Һөҗүм итүче пычагы белән бар көченә кизәнеп тагын кадамакчы булды, ләкин Саша янә сакланып өлгерде, финка стенага кадалды. Ул, шуны гына көткән кебек, Шәрипнең эченә китереп типте, сөйрәп алып башы белән ике тапкыр стенага бәргәч, теге идәнгә ауды. Хәнҗәрне тартып чыгарып кесәсенә тыккач, урамга йөгереп чыкты да «девятка»сына утырып, шәһәргә чапты. Аны хәзер акча да ул кадәр борчымый иде. Луизаны табып коткарырга кирәк. Аның күз алдына тагын теге подвалдагы бәндәләр килеп басты. Анда аяклары каерылып бәйләнгән Луиза. Теге Ярык ирен кызның күлмәген ертып төшергәч, кыз үзенең күкрәкләрен капламакчы була, ләкин куллары бәйләнгән, зинһар, тимәгез миңа, тимәгез, дип ялвара. Бандитларның башлыклары: «Нәрсә, безнең акчаларны алып Белоруссиягә сызмакчы идегезме, тиз генә баемакчы идегез, ә, эзегезне яшереп маташтыгызмы, бездән качып котылып булмаганны аңламадыгызмы,

сука?» — дия кебек иде. Луизаның ярдәм сорап кычкырганы, Саша, коткар мине моннан, зинһар, коткар, дип ялварганы күз алдына килде. Теге ярык ирен торып, ә-ә, әле сиңа Саша кирәкме дип, китереп суккач, кызны өчәүләп көчли үк башларлар. Егет, тешләрен шытырдатып кысып, газга басты. «Үтерәм!» — дип кычкырды ул.

Күктә кояш чыгып, таң атып килә иде.

Майор Гәрәев, соң булуга да карамастан, эшенә китте. Ул ике сәгатькә соңга калды. Анда аны ачуыннан күгәреп чыккан начальнигы каршы алды.

— Кая йөрисең соң син, бөтенләй санламый башладыгыз, анагызны шулай итимнәр. Хет әйтеп китәргә буладыр иде бит. Тагын безнең районда ЧП, заказной үтерү. Химкомбинат директорын олактырганнар. Министр котыра. Җинаятьчеләр табылмый. Әгәр тапмасагыз, бөтенегезне эштән куам, ди. Анасын гына сатыйм инде, тагын минем башка. Берсе артыннан икенчесе килә дә тора бит.

— Иптәш подполковник, әгәр үтерүчеләрне тапсам, нишлисез? Мин аларны беләм!

— Беләсең?! Ничек?

Майор бар белгәнен сөйләп бирде. Ул сөйләгән саен подполковникның йөзе яктыра башлады.

— Ну, Гәрәев, әгәр бу хәлләрең дөрес булса, билләһи, бүләккә тәкъдим итәм үзеңне! Молодец! Коткардың син мине. Киңәшеп эшләсәң дә була иде бит. Димәк, Фаязны үтерүчеләр дә билгеле. Ике җинаять бергә ачыла. Шәп бит бу. Тукта, министрга хәбәр итим әле, югыйсә тереләй ашый ул мине.

Озак та үтмәде, бөтен шәһәр оперативниклары җинаятьчеләрне эзләргә кереште. Бөтен җиргә фоторәсемнәр таратылды.

Соңрак подполковник Гәрәевны яңадан үз бүлмәсенә чакыртып:

— Илдус туган, Фаяз эшен без икәү алып бардык, дип әйтик әле, аннан сиңа зыян килми ич инде. Ә мин сиңа орден алырга булышырмын, — диде.

— Ә миңа барыбер, иптәш подполковник, минем өчен иң мөһиме: Фаязны үтерүчеләрнең табылуы. Ниһаять, аның алдында вөҗданым чиста, — дип, сүзен бетерде Гәрәев.

Подполковник торып майорның кулын кысты. Шунда телефон шалтырады. Ул министр иде. «Яхшы, иптәш генерал. Исән килеш алырга тырышачакбыз. Тыңлыйм! Рәхмәт!» — дигәч, подполковник трубканы куйды.

— Тере килеш кулга алырга тырышыгыз, ди. Карале, Илдус, син бу эшне үз кулыңа ал әле. Үзең башлагансың икән инде, ноктасын да үзең куй. Эшнең ничек барышын миңа хәбәр иткәләп тор. Ярый, уңышлар сиңа!

## САША СӨЙГӘНЕН ТАБА

Җинаятьчеләрне төнлә таба алмадылар. Оперативниклар Саша белән Шәрипнең өйләрендә булдылар. Гәрәев үзе машина белән Светаларга юл тотты. Сәгать иртәнге алты. Кыңгырау биргәч, майор белән килгән спецназ егетләре ишек кыреена качтылар. Эчтән хатын-кыз тавышы ишетелгәч, Гәрәев: «Ачыгыз, бу милиция!» — дип кычкырды. Берничә минуттан бишалты айлык көмәне күренеп торган Света ханым ишекне ачты. Аның куркудан йөзе агарган иде. Спецназ егетләре, пистолетларын әзер килеш тотып, бүлмәләрне тикшереп чыктылар. Майор хатыннан энесе белән аның иптәшенең биредә соңгы тапкыр кайчан булуларын сорады. Хатын аңа, бер өч көн бардыр инде күренмәгәннәренә, диде.

Иртәнге гәҗитләрдә җинаятьчеләрнең сурәтләре басылган иде.

Ярык иренле:

—Тәки ментлар күзенә чалынмыйча гына эшләрен эшли алмадылар. Бик тиз генә табып, юкка чыгарырга кирәк үзләрен. Ментлар кулына эләксәләр, анда ничек телләрен ачарга беләләр. Николь, тиз бул, кешеләреңне алып эзләргә чыгып кит, аңладыңмы?! Табуга юк итегез, патрон жәлләмәгез, югыйсә барыбызга да начар булачак, — диде.

Әсхәтне урамга чакыртып алдылар. Анда аны Саша көтеп тора иде. Ул егетне белмәгәнгә салышты. Саша, аның ни уйлаганын аңлап:

— Мин — Кощейдан, — диде.

— Ә, аңладым, хәзер. Югыйсә аптырап калдым, кем икән соң бу, дип. Нәрсә, кичкә өстәл хәстәрләргәме әллә?

— Юк! Ул сине үзе көтеп тора, үзенә генә әйтәсе йомыш бар иде, — диде. — Үзенең эшләре күп, килә алмады.

— Соң, мин эштә бит, тукта, хет берәрсенә әйтеп китим, — дип, Әсхәт кереп китте. Озак та тормады, кире чыкты.

Саша аңа:

— Рульгә үзең утыр әле, кичә бик каты салынган, — диде.

— Кая барабыз соң? — дип сорады Әсхәт.

— Элек кая бара идең соң, шунда.

— Аңлашылды, подвалга, алайса. Шеф үзе дә андамы соң?

— Юк, мин чыгып киткәндә килмәгән иде әле...

— Нишләптер мин сине элек күргәнем булмады, хәтерләмим.

— Әле минем чыкканга да бер генә атна, — дип ялганлады Саша.

— Ә, Кощейның сөйләгәне бар иде шул, тиздән шәп бер малай кайта, дип. Серый дигән иде бугай, шул мәллә син, брат, — дип, Әсхәт Сашага дусларча елмайды.

— Нәкъ үзе.

Машина чапты да чапты. Менә ниндидер заводлар тезелеп кала башлады. Ниһаять, машина зур бер тимер капка янына килеп туктады. Саша официантның башына алдан хәзерләп куелган зур ачкыч белән бар көченә сукты, теге креслога җәелде. Ачкычны ташлагач, койма кырые буйлап керергә җайлырак урын эзләп китте. Унбиш-егерме метрлап баргач, бетон стенада кеше сыярлык тишек күренде. Саша, башын тыгып, кеше-мазар юклыгына ышангач кына эчкә үтте. Тирә-якта иске машиналар, ниндидер тимер-томыр өемнәре, аларны, бәлкем, металлоломга тапшырырга җыенган булганнардыр. Хуҗалыкның эчкерәк өлешендә зур гараж күренде. Аның кырыенда да машина кабиналары, «КамАЗ» арбалары өелгән. Кайчандыр монда эш кайнап торганы сизелә. Тирә-юньдә кеше заты күренмәгәч, егет сак кына зур гаражга таба атлады. Гаражның ишеге ачык иде. Эчтә җан иясе юк. Саша үзенең подвалга төшкән ишеген танып, шуның кырыена килеп поскач, аста берәр тавыш ишетелмиме дип тыңлап карады. Тавыш-мазар килмәгәч, аяк очларына гына басып, аска төшә башлады. Коридордагы сакчыга юлыккач, кесәсеннән финка чыгарып, аның аркасына кадады. Саша, сакчының гәүдәсен артык тавыш чыкмасын өчен тотыбрак идәнгә салды да, пистолетын алып, Луизаны эзләвен дәвам итте.

Николь үзенең егетләре белән Шәрипне эзләп тапканда, ярты көн үткән иде. Башта шәһәр буйлап йөреп чыктылар, теге егет табылмагач, дачага барып карарга булдылар. Һәм дөрес эшләделәр. Шәрип шунда ята иде. Авызы-борыны яньчелгән, тик шулай да исән. Егетләр аны рәхәтләнеп типкәләгәчтен, караватка бәйләп өстенә бер канистр бензин сибеп, ут төрттеләр. Алар кайтып киткәндә, дача йорты дөрләп яна калды. Аннан Шәрипнең үлем ачысы белән кычкырган тавышы ишетелә иде.

Саша коридор буйлап баруын дәвам итте. Аның юлына бүтән кеше чалынмады. Менә теге көнне Ярык ирен кереп киткән соңгы ишек. Бәлки, Луизаны шунда саклый торганнардыр. Ул, сак кына килеп, ишек аша бүлмә эчен тыңлады. Анда кемнәрнеңдер барлыгы сизелә. Саша, нишләргә икән, дип уйлады. Ничәү булырлар икән? Ул стенадагы кечкенә тәрәзәне күрде. Урындыкка басып тәрәзәдән күз салса, караватта ике кеше ятканын күрде. Аның берсе — Ярык ирен булса, икенчесе — Луиза иде.

Луиза белән Ярык ирен инде бишенче ел бер-берсен беләләр. Ярык ирен, ягъни Сәлим, аны киендереп, акчасын биреп торучы спонсоры иде. Кызны ул кирәк чакта, берәр файдалырак кеше килеп чыкса, шулар астына сала һәм кыз үз ролен зур осталык белән башкара иде. Бу кыз аркасында ул шактый

гына зур түрәләр белән танышып, күп кенә авырлыклардан котылып килде.

Сәлим генеральныйны үз юлларыннан алып ыргытыр өчен дә Шәрип белән Сашаны сайлады. Чөнки бу ике егетнең ул профессиональ үтерүчеләр түгел, ә гади фатир караклары икәнен белә иде. Профессионаллар белән андый уен уйнап булмаганны аңлаганга, ул бу егетләрне сайлады. Икенчедән, аңа чит илгә китәргә акча кирәк булганга, гонорарны зур итеп билгеләде. Ә егетләрне һәрчак контрольдә тотар өчен уенга Луизаны кертеп җибәрде. Аның бөтен нияте үз кешеләре алдында чиста булып күренү, шул ук вакытта 500 миллионны эләктереп, Луиза белән Кушма Штатларга китү иде. Хәзер аның монда бер генә эшне — Шәрип белән Сашаның теге дөньяга олактылармы-юкмы икәнен генә ачыклыйсы калды. Ул Никольның кайтканын көткән арада, кызып китеп, Луиза белән ял итеп алырга уйлады.

Саша үзенең бу дөньяда берни тормаганын шушы мизгелдә генә аңлап алды. Ничек итеп оста алдадылар аны. Ул үзенең сәрхуш мәрхүм әтисе белән холыксыз әнисен каргады. Чөнки алар аркасында ул шушы көнгә калды. Алар биргән тәрбиясезлек аркасында ул җинаятьче булды. Чөнки бүтән эш эшли алырга аңа оеткы салынмаган иде. Ул кечкенәдән үзенә тиешен урлап йә булмаса талап алырга гына өйрәнде. Сашаның йөрәге китереп кысты, ул тешләрен кысып, сыгылып төште. Бераз хәле рәтләнгәч, урыныннан торып, ишеккә юнәлде. Килеп керүгә, ул аптырап калган Ярык иреннең башына бер патрон җибәрде. Аннан: «Мә, сука, ал үзеңнекен», — дип, Луизага атты.

Канга баткан кызга якын килеп:

— Нәрсә җитмәде соң сиңа, сука, мин бит сине ярата идем! — диде.

— Ә мин сине беркайчан да яратмадым, мин синнән җирәнәм, Саша, — диде Луиза һәм җан бирде.

Саша, акчаны табарга кирәк тизрәк, кая куйдылар икән, дип уйлап, өстәл янына килде. Анда яткан гәҗиткә игътибар итте, аның беренче битендә Шәрип белән үзенең рәсеме төшерелгән иде. Ул сискәнеп китте. Аннан өстәл астын, тумбочканы карады, ә акчалы сумка шкаф эченнән табылды. Ул сумканы ачты, акчалар өстендә ике паспорт ята иде. Берсен ачып карагач, Луиза фоторәсемен күрде. Тик исеме генә Фәридә дип язылган иде. Чит илгә сызар өчен ялган паспортлар да әзер булган боларның, дип уйлады ул.

Саша акча сумкасын тапкач, Сәлимнең кесәләрен актарып чыкты. Аннан револьвер тапкач, чалбарына кыстырып, чыгар юлга чапты. Өскә генә менеп җиткән иде, машина туктаган тавыш ишетелде. Револьверны кулына тотып, Саша гараж поч-

магына посты. Менә ишектән берәү күренде. Ату тавышы яңгырады, теге кеше барып төште. Саша чабып урамга чыкты, килгән ягына бармакчы иде, пистолет тоткан берәү каршыга төште, Саша аңа атып җибәрсә дә тидерә алмады һәм борылып бетон болгаткыч станция ягына чаба башлады. Аның артыннан Николь белән теге кеше куа иде. Ул тиз генә, барыр җир калмаганлыктан, чабып бетон болгаткыч станциясенең баскычыннан менде. Борылып куа баручыларның берсенә атса да тидерә алмады. Аңа акча сумкасы белән еш-еш сулыш алуы комачаулый иде. Өскә менеп җиткәч, ул сумкасын куеп, тегеләрнең берсенә төзәп атып җибәрде. Дошманы чабып килгән җиреннән тәгәрәп китеп егылды. Икенчесенә төбәп тәтегә баскан иде, револьвер атмады, патроннары беткән иде. Ул борылып качар урын эзли башлады. Шулчак тимер ядрә аның аягына эләкте. Саша авыртудан акырып җибәрде. Икенче пуля уң як күкрәгән тишеп чыкты, Саша бетон болгаткыч казанына барып төште. Николь аның казанга төшеп киткәнен күргәч, чабып килеп болгаткычны җибәрде. Казан эчендә Сашаның гәүдәсе, сөякләре шатыр-шотыр килеп, кисәкләргә турала иде. Аның күз алдына соңгы мизгелдә сугышта суелган яшь молдаван хатыны, аның канга баткан балалары күз алдына килде...

Николь чабып менеп сумканы ачып карады да, ябып, аска төште. Тиз-тиз атлап гаражга китте. Ул каты яралы шефы белән Луиза мәетенә тап булды. Сәлимнең башына пуля тигән. Ул, Никольны күргәч: «Тизрәк «скорый» чакырт, тизрәк», — дип кычкырды. Николь, аның башына аткач, урамга ыргылды.

Майор Гәрәев автохуҗалыкка килеп җиткәндә, мәетләргә генә тап булды. Ул алар арасыннан Шәрип белән Сашаны эзләсә дә таба алмады. Дөрес, берничә көннән дачада янып үлгән кешенең Шәрип икәнен ачыкладылар. Ә менә бетон болгаткычтагы ит кисәкләренең кемнеке икәнен тәгаен генә беркем дә әйтә алмады. Шулай да бу шул Александр Владимирович булырга тиеш дип фараз кылдылар.

Гали Шәрәбәновичны чакыртып сөйләшсәләр дә, директор итеп куймадылар. Моны исә инде, сезгә пенсиягә дә ике генә ел калган, дип аңлаттылар. Аның инде бернәрсәгә дә күңеле ятмый иде.

Химкомбинатка генераль директор итеп Петр Аранович Шпакны куйдылар. Аңа әле яңа гына кырык биш яшь тулган иде.

Светаны ирен үтерүдә катнашканлыкта гаепләп, алты елга хөкем иттеләр. Аның баласы төрмәдә туды. Тик бала өч яшь тулганда да йөреп китә алмады, Света шунда гына сабыеның гарип икәнен аңлады.

*Повестьлар*

# КАНГА БУЯЛГАН АЛТЫННАР



# I

Кече лейтенант Симаков кыска гына буйлы, очланып килгән башы гәүдәсенә караганда зуррак күренә. Кечкенә чепи күзләре арасына урнашкан очлы, озын борыны күзгә ташлана. Ул авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, кече лейтенант дәрәҗәсендә Совет Армиясендә хезмәт итә башлады. Һәр кыска буйлы адәмнең иң зур теләге зур үсү булган кебек, аның да үсәсе килә. Тик буйга үсү чорлары үткән, бары тик хәрби дәрәҗәсе генә үсәргә мөмкин. Ул аны бар кешегә караганда да яхшырак аңлый. Шуңа күрә хәленнән килгәннең барысын да эшләргә тырыша. Өлкән офицерларга ярарга тырышса, солдатларны үзенең дәрәҗәсеннән файдаланып изде. Бу хәлләр өчен солдатлар аны күрә алмасалар, офицерлар да бик өнәп бетермәделәр. Чөнки Симаков алар турында да комбатка төрле сүзләр җиткереп торды.

Ни генә кылмады, кыланмады. Актив та булды, тактик та булды ул. Кайбер вакыт көче җитмәслек эшләргә алынып, кызык хәлләргә калгалады. Соңгы мәртәбә ул менә мондый «мөгез» чыгарды. Бу «мөгез» соңрак аның тормышында зур үзгәрешләр китереп чыгарырга сәбәпче булды. Ә эш исә бөтенләй юктан башланды...

Совет Армиясе көненә Симаков Владимир Иванович футбол уены оештырырга уйлады. Оештырды да. Гади уен гына түгел, солдатлар белән офицерлар ярышы.

Баштарак бу эшкә комбат каршы төшеп маташса да, Симаковның: «Бер дә кайгырмагыз, иптәш подполковник, сез капка тирәсендә генә йөргәләгез. Без сезгә гел пас биреп, торырбыз. Ант итеп әйтәм, бер-ике туп кертмичә калмассыз», — дигәч, инде соңгы мәртәбә кайчан футбол уйнаганын да оныткан комбат риза булды.

Володя төне буе йоклый алмый хыялланып чыкты. Ничек ул тупны эләктереп ала, теге маңка солдатларны алдап, әле уңга, әле сулга алып китә. Шыр мыскылга калдырып солдатлар капкасына бер-бер артлы туп кертә. Комбатка пас биреп аңа да берне керттерә. Ну үсәчәк инде аның абруе. Бәлкем, озаклямый взвод командиры итеп тә куяр. Кем белә?..

Икенче көнне көндезге 12 дә футбол уены башланды. Стадионда бар батальон җыелган. Бер якта — солдатлар, икенче, каршы якта — гәүдә ныклыкларын югалта башлаган офицер-

лар командасы. Дөресен генә әйткәндә, арада үз гәүдәсенең кыяфәтен саклаган Симаковның үзе белән прапорщик Ослов кына иде.

Иң кызыгы алдарак икән... Уен башланды. Башта офицерлар, җитез егетләр сымак чапкаласалар да, ике-өч минуттан сулышлары кысыла башлады. Беренче булып олы корсаклы майор Гаврилов барып төште. Ул мәйданда японнарның милли уены булган соами көрәшчесен хәтерләтә иде. Озак та үтмәде, Паливани дигән грузин егете шапылдатып туп кертеп куйгач, Симаков:

— Кайгырмагыз, кайгырма, барысы да әйбәт булачак, — дип, офицерларны тынычландырырга тырышты. Уен дәвам итте, майор Гаврилов тагын бер мәртәбә барып төшеп, сыны катып яткач, көчкә үрмәләп торып, футбол карарга килгән солдатларның чын күңелдән көлүләренә гарьләнеп: «Пошли вы к черту!» — дип чыгып китте.

Тиздән Алик исемле азәрбайҗан, Фәрит исемле татар егетләре тагын берәр тупны керткәч, Симаков та акылына килде килүен, тик соң иде. Ни генә булмасын, түзәргә! Уңга чапты, сулга, чәбәләнеп җиргә барып төшкәләде. Сикереп торып тагын чапты. Үзе бертуктаусыз акырды. Комбатка да үзенчә көч бирергә теләп:

— Давай, давай, иптәш комбат, бирешмәгез! — дип көлгән итте. Ә тегесе исә, болай да чаба алмыйча, бер урында селкенеп тора. Симаковның чәрелдәвен үзенчә аңлап, ачуыннан бүртенеп чыкты.

Беренче тайм 27:0 исәбе белән солдатлар файдасына тәмамланса, икенчесенә офицерлар бөтенләй чыкмады. Солдатларның мондый кәмитне беркайда да күргәннәре юк иде. Әле булып үткән тамашаны оныта алмыйча, тәгәри-тәгәри көлдәләр. Бигрәк тә арада Хәсип исемле озын гына, таза гәүдәле татар малае уздырды. Эчләрен тота-тота, акыра-акыра көлде. Хәсипне болай да җене сөймәгән кече лейтенант шартлар дәрәҗәгә җитеп: «Үзенең юньләп русчасы да юк, ә ничек көлә бит миннән татарчук, ну, кәҗә маеңны чыгарам әле», — дип әйтеп куйды.

Кичке аштан соң Симаков комбатның күңелен күрү турында уйлады. Озак баш ватканнан соң, бер яртыны кыстырды да тәвәккәлләде. Ул килеп кергәндә, подполковник ике аягын үлән суына тыгып җылытып утыра иде, Симаковны күргәч, бәбәкләренә хәтле акаеп чыкты, шулай да дәшмәде. Симаковның:

— Иптәш командир, зинһар, үпкәләмәгез инде, — диюенә, подполковник, ачуланып:

— Иптәш кече лейтенант, бу комедия сезгә нигә кирәк иде, ә?! Ничек итеп солдатлар алдында оятка калдырдыгыз! Кем сез шулкадәр?! Ә?! Әйтмәгән саен! Үзең кепкаң белән бер метр! Ә үзең!..

Симаковның борын очлары тирләп чыкты.

— Зинһар, кичерегез, иптәш командир, кичерегез! Кем уйлаган шулай килеп чыгар дип.

— Беләсеңме моның өчен нәрсә эшләтергә кирәк? Сине армиядән куарга! Совет офицеры исеменә тап төшергәнең өчен, трибуналга!

Симаков, бөтен кыюлыгын җыеп:

— Командир, теләсәң нишләт, менә бу яртыны гына эчик тә мин китәм, калганы — сезнең эш!

Кече лейтенант ике стакан алып килеп, аракы салгач, берсен комбатка сузды. Тегесе биргәнне кире кага белмәгәнгә «хым» дип тамак кырды да эчеп тә куйды.

— Һәм шунысын исеңдә тот! Бүтән андый җүләрлекләр эшләмә! Югыйсә гомерең буе лейтенант булып калачаксың!

Симаковны урамга чыккачтын да комбатның шатыр-шытыр кыяр кимергән авызыннан чыккан «кече лейтенант, кече лейтенант, кепкаң белән бер метр» дигән сүзләре башын түгләды. Аның йөрәге әрнеде. Әле моның кадәр мескен хәлгә төшкәне булмаганга, гарьлегеннән елый-елый, караңгы урам буйлап каядыр атлады. Ул бар дөньяга нәфрәтле иде. Бар кешедән үч аласы килде. Тик аның кемгә генә хәле җитә ала соң?! Менә аның күз алдына шаркылдап көлгән рядовой Габдуллин килеп басты. Ул ачудан тешләрен кысып шыгырдатты. Аларның бер-берләрен сөймәүләре элек-электән булса, бүген Хәсипнең мыскыллы көлүе бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Менә бөтен үчне кемнән алырга була. Вонючий Чыңгыз хан оныгыннан...

Менә 1677 нче мотоукчылар частеның казармалары. Ул эчкә узды. Яңа гына отбой булган. Тирә-якны карап барганда, Хәсипнең бер иптәше белән шахмат уйнап утырганы күзгә чалынды. Ниһаять, бәйләнергә сәбәп бар. Тиз генә килеп шахмат тактасын тибеп җибәргәч, фигуралар шалтырап төрле якка чәчелде.

— Иптәш сугышчылар, әллә сезгә отбой булмадымы, әллә сезнең өчен башка законнармы?! Анагызны шулай итим!

— Минем әнине шулай итәргә буегыз кыскарак шул, иптәш лейтенант, шуңа күрә әнигә кагылмагыз!

Бу сүзләр Симаковның яңагына китереп сукканнан болайрак яңгырады.

— Сез, сез, — диеп, ул тотлыга ук башлады, — маңка малай, совет офицерына! Мин сезне! Сез, сез беләсезме, минем үз авырлыгымда бокс буенча спорт мастеры икәнемне.

— Мин аны яхшы күрдем футбол кырында. Тупны да груша белән бутадыгыз, ахры.

Бусы инде бөтенләй түзеп торырлык түгел иде. Симаков ярсып кычкырып җибәрде. Нидер эшләргә кирәк. Югыйсә бө-

тен батальон аннан тагын көләчәк. Кечкенә булса да төш кенә дип әйттерергә кирәк! Тик ничек?

— Смирно! Мин сиңа әйтәм, рядовой Габдуллин! Смирно! Ә хәзер минем арттан! Мин сиңа хәзер өйрәтәм, кышлагыңа кайткач, өлкәннәр белән ничек итеп сөйләшергә кирәк икәнен. Минем арттан!

Симаковка ияреп, Хәсип казармадан чыгып китте. Габдуллин белән шахмат уйнап утырган Әхмәтов, әрәм булды малай, дип кайгырса да, ярый әле, үзем җиңел генә котылдым, дип, эчтән шатланып та куйды. Әкрен генә йоклаган булып яткан солдатлар да торып утыра башлады. Пылин дигән Казан егете:

— Ну, Хәсипнең канын эчәчәк инде бу. Дембельгә кадәр көн күрсәтмәячәк. — Шулай диде дә сикереп торып: — Тукта, барып карыйм әле, тегендә ниләр бар икән? — дип, Симаковлар артыннан китте.

Тавыш канцеляриедән килә иде. Анда Симаковның котырып акырган тавышы ишетелә:

— Син беләсеңме, басурманин, синең кебекләрне мин нишләтәм?! Минем уң кулдан әле торган кеше юк, бәлкем, татып карыйсың киләдер, ә?!

— Беренчедән, мин мөселман, аннан сез Мөхәммәт Алиның кече туганы икәнсез, аннан кулыгыз да кычытып торгач, сугып карагыз.

Симаков 14 яшьлек чагында ике-өч ай бокс белән, чыннан да, шөгыльләнеп караган иде. Аның бүтән юлы калмады, хәзер ул ничегрәк итеп катырак сугарга икән, дип уйлады. Менә ул уң кулы белән селтәнеп җибәрде. Шуннан соң ни булганын хәтерләми. Әйтерсең лә аның өстенә ниндидер авыр әйбер төшерделәр. Ул үзен тотып калырга теләде. Тик аңын югалтуы сәбәпле гәүдәсен тотып кала алмады, гөрселдәп идәнгә егылды. Ни эшләгәнен хәзер генә аңлый башлаган Хәсип тә бер мәлгә югалып калды. Тик эш эшләнгән иде инде. Аның бите кызарып, борын очларына тир бөртекләре бәреп чыкты. Ул борылып канцеляриедән, аннан казармадан ук чыгып китте. Бу хәлләрне ачкыч тишегеннән күзәтеп торган Пылин тиз генә казармага ашыкты.

— Ну, егетләр, әле генә мин шундый нәрсәләр күрдем, сөйләсәм, кеше ышанмас. Дневальный да күрде. Беләсезме нәрсә, Симаков Хәсипкә сукмакчы иде, өлгерә алмый калды. Хәсип бер генә бирде. Чәчелде дә китте теге. Ул әле һаман канцелярие идәнендә ята.

— Ялганлыйсың! Булмас ла?! Ул бит үзен спорт мастеры диде...

— Белмим, нәрсә мастерыдыр. Ышанмасагыз, әнә үзегез барып карагыз! Ей богу, менә ант итәм! — Ул чукынып алды. — Ну, татарин шәп суга!

Шунда сүзгә Әхмәтов та кушылды:

— Сугуын суга. Хәзер бит аны дисбатка олактырачаклар.

Тик бу юрауларның берсе дә чынга ашмады. Хәсипне дисбатка да, хәтта гауптвахтага да озатмадылар. Чөнки комбатның тагын бер йолдыз алырга йөргән чагы. Әгәр дә берәр ЧП булса, беттең. Эшне тиз генә йомдылар. Башта Симаковны эт итеп сүктеләр. Кече лейтенант үзенең бик озакка, бәлкем, гомере буе «кече» булып калачагына шунда тәгаен ышанды. Ә Хәсипне исә башка частька күчерү чарасын күрделәр. Шулай итеп, бер елга якын хезмәт иткән Хәсипне якташларыннан, дусларыннан аерып, бөтенләй чит-ят булган җиргә озаттылар. Бу ике кеше — солдат белән иң түбән дәрәҗәле офицер берберсен күрә алмас булып аерылды.

## II

Автоколонна перевалга килеп керде. Барысы тугыз «КамАЗ» һәм унсигез солдат. Колонна башындагы «КамАЗ»да — прапорщик Бойков. Бу машиналарда Союздан килгән азыктөлек, ягулык һәм шартлаткычлар. Болай барысы да әйбәт бара, тик Бойковның йөрәгенә унсигез солдатның ундүрте яңа килгән «яшелләр» булуы тынычлык бирми. Ул эчтән генә әче итеп сүгенеп куйды. «Шушындый эшкә яп-яңа килгән малайларны җибәрсеннәр инде! Бер генә дә уйлап карамыйлар. Имеш, чыныгу алсыннар. Их, аналарын шулай итим. Аларга җиңел, начальник булып өйрәтеп ятарга. Ә монда бернинди сугышүлем күрмәгән бала-чага...» — дип уйлады ул. Көн кызу. Минут саен су эчеп торырга туры килә. Борын тишекләрендә, авызда — ком. Сулыш алуы кыен. Әфган даласының рәхимсез кояшы җелекләрне киптерә...

Менә, ниһаять, иң куркыныч, иң кыен арага килеп керделәр. Бойков рация аша: «Көтелмәгән һөҗүмгә әзер булыгыз! Куркыныч участок», — дип хәбәр салды.

— Йа Ходаем, үзең сакла!

Ул инде биредә өченче ел. Нинди генә газаплар, нинди генә авырлыклар күрмәде ул шушы чорда. Шуның билгесе буларак, күкрәгендә Кызыл Йолдыз, Кызыл Байрак ордены һәм берничә медаль ялтырый.

Вакыт-вакыт ул машина барган көйгә шушы рәхимсез кызулыктан әлсерәп, мәлҗерәп китә. Күз алдына Семферопольдә калган Оксанасы, кечкенә кызы Олечкасы килә. Кызының: «Әти, мин сине яратам», — дип, матур, кечкенә иреннәре белән үбүен тоя. Кайбер урыннарда машинаның тигезсез юлга эләгеп селкетеп җибәрүләре генә аны татлы хыялларыннан арындырып җибәрә иде. «Аллага шөкер, иң куркыныч араны да уздык бугай. Димәк, бүген безнең көн. Кызым, матурым минем, менә күп

калмады, тиздән мин сезнең янга кайтам. Менә бу соңгы перегон, — дип уйлады ул. Кинәт көчле шартлау Бойковлар машинасын күтәреп бәрде. Бойковның үзен һава дулкыны алгы тәрәзәдән очырып чыгарды.

Ул аңына килгәндә, калган машиналарга да ут капкан, шулай да кайдадыр берничә Калашников автоматының тавышы ишетелә. Димәк, әле исән калучылар бар. Бойков тиз генә тормакчы булды, шунда гына ул үз аякларының коточкыч авыртуын тоеп, әкрен генә ыңгыраша, калтырый, бөгелеп, аякларына күз салса, анда аяк урынында кан белән сугарылган, урыныурыны белән теткәләнеп беткән, сөякләре күренеп торган массаны шәйләде. Бу күренештән Бойков акырып җибәрде. Йа Хода, нинди гөнаһларым өчен?! Бойков нindидер бер ят нәрсәне тойды. Кайдадыр аның янында әҗәл йөри. Әҗәлдән мүкләнгән җир, черегән тирес исе килә кебек. Димәк, хәзер ул бу дөнья өчен юк. Бу аның соңгы минутлары. «Кызым, Олечка, эткәй-әнкәй, бәхил булыгыз, хушыгыз, кадерлеләрем», — дип пышылдады, күзләреннән бертуктаусыз яшь акты.

Мина шартлап барлыкка килгән чокырда исән калучылар икәү: утны-суны кичкән Барсуков белән Габдуллин Хәсип. Әфганлылар, көтмәгәндә һөҗүм итеп, берничә минутта ук ике машинаны юк итсәләр, өченче машинада барган Хәсип, алдагы машинага ут кабуга, сикереп төшеп чокырга чумды. Берничә секундтан аның машинасы да дөрләп яна башлады. Озак та үтмәде, мөҗәһитләр үзләре дә күзгә чалынды. Аның берүзенә дошман пулясы баш күтәрергә дә ирек бирми. Аның чокырына Барсуков килеп төшкәч кенә хәле җиңеләйде. Алар хәзер икесе ике якка карап саклана башладылар. Хәсип үзләреннән илле генә метр арада берәүне шәйләп алды. Бу ара куркыныч, граната ыргытса, исән калам димә.

— Коля, хәзер граната ыргытачаклар. Әнә теге таш артында дошман солдаты. Прицелга алырга кирәк, икебезгә дә! Югыйсә соң булуы бар!

Коля, тиз генә Хәсип янына килеп, автоматын ташка төбәде. Хәзер көтәргә генә калды. Кем кемне алдар. Берничә секундтан, чыннан да, мөҗәһит күтәрелеп тиз генә граната ташлыйм дигәндә генә автоматтан берьюлы очередь бирелде. Ул акырып җибәрде, ләкин кулындагы үлем ташын ыргытып өлгерә алмады. Озакламый көчле шартлау аның гәүдәсен теткәләп ыргытты.

Мөҗәһитләрнең гадәте билгеле: һич көтмәгәндә килеп чыгып, көтелмәгән урыннан ут өермәсе уйнату. Шуңа күрә алар бүген дә дөрес тактика сайладылар. Иң кулай урында һөҗүм итмичә, бөтенләй көтмәгән җирдән китереп чәнчеделәр. Нәтиҗә коточкыч иде. Уналты яшь солдатның унбере сугышның беренче минутларында ук һәлак булды. Калган берничәсе ап-

тырап калып, кайсы кая качып әфганлыларга менә дигән мишень булдылар. Ә ике «карт» солдат әле һаман исән иде. Үлем белән ярыш бара. Тик аларның да минутлары санаулы. Әгәр дә берәр могҗиза булмаса, иң күбе — тагын ун-унбиш минут.

Алардан бер-ике йөз метр гына ераклыкта авыр яралы прапорщик Бойков ята. Вакыт-вакыт ул аңын югалта. Аңына килгән арада атышкан, шартлаган тавышлар колагына ишетелеп китә. Менә аның күзенә дошман солдатлары чалынды...

Хәсип, яраланып, чокырга килеп төште. Пуля аның уң як җилкәсенә тигән икән, ярадан сулкылдап кан ага башлады. Коля тиз генә аның ярасына мамык тутырып бәйләргә тотынды. Шулай да кан туктарга теләмәде. Коля, кысып-кысып бәйләп, һаман канны туктатырга тырышты. Хәсипнең авызына су салды:

— Картлач, түз инде, түз! Мин сине яратам, зинһар, үлмә инде! — дип ялварды. Хәсип әкрен генә һушыннан язды.

Вертолетчылар килеп җиткәндә, монда исән нәрсә калмаган иде шикелле. Бойковны эзләп тапкан солдатлар, аның кыяфәтен күреп, өнсез калдылар. Мөҗәһитләр аны авыр яралы килеш тапкач, колак-борыннарын кисеп алганнар. Аның Бойков икәне погоныннан гына танылa иде.

Бераздан авыр яралы Хәсип белән үкереп елап утырган Барсуков Николайны да табып алдылар. Беренче вертолет Хәсипнең гәүдәсен алып һавага күтәрелде. Соңга калырга ярамый. Соңга калу — үлем белән бер. Яралы күп кан югалткан. Ә калганнарның исән калган өлешләрен җыеп бер чокырга күмделәр дә вертолетлар һавага күтәрелде. Аста «КамАЗ»лар яна, алар тирәсендә яшь солдатларның ит кисәкләре чәчелгән. Ата-аналар газиз балаларыннан, күпме кызлар сөйгән ярларыннан мәхрүм калды. Коточкыч зур бәхетсезлек. Күпме тол хатыннар, күпме тумый калган нарасыйлар...

## III

Хәсипнең Әфганга эләгүе болай булды. Армиядән ике елын тутырып кайткач, башта ул сөйгән кызы Хәдичәне югалтты. Үзе хыянәт итүне белмәгән егет бу хәлне күтәрә алмады. Эчүгә сабышты. Җыелышып эчәргә яратучы дус-ишләре белән йөри башлады. Атналар, айларга сузылды бәйрәмнәр. Нәрсә эләкте, шуны сатып эчтеләр. Инде милицияләргә эләгеп бетеп, үзенең сәрхушлек сазлыгына бата баруын аңлаган Хәсип, иптәш малае Рафаэль белән хәрби комиссариатка барып: «Алмасагыз, җинаять ясап төрмәгә керәчәкбез», — дигәч, тыңладылар. Рафаэль монда килүенең беренче аенда ук минага эләкте. Дусты искә төшкән саен, Хәсип бергә үскән, мәктәптә укыган чакларын сагынып, солдатлардан качып, күз яшьләрен койды.

Рафаэльнең вафатында аның да гаебе бар иде. Сугышка китәргә аны ул өндәде. Ничек итеп Рафаэльнең әти-әнисе күзенә карарга?!

Хәсипне аңсыз хәлендә Кабулның төньягында урнашкан госпитальгә китерделәр. Носилкага салган хәлдә ике санитар аны өч катлы бинага алып кереп китте. Дежур табиб, яралыны карагач: «Кичекмәстән операция!» — диде һәм шәфкать туташына Лев Моисеевичны тизрәк табарга кушты.

Бу вакытта хәрби хирург Лев Моисеевич үзенең танышы, өлкән лейтенант белән бүлмәсендә гәпләшеп утыра иде. Яралыга кичекмәстән операция кирәк икәнен белгәч, ашыкмый гына урыныннан торып:

— Менә үзегез күрәсез, дускай, бер минут тынычлык юк. Яралыны ничәнче палатага урнаштырдыгыз? — дип шәфкать туташыннан сорады.

— 12 нче палатада.

— Юк, 13 нчегә күчерегез, анда җайлырак булыр. Ну, миңа вакыт, якташ.

— Әйдәгез, мин сезне бераз озата барам, Лев Моисеевич.

— Соң, әйдәгез. Әгәр безнең авыруларны күреп йөрәгегез ярылмаса.

Менә алар 12 нче палатага килеп керделәр. Чыннан да, бүлмә бик шыксыз, стеналарыннан штукатуры коелган, идәндәге линолеум теткәләнеп беткән. Тәрәзәләрдән юньләп яктылык та үтми, аларның пыялалары тузанланган. Бүлмәнең үзеннән чиркангыч әллә нинди исләр килә. Капитан килеп яралының йөрәк тибешен тыңлап карады. Шәфкать туташы белән өлкән лейтенант тавышсыз гына өлкән табибны күзәттеләр.

— Эшләре начар моның, тизрәк операционныйга! Югыйсә минем намуста калачак.

Өлкән лейтенант та, табиб янына якынрак килеп, авыруга текәлде. Һәм яралының таныш йөзен күреп, аптырап калды. Кая күргәне бар соң аны? Кая?! Ул исенә төшерергә тырышты. Ике санитар кереп Габдуллинны арбага салдылар да бүлмәдән алып чыгып киттеләр.

Моисеевичның:

— Ну, миңа вакыт, туган, — дигән сүзләреннән өлкән лейтенант айнып китте.

Бу өлкән лейтенант Володя Симаков иде. Ул госпитальгә Лев Моисеевичтан берәр литр спирт алырга дип керде. Чөнки туган көне уңаеннан берничә өлкән офицерны сыйлыйсы бар иде.

Ул, госпитальдән чыккач, урамда сумала кебек каралган ике әфган баласының бер тишек тупны тибеп футбол уйнаганын күрде. Тукта, футбол. Футболның ни катнашы бар? Теге яралы һәм футбол. Симаковның башы нәрсәнедер исенә төшерергә

тырышып чыгымлый. Шулай уйланып барганда, җирдә яткан таш кисәгенә абынып, барып төште. Зур корсаклы майор Гавриловны, аннан бертуктаусыз шаркылдап көлүче солдатны исенә төшерде. Кем иде соң әле ул? Габ... Габид... Габдуллин бугай... Димәк, теге яралы сугышчы Габдуллин. Симаков ачудан тешләрен шыгырдатып куйды. Аңарда онытылып бетә язган үч алу теләге уянды. Шул солдат аркасында бөтен батальон алдында оятка калды бит ул. Аның аркасында күпме вакыт чираттагы хәрби дәрәҗәне бирмәделәр. Солдатлар һәм офицерлар арасында абруе бетте. Инде менә тагын язмышлар очраштырды.

Симаков үчле һәм гарьчел кеше иде.

Кич белән Симаковның туган көне әйбәт узды. Мәҗлестә барлыгы дүрт кеше иде. Икесе штабтан, берсе полк командиры Башкирцев. Штабтан килгән полковник Симаковны капитан дәрәҗәсе белән котлады. Тост әйтелде. Мактадылар. Генералга кадәр үсүен теләделәр.

Симаков Әфганга үзе теләп килде. Бу сугыш аның соңгы өмете. Үсәр өчен соңгы чара. Һәм ялгышмады да. Кече лейтенант булып килгән иде, капитан дәрәҗәсенә күтәрелде. Ләкин бүген ул күңелсез. Күңеленә шик төште. Тагын иске ярасы кузгалды. Кунакларга ярарга тырышып кына елмайды-көлде. Урамда көчле җил ком куа. Вакыт-вакыт каравылда торучы солдатның иптәшенә сүз катуы, кайдадыр далада ач шакаллар тавышы ишетелеп китә. Төнге сәгать бердә Симаков сакчы киткәнне көтеп торды да, госпиталь эченә үтте. Ул түзмәде. Чөнки үзенең erткыч йөрәге белән сизә: Габдуллин монда чакта аңа көн булмаячак. Нинди авырлыклар белән күтәрелгән абруе чәлпәрәмә килергә мөмкин. Ул икенче катка менеп җитте. Дежурный, өстәлгә башын куеп, черем итә. Янында битләре ачылган ниндидер китап. Әгәр алай-болай уяна калса, Лев Моисеевич янына кергән идем, диячәк. Тик әлегә барысы да тыныч. Кайсыдыр палатада гына авыр яралы ыңгыраша. Ул 13 нче бүлмә янына килеп җитеп, ишекне әкрен генә ачып, эчкә узды. Бүлмәдә караңгы. Бераз күз иялəшкәнче басып торды. Береаздан бүлмәдә ике койка, аның да берсе буш икәне беленде. Менә ул үзе. Соңгы сәгатең сукты, Габдуллин. Симаков синнән көчлерәк. Көчлеләр, хәйләкәрләр генә яшәргә хаклы. Беренче еккан түгел, соңыннан еккан җиңүче, дип уйлады ул. Аннары ныклап одеял белән яралының авызын томалады. Мөҗәһитләрдән алынган пычак авыруның сул як күкрәгенә сабына хәтле батып керде, яралы бераз тыпырчынып маташкач, җан бирде. Симаковның йөрәге күкрәгеннән чыгарлык булып тибә, ул пычакны суырып чыгарып, канын яхшылап одеялга сөртте. Аяк очларына гына басып ишек төбенә килеп, коридорны тыңлады. Анда тавышлар ишетелмәгәч, ишекне ачып кори-

дорга чыкты. Дежурный урынында. Ул аска төшеп китте. Барысы да әйбәт кенә бетте дигәндә... Урамга чыккач, ашыгып качып барганда ниндидер буш шешә аягына бәрелеп, тавыш чыгарды. Каравылчы, тавышны ишетеп, сагаеп калды.

— Кем бар анда?

Ул Симаков посып торган коймага таба атлый башлады. Бәхеткә, ул качып торган урынга яктылык төшми. Шушы нәрсә Симаковны коткарды да. Каравылчы аны шәйләмичә узып китте. Тик шуның белән капитанның качу юлын да бикләде. Кире әйләнеп кайтканда күрсә, беттең. Ул, озак уйлап тормастан, әле каны да кибеп җитмәгән пычагын солдатның култык сөяге астына кадады. Каравылчы, мескен, кычкыра да алмый калды. «Ах!» диде дә, сыгылып төшеп, йөзтүбән җиргә капланды. Симаков, карак мәче кебек, казармалар ягына элдерде. Үзе эчтән: «Ах, елки-палки, каян туры килеп тора бит, каян, ә?» — дип уйлады. Казармага килеп кергәч, сакчы солдатны чакыртып:

— Рядовой Базаров, барысы да тәртиптәме? — дип сорады.

— Әйе, иптәш капитан.

— Мин бераз ятып торам, ул-бу булса, уятырсың!

— Яхшы, иптәш капитан.

Симаков үз бүлмәсенә кереп ярты стакан спирт салды. Аның куллары дер-дер калтырый. Көзге каршына килеп үзенә күз салды. Кан-мазар эләккән урыннар күренми. Ул, спиртны эчеп, стаканны өстәлгә куйгач, урынына барып ауды. Яткач, бөтен гәүдәсе белән дерелди башлады. Сикереп торып тагын спирт эчкәч, көзге каршына килде. Аның ике күзе урынында, утлы күмер кебек, ерткыч күзләре яна. «Бу нинди күзләр соң, кая күргәнем бар иде?» — дип уйлады ул. Болар инде кеше күзләре түгел иде. Аларның бәбәге саргаеп, шуның өстенә кан йөгергән. Каравылчы Базаров бу күзләр белән очрашкач, сискәнеп куйды. «Иптәш капитан, сезнең күзләрегезгә ни булды соң?» — дип сорамакчы булган иде дә, Симаковның холкын яхшы белгәнгә, дәшми калды.

Шулай йокыга китә алмыйча интегеп ятканда, дневальныйның:

— Тревога, подъем! — дигән тавышы яңгырады. Симаков сикереп торды. «Димәк, мәетләрне тапканнар» дигән уй узды аның башыннан. Йа Алла, үзең сакла! Сикереп торып, калган спиртны шешәнең авызыннан гына койды да чыгып чапты.

Юлда аңа лейтенант Хәйдәрев очрады.

— Нәрсә булган анда, лейтенант?

— Госпитальгә һөҗүм ясалган, үлүчеләр дә бар бугай.

Алар килеп җиткәндә, особый отдел кешеләре мәет янында кайнаша иде. Берсе Әфган пычагын кулына тоткан килеш: «Менә шушы финка белән ике солдатны да суйган. Нишләп башкаларга кагылмагандыр, шунысы аңлашылмый. Ни генә булма-

сын, аңа нидер комачаулаган. Үзе генә эш иткән. Эзләр шуны күрсәтә. Ярый, мәетләрне алып китсәгез дә була. Ә сез, сержант, менә шушы финканы безнең яклы әфганлыларга күрсәтеп карагыз әле, бәлкем, таныйрлар. Миңа калса, бу кешенең шушы госпитальдә эшләгән булуы да бик мөмкин.

— Яхшы, иптәш майор! Китәргә рөхсәт итегез.

— Барыгыз!

Сержант, тиз-тиз атлап китеп тә барды. Симаков та госпиталь эченә узды. Бу финка аныкы икәнне беркем белми иде. Шуңа күрә бу нәрсә аны бик өркетмәде. Аннан бөтен андый эшләрне кем тикшереп бетерә. Моннан зуррак эшләр дә тикшерелмичә кала. Аны бөтенләй башка нәрсә борчый. Үзенең төп корбанын тагын бер мәртәбә күреп яисә берәрсеннән белешеп, Габдуллинның чынлап дөмеккәненә инану.

Каршыга шәфкать туташы очрады.

— Карале, гүзәлем, Лев Моисеевич кай тирәләрдә икән?

— Ул үзендә иде.

— Рәхмәт, сандугачым!

Олы гына гәүдәле сары марҗа кызы зур авызларын ерып җибәрде. Тик капитанның аның белән сүз куертып торырга вакыты юк иде, ул өскә ашыкты.

Хирург, ул килеп кергәндә, тәмәке көйрәтә-көйрәтә ниндидер кәгазьләр актара иде.

— О-о, әйдә, узыгыз, якташ, — дип, Симаковны каршы алды. — Ну, бәйрәмнәр ничек узды, баш ничек?

— Түзәрлек. Сездә генә күңелсезлекләр булган икән.

— Нишлисең, сугыш... Бернишләп булмый, сугыш аяусыз.

— Шулай шул, Лев туган, кайсы якныкылар соң?

Симаковның тизрәк Габдуллинның беткәненә ышанасы килә.

— Каравылчысы Саратовтан, икенчесе Ульяннанмы шунда, Сызраньнанмы?..

«Неужели», дип уйлап куйды яңа капитан.

— Әйе, Сызраньнан бугай, үзебезнең урыс малайлары. Икенчесен өч көн элек кенә яралы килеш салганнар иде.

Симаковның эче «жу» итеп китте. «Габдуллинны юк итәм дип, бер гаепсез ике солдатның башына җиткән түгелме соң?! Вәт шайтан! Исерек дуңгыз», — дип уйлады ул үзе турында.

— Шулай, Володя. Мин үзем дә юньләп аңламыйм. Әфганнарның безне җеннәре сөйми, ә без, алар өчен дигән булып, сугышып ятабыз. Кемгә кирәк инде бу эш?

— Ә мин сәясәткә катнашмыйм. Анысы начальниклар эше. Үзләре беләдер инде нигә кирәген.

Беразга сүзсез калдылар. Аннан Симаков:

— Карале, якташ, кичә бер авыр яралыны китергәннәр иде, исән калдымы соң? — дип сорады.

— Исән! Әллә берәр танышыңмы?

— Юк. Болай гына сорыйм. Үзең бит моның хәлләре хөрти, дигән идең.

— Бик түзем, таза организм булып чыкты. Канын күп югалткан булса да, бәхетенә, сөягенә зыян килмәгән.

Хәсипнең исән калуы аяз көн кебек ачык. Димәк, ул һаман исән.

— Нәрсә уйга баттың, баш чатныймы? Хәзер төзәтәбез аны, — дип, Моисеевич бер шешә чыгарды. Өстәлгә ике стакан, казылык белән ипи куйды.

— Әйе, бераз төзәтми булмас, ахры, — дип, Симаков стаканны алды.

— Әйдә, Володя, бу тәмугтан исән-сау чыгып, өйләребезгә кайту язсын, — дип, Моисеевич эчеп җибәрде.

## IV

Бер ай да ун көн дигәндә, Хәсип аягына басып, госпитальдән чыкты. Аны хәрби частька җибәрделәр. Ул хезмәт итәсе урын моннан ун-унике чакрым ераклыкта урнашкан икән. Көн кичкә авышып барганда, ул, частька килеп җитеп, тикшерү пунктында документларын күрсәткәч, сезгә менә шушы ротада хезмәт итәргә, дип, юл күрсәтеп озатып җибәрделәр.

Габдуллин килеп кергәндә, рота командиры бер яшь кыз белән сөйләшеп утыра иде. Хәсипнең колагына: «Мин сезнең белән кабергәчә дус булыр идем», дигән сүзләр чалынып калды.

Габдуллин:

— Рөхсәт итегез, мөрәҗәгать итәргә, — диде.

Рота командиры торып басты. Менә алар кабат очраштылар. Каршыда — капитан Симаков үзе! Ул Хәсипне шундук таныды. Бу кадәрен рота командиры көтмәгән иде. Ничек туры килә бит!

— Галя, сез мине гафу итегез, соңрак сөйләшеп бетерербез, минем янга якташ килгән, аның йомышы бар, ахры, — дип, кечкенә буйлы, ябык бу кызны чыгарып җибәрде.

Кыз киткәч, капитан:

— Ни йомыш, Габдуллин, әллә танымыйсың инде?! — диде.

— Таныйм шикелле, иптәш капитан!

— Димәк, сез дә биредә?!

— Нишлисең, хезмәтең шул булгач.

— Ә мин сезне шундук таныдым.

Габдуллинның йөзенә кызыллык йөгерде. Симаков, аның каушаганын сизеп:

— Сез уңайсызланмагыз, Габдуллин. Мин үчле кеше түгел. Теге чакта гаеп миндә иде, — диде.

Габдуллин, чыннан да, югалып калды. Кайчандыр бу кешедән шактый гына зыяннар күрсә дә, теге чактагы эшенә үкенә иде. «Шайтаныма кирәк идеме соң аңа сугарга. Бер-ике тапкыр менеп төшсен иде дә, күңеле булсын иде», — дип уйлады ул.

— Сез, зинһар, кичерегез, иптәш капитан.

— Ну, ничего, ничег-о! Дөньяда ниләр булмый. Алла боерса, менә монда, сугыш барган җирдә уртак тел табарбыз, дип уйлыйм.

— Хәлемнән килгәнчә тырышырмын, иптәш капитан.

— Бик яхшы! Минем аңлавымча, сине минем ротага җибәргәннәр. Ә хәзер барып взводыңны тап.

Габдуллин борылып чыгып китте. Штабтан чыккач, урамда теге чактагы гөнаһлары өчен үкенеп барганда, берәү аңа: «Хәсип, брат!» — дип эндәште.

Бу аның элеккеге хезмәттәше Коля Барсуков иде. Алар кочаклашып шактый басып тордылар.

— Хәсип туган, инде мин сине мәңге күрә алмам, дип уйлаган идем. Димәк, тагын бергә?

— Күрәсең ич, тагын бергә...

— Ә кайсы ротада соң син?

— Икенчедә.

— Алайса тагын бергә, менә сиңа майть ти-ти! Бигрәк шәп! Әйдә, алайса, малайлар белән таныштырам. Менә дигән итеп яшәрбез, Алла боерса. Аннан монда тагын берничә татарчук бар, бәлкем, синең земляклардыр әле, киттек!

## V

Гөлбетдиннең гаскәре икегә таркалды. Аның белән элек берләшкән Мөхәммәдьяр бүген үз кешеләрен алып аерылып китә. Гөлбетдин аңа күпме генә аңлатса да, үзенең намуслылыгына антлар эчсә дә, Мөхәммәдьяр тыңларга да теләмәде. Ул Гөлбетдинне караклыкта гаепләде. «Америкадан килгән валютаны тигез бүлмәдең, үзеңнең кешеләреңә иң яхшы коралны бирәсең, минекеләрне кагасың», — дип үпкә белдерде.

Гөлбетдин аңа америкалылар бирәбез дигән акчаның бер өлешен генә бирүләрен, ә корал бүлгәндә, һәрвакыт тигез бүләргә тырышканын әйтте.

Ул ялганламый иде. Тик Мөхәммәдьярның максаты бөтенләй башкада булып, тыңларга да теләмәде. Бу максатны Мөхәммәдьяр үзе һәм берничә иң якын кешеләре генә белә иде.

Капитан Симаковны тиз генә штабка чакыртып алдылар. Бүлмәдә полковник Черкашин белән бер әфганлы утыра иде. Өстәлдә — тәмәке һәм инглиз сырасы. Әфганлының өстендә — чапан, башында — яшел чалма. Маңгаенда зур яра ярылып ята.

— Утырыгыз, утыр, иптәш капитан. Таныш бул, менә бу Мөхәммәдьярның элемтәчесе.

Әйе, бу, чыннан да, шулай — Мөхәммәдьяр кешесе иде. Мөхәммәдьяр, бу сугышлардан арып-туеп, тыныч тормыш белән яшәргә уйлады. Дөрес, аның бу нияткә килүендә сөекле хатыны Әминә ханымның басымы көчле булды. Әминә ханым аңа мөмкинлек чыккан саен:

— Мөхәммәдьяр, син — батыр ир. Син — тау бөркете. Ләкин бөркетләр дә давылда һәлак була. Әгәр дә синең белән берәр хәл булса, Аллам сакласын ул нәрсәдән, бу турыда уйларга да куркыныч! Бу сабыйларым белән мин нишләрмен. Шимальдән килгән явыз урыслар китәргә җыенмыйлар. Көнетөне яңа корал, яңа гаскәр керә. Күпме мәет, хәрабәләр. Кит бу уеннан, балалар хакына үтенеп сорыйм!

Гаскәр башлыгы Мөхәммәдьярга хатынының сүзе чүп түгел иде. Ул аны ярата, аннан туган балалардан башка тормышын күз алдына да китерә алмый. Бу турыда ул үзе дә күп уйлады. Тик моңа кадәр бу эшне эшләргә ике әйбер комачаулады: берсе — шуның хәтле күп афәт алып килгән совет гаскәрләрен күралмау, икенчесе — әфганлыларның аны сатлык җан булуда гаепләүләре.

Әминәнең дә әйтүләре үз эшен эшләде. Мөхәммәдьяр тәвәккәлләргә булды...

Полковник, сүзен дәвам итеп:

— Алар хөкүмәт ягына чыгарга җыена. Бу операцияне син очлап чыгарсың. Бер-ике ышанычлырак солдат ал да, Мөхәммәдьярны каршы алырсың. Элемтәченең әйтүенә караганда, ул үзенең гаиләсе, тән сакчылары белән Елан тавының көньягыннан узачак. Шунда сез аның белән ничек безнең якка чыгачагын, кайда корал ташлаячакларын килешерсез. Бу турыда беркемгә дә ләм-мим. Берсекөнгә менә шушы элемтәче сезгә юл күрсәтер. Шулай да сак бул, бөтенләй ышанып бетәргә дә ярамый!

— Яхшы, иптәш полковник, әзерләнә башларга рөхсәт итегез!

— Барыгыз, иптәш капитан, уңышлар сезгә!

Алар яңадан элемтәче белән икәү генә калдылар. Кемнәрне алырга икән, дип баш ватты Симаков. Тәк, Барсуков бара. Тагын кем? Бәлкем, Габдуллинны?.. Белергә кирәк кем икәнен. Элеккеге кебек горур, тупас микән? Җае чыкса, олактырырга да мөмкин. Димәк, шушы ике солдат. Ярар, ни булса да булыр, хәерле сәгатьтә!

План гади генә. Элемтәче, чыгып, каретада утырып баручы Мөхәммәдьярга хәбәр бирә. Мөхәммәдьяр, экипаждан чыгып, Симаков белән юл кырыендагы зур таш янында очрашалар. Күрешү тәмамлангач, Симаков — үзенекеләр янына, Мөхәммәдьяр үзенә китә. Ә тәрҗемәче эшен элемтәче алып барачак.

Менә еракта ике ат җигелгән карета күренде. Алда — атка атланган тән сакчысы, артта — тагын бер җайдак. Димәк, Мөхәммәдьяр белән ике кеше. Симаков элемтәчегә кузгалырга ымлады. Әфганлы, ташларга баса-баса, аска — түбәнгә атлады. Ул киткәч, Симаков солдатларга:

— Егетләр, барысын да прицелга алыгыз, ләкин мин әйтмичә ут ачмагыз, — диде.

Тау борылышыннан экипаж килеп чыкты. Элемтәче, кул селтәгәч, алда барган җайдак элемтәче янына килеп нәрсәдер сорады. Аннан, борылып, каретага таба китте. Мөхәммәдьяр, элемтәче килеп җитәрәк, ун-унбиш метр ара калгач, каретадан чыкты. Элемтәче нидер аңлата башлады. Алар янына беренче җайдак та килеп туктады. Симаков солдатларга:

— Барсуков, син боларын, Габдуллин, син арттагы җайдакны мушкага ал! Тәк! Әзер булыгыз! Ут! — диюенә, ике автомат һәм бер пулемет тик торган кешеләргә ут ачты. Биш минут дигәндә, Мөхәммәдьярның бөтен гаиләсе, ике тән сакчысы, элемтәчесе якты дөньядан олактырылды.

— Минем арттан, егетләр, — дип, Симаков түбәнгә таба атлады. Аңа аптырап калган ике солдат иярде. Капитан, автоматын терәп, каретаның алгы ягында яткан өч гәүдәгә якынлашты. Шунда тән сакчысы селкенеп куйган кебек булды. Симаков аңа бер магазин патронын атып бетермичә туктамады.

Мөхәммәдьяр юл кырыена чалкан ауган. Авыз-борыныннан кан ага. Күкрәге теткәләнеп беткән. Симаков, борылып, каретага таба китте. Барсуков каретаның ишеген ачып җибәрүгә, имчәк баласын күкрәгенә кыскан Мөхәммәдьярның гүзәл хатыны Әминә гәүдәсе авып төште. Пуля аның чигәсенә эләккән. Кулындагы бала да җансыз иде. Габдуллин белән Барсуков бу хәлне күреп, аптырап калдылар. Чөнки бу вәхшилектә аларның да өлеше зур. Эчтә тагын дүрт бала мәете ята. Барсуков түзмәде:

— Иптәш капитан, сез бит сөйләшергә генә барабыз, алар безнең якка чыгарга җыена, — дигән идегез.

Симаков, акырып:

— Нәрсә эшләргә икәнен мин үзем беләм, Барсуков. Меҗ-меҗ килмә, аңладыңмы? Бу — сугыш. Сугыш мәетсез булмый. Йә без, йә алар, аңладыңмы?

Барсуков дәшмәде. Капитан, мәетләрне тибеп төшереп, каретадан посылка тартмасыннан зуррак бер сандык тартып чыгарды. Бу — Мөхәммәдьярның бар булган байлыгы иде. Симаков сандыкны ачып карады. Анда — алтын-көмеш акчалар, муенса, беләзек, алмаз ташлар, тагын бик күптөрле бизәнү әйберләре... Капитан, бер беләзекне алып, әйләндерә-әйләндерә карагач, Хәсипкә китереп тоттырды.

— Мә, ал, дембельгә кайткач, әниеңә бүләк итәрсең! Сезнең мөселман халкы андый нәрсәләрне ярата бугай. Ал, ал! Әгәр минем белән хезмәт итәргә язса, дембельгә миллионер булып кайтып китәрсез.

Ул шулай диде дә Барсуковка да бер зур кашлы йөзекне төртте.

— Бу Союзда егерме-утыз мең йөри, аңладыңмы? Ә хәзер, кузгалдык!

Симаков, сандыкны тоткан килеш, алга атлады. Аңа соңгы хәлләрдән миңгерәп калган Барсуков белән Хәсип тә иярде. Бераз барып аңына килгәч, Хәсип башкалар күрмәгәндә генә беләзекне ташлап калдырды. «Ни өчен алар бер гаепсез сабыйларны харап иттеләр, ни өчен? Ни өчен капитан ут ачарга кушты, ни өчен? Бу бит җинаять!» — дип уйлады. Тик эш узган. Аның күз алдыннан канга баткан Мөхәммәдьяр һәм берсеннән-берсе матур сабыйлары китмәде. Алар бит безнең якка чыгарга теләделәр...

Берничә чакрым ара үткәч, Симаков сандыктагы байлыкларны үзе белән алып килгән капчыкка бушатты да, савытны атып бәрде. Тагын бераздан алар БТР эчендә су эчеп утыра, ә сугышчан машина тузаннар туздырып алга чаба иде.

Икенче көнне Симаков, Габдуллиннарны үзенә чакыртып:

— Сезне икегезне дә бүләккә тәкъдим иттем. Барсуков, сиңа — Кызыл Йолдыз ордены, Габдуллинга — «Батырлык өчен» медале. Кайткач, бар кызлар да сезнеке инде. Сездән бер ярты, егетләр... Нәрсә дәшмисез? Аңлашылды. Яртыгыз юк, димәк. Ярый, бу юлы үзем сыйлыйм.

Капитан, өч стакан алып, аларга виски салды.

Әйдәгез, безнең сугышчан уңышлар өчен!

Хәсипнең тамагын көчле эчемлек өтеп алды. Бераздан эчкә җылы йөгерде.

— Ну, егетләр, давай! Ял итегез, барыгыз! Мин сездән канәгать.

Солдатлар чыгып киткәч, үз-үзеннән күңеле булган Симаков тагын бераз виски эчеп куйды. Моннан бер сәгать кенә элек полковник белән сөйләшүне исенә төшерде. Полковник аңа:

— Молодец, Володька! Тиздән майор йолдызына тишек әзерли тор. Миннән калмас, Алла боерса. Ну син дөрес эшләгәнсең аларны юкка чыгарып. Ышаныч юк аларга.

Симаков бераз кабартыбрак сөйләгән иде хәлләрнең ничек булганын. Имеш, Мөхәммәдьяр күп акча, корал сорады. Соңрак яный башлады. Бүтән юл калмады.

Хәсип, чыгып, караватына ауды. Күз алдына яшь чаклары килеп басты. Хәдичә белән күрешкән кичләр. Татлы үбешүләр. Вәгъдә бирешүләр... Ләкин тормыш ул теләгәнчә генә түгел икән шул. Хәдичә башка кешегә кияүгә чыкты. «Син

мине гафу ит инде, Хәсип, бәхетле бул!» — диде дә китеп барды. Бу Хәсип өчен авыр югалту иде. Аңа Хәдичә кебек матур, аныкы кебек кара калын толымлы, йомры гәүдәле, биегәндә дә үзенә бертөрле итеп биюче кеше бүтән юк иде. Хәдичәне уйлап бик әрнеде Хәсип. Димәк, Хәдичә аны чынлап яратмаган. Инде монда, тәмугның нәкъ уртасына килеп кереп, муеннан канга батты. Ходай Тәгалә кичерер микән бу гөнаһларын?! Симаков аны батырлыгы өчен медальгә тәкъдим иткән. Кеше сую — батырлык, имеш... Ул үзен күз алдына китерде. Медаль таккан. Медальнең йолдызы очыннан кан тама. Аңа чиркангыч булып китте. Нәрсә эшләргә? Ничек котылырга бу җәһәннәмнән?

— Хәсип, тор әле! — Коляның тавышына аның уйлары бүленде.

— Тор, әйдә! Мин бер ярты таптым.

— Каян?

— Теге йөзеккә алыштырдым. Кирәге юк миңа кеше йөзекләре!

— Дөрес эшләгәнсең, Коля! Мин үземнең трофейны юлда ук ташлап калдырдым.

— Юкка ташлагансың, Хәсип. Монда аны штабистларга биреп, өч-дүрт яртыга алыштырып була иде!

— Кирәкми миңа канга баткан алтыннар! Кирәкми! Гарык мин кеше үтерүдән!

Ул сикереп торды.

— Соң, мин дә гарык, миңа да кирәге юк, картлач. Тик нишлим соң?! Син тынычлан, юкка башыңны катырма. Әйдә, салыйк булмаса. Кабарга нәрсәң бар?

Хәсип, бер плитка шоколад чыгарды. Унбиш минуттан алар акырып җырлыйлар иде инде. Коля үзенчә, Хәсип үзенчә.

## VI

Әфган җире ут эчендә... Яңа җирләрне буйсындыру авырлыклар, зур югалтулар, корбаннар, ата-аналарга кайгы-хәсрәтләр китерү аша бара. Тик империя ваемсыз. Аңа барыбер. Иван үлдеме, Галиме? Сугыш Мәскәүдән ерак. Аларга җилъяңгыр тими. Зур-зур өстәлләр сыйдан сыгылып тора. Монда — үлем, анда — бәйрәм. Бер-берсен мактау, күпертелгән уңышлар өчен орден-медальләр тагу...

Тиздән Җиңү бәйрәме. Бөтен Союзда шуңа әзерлек бара. Әйтерсең табигать үзе дә шуңа әзерләнә. Агачлар яфрак яра, кошлар сайрый. Бөтен табигать яшеллеккә төренергә җыена. Бу — яшәү, тереклек төсе.

Мәскәү Кремлен дә тырыша-тырыша алсу төскә буйыйлар. Бу — кан төсе. Бу — сугыш төсе. Бу — аның символы.

Ерак Әфганда да Бөек Җиңүгә әзерлек бара. Мәскәү түрәләренә бүләк ясарга кирәк. Шуңа күрә полковник Черкашин һәрбер взводка аерым-аерым эш биреп чыкты. Менә шуны-шуны эшләргә. Аңа, ягъни Черкашинга, өстәгеләр басым ясый. Тизрәк тә тизрәк!

Капитан Симаков кергәндә, полковник шулар хакында уйланып утыра иде, капитанның рөхсәт соравын ишеткәч, урыныннан ук торып:

— Уз, уз, Володя. Утыр. Хәлләр ничек? — дип сорашты.

— Аллага шөкер, түзәрлек, иптәш полковник.

— Менә нәрсә, капитан! Тиздән бәйрәм. Мәскәү бездән бүләк көтә. Берәр нәрсә эшләргә кирәк.

— Без әзер, иптәш полковник!

— Эш болай, капитан. Бикбулат шаһ К. авылына килеп йөри икән, — дигәч, полковник, Симаков ни әйтер икән дигәндәй, пауза ясады. Симаков дәшмәде.

— Анда аның туганнары бар, ди. Атасы һәм анасы. Алар янында шаһның берничә баласы да яши, ди. Сизәсеңме, эшнең нидән гыйбарәт икәнен?

— Юк әле, иптәш полковник.

— Хәзер аңлатам.

Озын буйлы, ак чырайлы полковник торып ук басты.

— Шаһны, шушы хәлдән файдаланып, корал ташлатырга кирәк. Тик шуны бел: ул — бик горур кеше һәм искиткеч кыю.

Симаковның бераз ачуы чыкты. Кыю һәм горур кешеләрне җене сөйми, алардан шүрли иде ул.

— Зур тактик булырга кирәк сиңа, капитан. Эшкә бер взводыңны алырсың. Әзерлән. Тиздән бәйрәм. Сине орденнан башка майор погоны да көтә! Үзең беләсең...

Симаков, бүлмәсенә чыккач, иң беренче булып взвод командирын чакыртып, эшнең нидән торганын, ничек буласын аңлатты. Соңрак, ялгызы гына калгач, барысын да тагын бер кат анализлады. Димәк, шаһның туганнары, балалары шунда булгач, сөйләшүләр барганда, шаһ безнекеләргә зыян эшли алмаячак. Үзем барсам ничек булыр икән, дип уйлады ул. Әйе, барыргадыр, мөгаен. Полковник алдында үземне күрсәтергә кирәк. Дөрес, куркынычрак эш. Шулай да тәвәккәлләргә!

Беренче Май көнне взвод кирәкле кышлакны камап алды. Өч зенит установкасының үлем бөрки торган зәһәр авызы авылга төбәлде. Симаков утырган җиңел танк авыл урамына килеп керде. Менә алар эзләгән йорт. Аны хөкүмәт яклы диһкан күрсәтте. Танк йорт янына килеп туктагач, урамга ап-ак сакаллы, 70—80 яшьләрдәге карт чабып чыгып, өйгә төртеп күрсәтә-күрсәтә нидер аңлата, тиз-тиз сөйли башлады. Күзләрендә каушау, курку галәмәте. Теге диһкан русчаны вата-җимерә тәрҗемә итә башлады:

— Ул әйтә, анда берсеннән-берсе бәләкәй тугыз бала бар. Ике хатын-кыз. Зинһар, ата күрмәгез, Ходай Тәгаләдән куркыгыз, ди.

Симаков тәрҗемәчегә:

— Әйт аңа, әгәр дә карт безне Бикбулат шаһ белән очраштырмаса, бу йорт бөтен ияләре белән күккә очачак, — диген.

Карт:

— Мин шаһның кая икәнен белмим, зинһар, балаларга кагылмагыз, үземне теләсә нишләтегез, — дип, җиргә тезләнде. Аның шомырт кара күзләреннән яшь бәреп чыкты. Бу хәлне күреп торган Хәсипнең картны кызганудан йөрәге әрни башлады.

Аның хәлен сизгән кебек Коля да:

— Бернишләп булмый, туган, сугышның үз законнары. Йә алар, йә без... — дип әйтеп куйды.

— Үзеңә кара, алайса, аксакал, минем әйтүем хак булсын. Пушканы корырга! — дип кычкырды капитан.

— Туктагыз, ата күрмәгез, хәзер мин шаһны эзләп киләм! — диде карт.

— Бар, алайса, тиз бул, — дип, капитан кырыс кына әйтеп куйды. Карт, артына борылып карый-карый, тау ягына ашыкты. Ярты сәгатьтән артык вакыт үтмәгәндер, карт белән кемнеңдер кайтып килүләре күренде. Икенче кеше Бикбулатның элемтәчесе иде.

Ул:

— Шаһ сезнең белән көрешергә теләми. Бөтенләй имансыз кешеләр генә бала-чага, карт-корыга тия, — диде. Шуңа күрә ул сезне сугыш кырында очрашырга чакыра. Ә хәзер кышлактан китүегезне сорый.

Капитан Симаков тиз генә гранатометчы Капустинны чакырып алып: «Әнә теге кыяны күрәсеңме, манчы шуңа!» — дип, әмер бирде.

Капустин яхшылап төбәп атып җибәрде. Каты шартлау ишетелде. Мина кыяга барып бәрелеп, аны кисәкләргә чәчеп ыргытты. Озак та үтмәде, икенче бер кыядан ниндидер сигнал бирә башладылар.

Элемтәче:

— Шаһ сезнең белән сөйләшергә тели, — диде.

— Бик шәп. Мин бит шуннан артыгын теләмим дә. Киттек! Ә сез, лейтенант, әзер торыгыз!

Алар элемтәче белән таш араларыннан өскә үрмәләделәр. Озак та үтмәде, аларны баштанаяк коралланган сугышчы каршы алды. Элемтәче аңа нидер әйткәч, юлны дәвам иттеләр. Бераздан урман башланды. Каядыр челтерәп чишмә ага. Ун минутлап баргач, күзгә бер төркем кешеләр һәм алачык күренде. Бу — Бикбулат шаһның яхшы итеп яшерелгән, куе агачлар

арасындагы базасы иде. Каршыга кап-кара сакаллы, зәңгәр күзле, төз гәүдәле бер кеше чыкты. Аның ике ягында ярдәмчеләре һәм тән сакчылары. Симаков, Бикбулат шаһны күргәч, аның чибәрлегеннән көнләшеп, моның артыннан хатын-кызлар көтүе белән чабадыр инде, дип уйлап алды. Шаһның усал күз карашыннан капитан, каушап, тагын да кечерәеп калган кебек булды.

— Курыкмагыз, капитан, сезгә монда бармак белән дә кагылмаячаклар. Сез әлегә кунак. Өстәл янына рәхим итегез!

Элемтәче — өстәлнең башына, капитан белән шаһ каракаршы утырды. Калганнар баскан җирдән генә күзәттеләр. Капитан сүз башлады:

— Хөрмәтле Бикбулат шаһ, мин сезгә коралларыгызны ташларга тәкъдим итәм. Нигә бер кирәкмәгәнгә кан коярга?

— Без туган җиребез өчен кан коябыз, капитан. Менә сез безнең үз ихтыярыбыз белән колга әйләнүебезне телисез. Меңнәрчә чакрым ераклыктан килеп, буйсындырмак буласыз. Без бит сезгә барып, ничек яшәргә икәнен өйрәтмибез. Нишләп монда килдегез? Нинди начарлыгыбыз тиде икән сезгә?

Вакыт-вакыт аның матур зәңгәр күзләрендә нәфрәттән яшькелт очкыннар уянды. Ләкин ул үзен шундук кулга ала, янәдән тыныч, сабыр тавыш белән сөйләвен дәвам итә иде.

Симаков акланырга тотынды:

— Без бик кечкенә кешеләр, кая кушсалар, шунда барабыз, ни кушсалар, шуны эшлибез. Без — солдатлар. Монда килүебезнең дә ни өчен икәнен сез яхшы беләсез. Сезнең халыкка тыныч, бәхетле тормыш төзергә ярдәм итү. Тугандаш Әфган халкына дусларча кул суздык без.

— Сезнең аркада күпме бала-чага, хатын-кыз, карт-коры һәлак булды. Күпме авыллар, шәһәрләр хәрабә хәлендә. Шушымы ярдәм?! Капитан, үтенеп сорыйм, китегез сез моннан! Китегез! Калдырыгыз безне! Яшик яхшы күршеләр шикелле тыныч кына!

— Әллә сезгә аста калган кешеләрегез кызганыч түгелме?

— Кызганыч, капитан. Әгәр алар кызганыч булмаса, мин сезнең белән сөйләшеп тә тормаган булыр идем. Шуңа күрә мин сезгә икенче юл тәкъдим итәм. Мин сезгә сигез әсир солдатыгызны һәм шактый гына алтын-көмеш бирәм. Тик сез кышлактан китегез!

— Яхшы, уйлап карарбыз, шаһ.

— Менә монысы егетләрчә, капитан. Әсирләрне китерегез!

Бераздан сигез әсирне Симаков янына китереп бастырдылар. Аптырап һәм куркып калган солдатлар, сарыклар шикел-

ле, бер-берсенә сыенып бастылар. Аларның күптән су-мазар күрмәгән тәннәреннән борын түзмәслек ис килә иде.

Симаков үзенең җирәнгәнен яшереп кала алмады, фу, дип куйды.

— Ярый, алар төшә торсыннар.

Бер-ике сакчы әсирләрне этә-төртә аска алып төшеп тә китте. Алар киткәч, шаһ зур гына бер янчыкны капитанга тоттырды.

— Мондагы байлык балаларыңның балаларына да җитәчәк. Алыгыз! Берәр нәрсә эчәсегез килмиме?

— Булса ярый. Көн бик эссе шул.

Бераздан өстәлдә виски, коньяк, инглиз сырасы пәйда булды. Шаһ: «Гафу итегез, мин эчмим», — дип, үзенә пепси-кола салдырды, Симаков бер стакан виски күтәреп куйды. Тагын ике банка сыра да өстәлгәч, ул үзен шактый гына кәефле һәм кыю сизде. Кайбер минутларда үзен, хәтта бик зур дипломат итеп сизеп, шаһ белән үбешәсе дә килеп китте. Тик ярамый, каршыда дошман тора. Ул тураеп басты.

Шаһ капитанга теләгән эчемлекләрен алырга тәкъдим итте. Симаков башланмаган бер виски, дүрт банка сыра алды. Аннан ачылган шешәдән бер стакан виски салып, сезнең исәнлеккә, дип, тагын эчеп җибәрде. Шаһ, ярдәмчесенә ымлап, капитанга булышырга кушты. Сугышчы виски белән сыра банкаларын тотып, Симаковны озата китте. Шаһ алар күздән югалганчы карап калды.

Симаковның башына виски шактый бәргән булып чыкты. Ул абына-сөртенә алга чапты. Аны, бөтенләй тәгәрәп китмәсен өчен, икенче бер озатучы тоткалап барды. Симаков ара-тирә аңа: «Бар да тәртиптә, бар да тәртиптә, иптәш», — дия иде. Акча янчыгын күкрәгенә яшергәч, ул уйлый башлады. Сигез әсиребезне алып кайту начар түгел, тик шаһның коралларын ташлатып булмады. Ни кылырга икән? Бераздан алар әсир солдатларны куып җиттеләр. Шаһның озатучылары шунда тукталып калды. Симаков, вискины үз кесәсенә тыкты, сыраларны әсирлектән котылган солдатларга тоттырды. Шул килеш алар аска таба атлауларын белделәр. Менә аста кышлак күренде.

Теге өй янында хуҗа карт солдатларны нindидер эчемлек белән сыйлый. Өстәлдә икмәк кисәкләре. Шунда ук бала-чага бөтерелә. Шулар арасында шаһныкылар да бар.

— Отставить! Уходим! — дип кычкырды Симаков. Ә үзен бертуктаусыз очкылык тота иде. Бар да танкка төялгәч, яңадан ком тузаннары туздырып, алга ыргылдылар. Ун минуттан алар зенитчиклар янында иделәр инде. Симаков тагын уйга калды. Полковникның приказы үтәлмәде. Сигез әсир генә эшкә файда китерер микән? Нәрсә эшләргә? Нәрсә?

— Әй, лейтенант, кил әле бирегә! Нишлибез, шаһ безнең якка чыгарга теләми. Полковник рәхмәт әйтмәячәк!

— Берни әйтә алмыйм, капитан, сез ни кушсагыз, шуны эшләрмен.

— Мә, эчәсеңме, лейтенант, шаһ бүләге.

Ул вискины сузды, лейтенант бераз эчкәч, шешәне кире кайтарды. Симаков, шешә авызын кулы белән сөртеп, үзе дә эчеп куйды.

— Уйларга кирәк, лейтенант. Уйлый-уйлый сыра эч, мә.

Лейтенант сыра эчә-эчә, ни эшләргә икән, дип уйлады.

— Беләсеңме, лейтенант, әйдә, болай итәбез.

— Ничек, капитан?

— Минә тыңла.

Озак та үтмәде, ташны да яндыра торган зенитка снарядлары кышлак өстенә яуды. Әле яңа гына тормыш кайнап торган авыл йортлары хәрабәләргә әйләнеп, туганнар каберлегенә әверелде.

Өстә бу хәлне күреп, үзенең берничек тә ярдәм кыла алмавыннан үрле-кырлы сикергән Бикбулат шаһ, тешләрен кысып, ыңгырашып, бу кабахәтлектән телсез калып, аска карап торды. Анда бер гаепсез җан ияләре кырыла. Шулар арасында — шаһның нәүмизләре. Аның йөрәге, соңгы тамчы каныма хәтле үч алачакмын, дип типте. Бераздан ул кайгыдан аңын югалтты, аның бу якты дөньяда бүтән беркеме дә калмаган иде.

Мәскәүгә түбәндәге хәбәр бирелде: «Каты бәрелешләрдән соң Бикбулат шаһ бандасы бик аз калган гаскәре белән тауга качты; сигез Совет әсире азат ителде, бик күп корал кулга төшерелде; безнең яктан югалтулар юк».

Озак та үтмәде, полковник—генералга, капитан майорга әйләнде. Хәсипнең йөрәге телгәләнде. Ул монда күбрәк булган саен, бу сугышның бер гаепсез кешеләрне корбан итүен күрде. Төптән үк аңлап бетермәсә дә, ул бу сугыш белән бик үк чиста күңелле булмаган кешеләр идарә итүен сизенә иде. Аның элеккеге патриотлыгыннан бик аз нәрсә калса, Симаковның явызлыгын күргән саен, аңа карата булган нәфрәт кабат үсә барды. Симаков та ике арада дошманлык җилләре көчәюен сизми калмады. Коля бу хәлләрне яхшы аңласа да, юк белән башыңны катырма әле, чәнчелеп китсеннәр шунда, дип, мөмкинлек чыкканда типтереп яши иде. Озак та үтмәде, Бикбулат шаһ, төн караңгылыгыннан файдаланып, бер ротаны диярлек суеп чыкты. «Симаков, син палач, мин синең белән бергә-бер очрашасым килә. Бер гаепсез сабыйларның, хатын-кызларның, картларның җаны — синең намуста. Мин сине көтәм, газраил», — диелгән иде ташлап калдырылган листовкаларда.

Бу уен эш түгел. Хәзер шаһ Симаковны юк итмичә тукталмаячак. Йә Симаков аны юк итә, йә шаһ... Бикбулат исән икән,

Симаковка тынычлык булмаячак. Аның исенә прапорщик Саттаров төште. Курку белмәс Саттаров мөҗәһитләрнең котын алып тора иде. Арымас, иренмәс бу кеше үзенең махсус группасы белән дошманнарга тынычлык бирмәде. Аның һәр солдаты ун солдатка торыр, үзе — егермегә. Тауларда засадалар оештырып, капкыннар куеп, сюрпризлар ясарга ярата прапорщик. Мөҗәһитләр, аңа бик күп нәрсәләр тәкъдим итеп, үзләре ягына чыгарга өндәделәр. Тик ул аларның элемтәчеләренә мыскыллы язу тоттырып кайтарып җибәрде. Язуда мондыйрак сүзләр булган: «Мин синең анаңны, хатыныңны, кызыңны үз күз алдыңда шулай итәм...»

Бу Рәсәй дәүләте өчен түзәрлек нәрсә булса да, мондагы халык өчен коточкыч мыскыллау иде. Озак та үтмәде, прапорщик Саттаров юкка чыкты. Берничә атнадан аның мәсхәрәләнгән гәүдәсен хәрби частьтан ерак түгел җирдән таптылар. Муенына «Синең йөрәгең батыр, тик күңелең шакшы» дигән язу тагылган иде.

Майор Симаков генерал янына китте. Ул аңардан күптән ялда булмаганын әйтеп, өенә кайтып килүне сорады.

Генерал аңа:

— Ярый, әнә һәлак булган солдатларны озата кайтырсың. Мин документларны әзерләтеп куям. Безгә дә кереп чыгарсың, — диде.

— Яхшы, иптәш генерал-лейтенант.

— Барыгыз, майор, ял итеп килегез.

Ике көннән Симаков белән ике солдат утырган йөк самолеты, күккә күтәрелеп, Ташкентка юл алды. Самолетта тагын биш тутыя табут. Аларның барысын да кайтарып куясы бар. Менә очкыч, чик сызыгын үтеп, Үзбәкстан җиренә килеп керде. Симаков җиңел сулап куйды. Хәсип, тәрәзә төбенә terәлеп, уйга чумган, Коля гырылдап йоклый.

Самолет, Ташкентта ике сәгатьләп торгач, яңадан күтәрелеп, Мәскәүгә юл алды.

Хәрби аэродромда аларны «КамАЗ» машинасы каршы алды, самолеттагы табутларны ике солдат машинага күчерергә тотындылар. Бер табутны илтеп урнаштыргач, Хәсипләр икенчесенә киттеләр. «Менә бу солдатлар урынында син дә булырга мөмкин бит. Ата-аналарга нинди хәсрәт! Тап-таза итеп үстереп, адәм иттем дигәндә генә, бу бәхетсез гаиләләргә җансыз гәүдә кайта. Алла үзе сакласын!» — дип уйлады Хәсип.

Икенче табут нишләптер бик авыр булып чыкты.

— Нишләп бу кадәр авыр икән бу, Коля?!

— Таза малай булган, ахры. Табутны «КамАЗ»га куйганда, ул Хәсипнең кулыннан ычкынып китеп җиргә төшкәч, эчендә акча шалтыраган кебек булды. Егетләр бер мәлгә аптырап калды.

— Коля, монда нәрсә икән соң?
— Шайтан белсен.
— Шулай да мәетме икән эчендә?
— Менә язылган ич, «Михайлов Артур Константинович» дигән.
— Шикле бу, Коля.
Шулвакыт артта майор Симаковның тавышы ишетелде: «Егетләр, тизрәк кыймылдагыз инде, тизрәк. Самолетны тоткарлыйбыз.»
Эш беткәч, Хәсип «КамАЗ»ның йоклагычына, Симаков белән Барсуков урындыкларга урнашты. Аларның беренче барыр җирләре 250—270 километр тирәсе иде.
Дүрт көн буе җеназаларда катнашып, әллә нихәтле кайгы-хәсрәт, күз яшьләре күреп, көне-төне аракы эчеп йөри торгач, Хәсип белән Коля тәмам ябыгып, суырылып калдылар. Ярый әле, аракы бар. Миңгерәгәнче эчкәч, бераз җиңел булып китә сыман. Бу Рәсәйдә кайгы-хәсрәт гасырлар буе бетмәгәнгә эчүчелек көчәйгәндер инде. Кая барма — эчү. Шатлык килсә — эчү, аерылышканда — тагын эчү. Аның саен кайгылар күбәя. Ирләр үлә. Хатын-кыз азгынлана. Ятим балалар саны арта. Тагын эчү, эчү, эчү... Бәхетсезләр иле. Шушы бәхетсезләр башкаларны ничек яшәргә өйрәтәләр. Бар булган байлыкларын урталай бүләргә өндиләр. Тыңламасалар, көч кулланалар, дигән уйлар килде Хәсипнең башына.
«КамАЗ», ниһаять, бер йорт янына килеп туктады. Симаков сикереп төшеп: «Әйдәгез, оланнар, без өйдә», — дип кычкырды. Өйдән бер кечкенә генә карчык килеп чыкты. Йөзенә караганда, аның Симаковның анасы икәнен чамалап була иде. Бу, чыннан да, майорның әнисе Наталья әби икән. Ул чыгып малаена сарылды.
— Володькам минем, нәнием, синме соң бу, синме?
— Мин, анакай, мин, йә, йә, булды. Әнә, кунак егетләрен каршы ал. Өйгә узыгыз, егетләр!
— Әйдәгез, әйдә, балакайларым, керегез, эчкә узыгыз. Улым, әйдә, башлап үзең кер!
Бар да өйгә керде. Өй кечкенә генә. Күптән җыештырылмаган, юылмаган икәне сизелә. Өстәлгә бер ярты, тозлы кәбестә, икмәк менеп утырды.
— Әйдәгез әле, балалар, булганыннан авыз итә торыгыз, — дип кыстады әби. Симаков стаканнарга аракы салырга тотынды. «КамАЗ» шоферы: «Миңа салма, иптәш майор, мин рульдә», — дип кире какты.
— Исән-сау кайтып җиткү белән, егетләр!
Шофердан кала бар да эчеп куйдылар. Бераз кызып алгач, Барсуков:
— Иптәш майор, ә тегесен кайчан илтәбез? — дип сорады.

— Анысы, егетләр, беркая да бармый, монда кала. Башка берни дә әйтмим, хәрби сер. Башыгыз яшь әле күп белергә.

Берничә шешә бушап, тамак ялгагач, Хәсипнең күзләрен йокы баса башлады. Моны күреп, Симаков анасына: «Әни, бу иптәшкә урын гына җәеп бир әле, ял итсен!» — диде.

Карчык торып, урын әзерләргә кереште. Өйнең почмагына идәнгә матрас җәйде, мендәр куйды.

— Ят, улым, яхшылап ял ит! — дип, Хәсипкә урын әзер булуын әйтте.

Бераздан Хәсип йокыга да китте. Иртәгесен уянып китеп, кая ятканын аңлашмый аптырап калды. Соңрак, аңына килгәч, торып тышка чыкты. Калганнар бар да йокы симертә иде әле. Арт ягы җимерелеп беткән бәдрәфне эзләп табып, эшен бетереп чыкканда, ишектә Барсуков Николай да күренде.

— Беләсеңме, старик, теге табутта нәрсә ятканын. Кичә син йокыга киткәч, без аны Симаков белән келәткә алып кереп бикләдек. Салган баштан Володя миңа, беләсеңме, нәрсә мактанды? Монда, ди, ун танк алырлык һәм тугыз катлы йорт салырлык байлык, ди. Вот козел. Син хаклы булып чыктың. Әйдә, кысып карыйк үзен. Безгә дә өлеш чыгарсын.

— Кабахәт! Ничек җирәнми икән ул кеше үтереп алтын җыярга?!

— Ташла әле, Хәсип, юк белән башың катырма! Чәнчелеп китсен алтыннары белән. Әйдә, кереп баш төзәтәбез!

Алар өйгә керделәр. Коля, өстәл янына килеп, тавыш чыгармаска тырышып аракы салды. Пышылдап кына: «Әйдә, Хәсип», — диде.

Шунда караватта яткан Симаков:

— Ну, егетләр, оятыгыз да юк икән, миңа әйтмичә генә качып эчәсез. Яле, миңа да салыгыз әле, агай-энеләр. Менә сиңа сугышчан дуслар!

Барсуков өстәл өстендә торган башланмаган шешәне ачты.

— Әйдә, командир, тор, сезнең заказ үтәлде.

Капитан торып чалбарын киде. Аяк очларына гына басып килгәч, стаканны күтәреп:

— Әйдәгез, егетләр, операциянең уңышлы бетүе белән! — диде.

Ул эчеп куйды да өстәлдән дуңгыз мае алып капкач, әнисе йоклаган почмакка таба карап:

— Наталья әби, монда синең ягулыгың бетте әле, кунаклардан оял бераз, тор әйдә, тор, ялкау киленнәр кебек ятма, — дигәч, егетләргә күз кысып алды.

Почмактан әби тавышы ишетелде:

— Хәзер, улым, торам, нишләптер теге аракыгыз тәнемне авырайткан әле, хәзер.

Бераздан әби, торып, газ плитәсе янында кайнаша, ә борынга кыздырылган дуңгыз мае исе килә башлады. Үзе, өстәл ягына караштыргалап:

— Хәзер, улым, хәзер! Менә бәрәңгемне генә кыздырырга салыйм да. Күрше Николай Васильевичка кереп чыгармын инде, — дип сөйләнде.

— Әнкәй, кил әле бирегә! Кешедән соранып йөрмә. Тот та спекулянтлардан ал, — дип, Симаков әнисенә егерме бишлеклардән торган акча төргәген сузды. Наталья әби шулкадәр күп акча күреп, каушап калды.

— Улым, нигә шулкадәр акча?!

— Бер ун шешә аракы алырсың, калганына үзеңә күчтәнәч.

— Рәхмәт инде, улым, рәхмәт! — дип, әби ишеккә таба атлады. Ишеккә җитәрәк, борылып: — Соң, улым, үзеңә калдымы, җыйган акчаңны туздырып бетермә инде! — диде.

— Кайгырма, әнкәй, калды. Андый акча миндә бер букча!

Әби чыгып киткәч, Симаков стенада эленеп торган радионы кабызды, кесәсеннән сигарет чыгарып, солдатларга да сузды.

— Тартыгыз, егетләр. Бүген яхшылап бер ял итик тә, иртәгә — юлга. Төшке аштан соң хәрби комиссариатка барып кәгазьләрне рәтләрбез. Кичкә икегезне дә ресторанга чакырам. Кайгырмагыз, минем счеттан булыр, — дип, шаяртып сүзен бетерде. Коляга бу яңалык ошады, күрәсең.

— Берәр мәткә белән танышырга булыр. Шулаймы, Хәсип?! — дип, иптәшенә карады.

— Мин бармыйм. Икәү генә әйләнерсез.

— Тагын ни булды инде сиңа? Ничек инде бармыйсың, ну, татарин, ты даешь!

— Барасым килми, кәефем юк.

— Соң, шунда күтәрелә инде ул кәеф, дустым!

Хәсип юк, диде дә Симаковтан бушап калган караватка барып ятты.

— Кайгырма, Барсуков, икәү булса да типтереп кайтырбыз, — диде Симаков.

— Өчәү күңеллерәк иде бит.

— Икәү дә күңелсез булмас. Әйдә, тышка чыгып һава сулап керәбез. Ә ул ятсын, вакытыннан алда картайган нәрсә.

Симаков белән Николай урамга чыгып югалдылар. Тәрәзә аша аларның кычкырып-кычкырып сөйләшкән, көлешкән тавышлары ишетелеп китә. Аларның кәефен аракы пары шактый гына күтәргән иде инде. Хәсип үз уйларына чумды. Аның күз алдына бер гаепсезгә үтерелгән карт-корылар, гөнаһсыз сабыйлар килде. Аннан штабта берни эшләмичә корсак си-

мертеп ятучы офицерларны уйлады. Үз-үзләреннән канәгать, төрле оятсыз анекдотлар сөйләшеп кенә көн уздырган бу адәмнәрдән җирәнеп куйды. Шул ук вакытта сугыш, чыннан да, Әфган халкына кирәк, аларның киләчәк бәхетле тормышы өчен көрәшәбез, дип уйлап кан койган солдат-офицерлар исенә төште. Бу каһарманнар эшләгән батырлыклар хисабына кемнәрдер баеды, орден-медальләр алды. Дәрәҗәләре үсте. Ә теге беркатлы алданган патриотларның күбесе тутыя табутларда илгә озатылды.

Симаков белән Барсуков урамнан бәрәңге пешеп җиткәнче үк керделәр.

Симаков, Хәсипкә карап:

— Нәрсә, картлач, әллә татар кызлары исеңә төштеме? Әгәр безнең карамакта көннәр булса, кайтып килгән булыр идең дә, вакыт чыкты. Иртәгә кузгалырга кирәк, — диде.

Ишектә Наталья әби күренде. Ике зур сумканы көчкә күтәргән бу кечкенә карчыкны Хәсип кызганып куйды. Барып тиз генә аның кулыннан сумкаларын алып, өстәл янына китереп сөяде.

— Уф, булды, улым! Менә унбиш шешә итеп алдым инде. Җитмәсә тагын эзләп йөргәнче.

— Ярый, әнкәй, шәп булган! Кил инде монда үзең дә. Әйдә, әткәй мәрхүм өчен берне күтәрик әле!

— Хәзер, улым, хәзер, бәрәңгене генә карыйм да. Көеп бетмәгән булса ярый инде. Сезгә дә әйтеп калдырмаганмын.

Әби, шулай сөйләнә-сөйләнә, мич артына кереп югалды. Симаков яңа шешәнең авызын ачып, дүрт стаканга аракы салырга өлгермәде, мич артыннан таба тоткан әби күренде:

— Менә, балалар, бәрәңге дә әзер булды.

Өстеннән пар күтәрелеп торган, яшел суган сибелгән бәрәңгене өстәлгә китереп куйды.

— Әйдә, әнкәй, бик озак көттерәсең, тот, әйдә!

— Әйдә, улым! Әтиең генә күрә алмады инде бу көннәрне. Сине шушы кыяфәтеңдә күрсә, шаккатыр иде. Шатлыгыннан үрле-кырлы сикерер иде.

Шулай дия-дия, Наталья әби яулык чите белән күз яшьләрен сөртеп алды.

— Ярый, әнкәй, әйдә, сыгылма, авыр туфрагы җиңел булсын!

Аракы эчкәч, бар да тавышсыз-тынсыз гына бәрәңге ашадылар. Ашап туйгач, Симаков: «Ярый, егетләр, хәрби билетларыгызны бирегез дә, мин билгеләнеп чыгыйм. Ә сез яхшылап ял итегез!» — диде. Урыныннан торды да, бер яртыны газетага төреп, дипломатына тыкты. «Бусы шундагы дусны сыйларга. Озак тормам, ул монда гына», — дип, тиз-тиз атлап чыгып китте.

Әби, Симаков китkәч, Хәсипкә карап:

— Улым, син нишләп бер дә сөйләшмисең соң? Бик күңелсез утырасың. Чирләмисеңдер бит? — дип сорады.

— Юк, әби, чирләмим.

— Үзең кайсы яктан соң, улым? Атаң-анаң бармы, бәбкәчем?

— Бар, алар Татарстанда яшиләр.

— Алайса, татар малаемы инде син?! Карале, улым, сезне тууга ат өстенә бәйләп куяларммы? Аннары сезне кәкре аяклы, кысык күзле булалар, дип сөйлиләр иде. Син бер дә андыйга охшамагансың?!

— Юк, әби, без андый түгел. Аннан ат өстенә дә бәйләп куймыйлар.

Коля шаркылдап көлеп җибәрде.

— Мин дә башта сезне шундыйрак дип уйлый идем. Әфганда татар малайларын күргәч, исем китте. Сез дә безнең кебек икәнсез ич.

Наталья әби:

— Улым, ул далада теге нәрсә әле, юрталармы әле, аларда ничек яшисез? Кыен түгелме? Аннан ниндидер сыннарга табынасыз, ди. Мунча-суның ни икәнен дә белмисез икән. Шулаймы? — дип сорады.

Хәсипнең бу сүзләргә ачуы чыкса да, әбигә сиздермәде. Елмаеп:

— Юк, әби, без авылларда яшибез. Андагы йортларыбыз сезнекеләргә караганда бик күпкә матуррак, төзегрәк. Аннан бик күп шәһәрләребез бар. Иң зурысы — Казан, ишеткәнегез бармы?

— Юк шул, улым. Минем Монголиягә барганым булмады.

Коля тагын көлә башлады.

— Наталья әби, алар бит Монголиядә яшәмиләр, ә Татарстанда.

— Ә анысы кайда, Кытайдамы әллә?

— Юк, әби, Идел буенда. Сезнеңчә Волга елгасы инде. Аннан без — мөселманнар. Төрки халыкның бер өлеше.

— Әй, улым, мин бернәрсә дә аңламыйм. Ярар инде, карт кешегә үпкәләмәгез, улым...

Ике көннән алар кабат Ташкент шәһәрендә иделәр. Симаков тегендә-монда чабып йөргән арада, Коля белән Хәсип берничә морожный ашап, туйганчы морс эчәргә өлгерделәр. Көн шактый кызу, 30—35ләр тирәсе. Бераздан Симаков күренде. Ул шабыр тиргә баткан. Фуражкасын салып, кулъяулыгы белән битен, муенын сөртте: «Булды, егетләр, тиздән очабыз...»

Тагын ике сәгатьтән алар утырган самолет күккә күтәрелеп, Кабулга юл тотты. Алда тагын күңел әрнеткеч көннәр:

үлем, кан... Хәсип, шуларны уйлап, тагын да күңелсезләнде. Коля да, бераз эче пошып утыргач:

— Иптәш майор, әйдә инде, бер яртыңны чыгар. — диде.

— Егетләр, бәлкем, кайтып җиткәч.

— Баш чатный бит, командир. Үтермә инде. Өстәвенә эссе.

— Ярый, сезнең кебек егетләр өчен не жалко, — дип, майор дипломатыннан шешә чыгарды. Коля үз сумкасыннан өч стакан, кыяр, туралган колбаса, ипи, бер плитка шоколад чыгарды. Бераз салып алгач, Симаковның да теле ачылды. Ул егетләрне мактады. Әгәр барысы да яхшы гына барса, орден-медальләр вәгъдә итте.

## VII

Бу хәлләрдән соң өч ай вакыт үтеп тә китте. Тагын сугыш. Майор Симаков батальоны мөҗәһитләр кереп оялаган кышлакны камап алды. Аларга бирелергә кушарга бер дийканны җибәрделәр. Дийкан киткәнгә шактый вакыт узды. Инде көн дә яктырды. Майорга, ничек кенә булмасын, бу банданы юк итәргә кирәк иде. Чөнки анда аның төп дошманы — Бикбулат шаһ. Риза булырмы шаһ бирелергә, юкмы? Әгәр коралларын ташламасалар, кышлакны юкка чыгару берни тормый. Бу соңгы чара. Тик бу чараны куллануның тавышы күп булачак. Болай да Көнбатыш пропагандасы рус солдатларының кансызлыгы турында көне-төне агитация алып бара. Карьерага зыян килүе мөмкин. Бусы — соңгы чара. Шулай да эшнең уңай бетүен теләде ул. Кышлакның бер ягында таулар башлана. Әгәр мөҗәһитләр котылырга теләсәләр, нәкъ шул яктан һөҗүм итәчәкләр. Шуңа күрә Хәсипләр ротасы күчәйтелеп, тауга урнашты. Кояш кызуы тынга каба башлады. Симаков, фляжкадан су эчеп алгач, сәгатенә күз салды. Ун тулып килә, ә дийкан һаман юк. Коля белән Хәсип янәшә генә яталар. Коля — пулемет артында. Хәсип кулында автомат. Ул гранаталарын әзерләп куйды. Унберенче яртыларда кышлак ягыннан бер кеше күренде. Симаков бинокльдән карап, элемтәче икәнен таныды. Аның башыннан риза булдылармы икән, юкмы дигән уй йөгерде. Менә әфганлы комбат көткән кыя янына килеп җитте. Кыяфәтенә караганда, аннан яхшы хәбәр көтеп булмый иде. Нәкъ шулай булып чыкты да.

— Алар бирелергә теләмиләр. Кышлактан чыкмаячаклар. Соңгы тамчы каныбызга хәтле урыс дуңгызларына каршы сугышачакбыз, — диделәр.

— Аңлашылды. Ярый, барыгыз!

Әфганлы китеп барды. Симаков уйга калды. Бикбулатны ычкындырырга ярамый. Мондый мөмкинлекнең булмавы да

бар. Иң куркыныч дошманы читлектә. Шуннан ул, телефонист янына килеп: «Полковник белән ялга әле!» — диде. Берничә минуттан полковник элемтәдә иде.

— Ни булды, майор?!

Симаков эшнең торышын аңлатты. Ни эшләргә инде, дип сорагач, полковник: «Сиңа ни эшләргә икәнен өйрәтеп торырга, пешмәгән малай түгел ич инде син! Үз җаеңа кара!» — диде дә, элемтә өзелде.

— Тфү, шайтан, — дип, Симаков сүгенеп куйды. — Аңа җиңел, үз җаеңны кара, имеш. Козел старый, — дип полковникны сүкте. Шулай да бераз көтеп торырга кирәк.

Бу вакытта кышлакта да киңәшәләр иде. Бикбулат шаһ уйга калды. Барысы да аның сүзен көтте. Шаһ үзенең хәлен аңлый. Әгәр ул бәреп чыгарга теләсә, аларны кырып салачаклар. Инде монда калсалар, кышлак халкын ут астына алачаклар. Котылу юк. Шаһ урыныннан торды. Бар да тынып калды.

— Мин сезгә бирелергә тәкъдим итәм. Бу капкыннан исән котылу юк. Үзегезнең дә, кышлак кешеләренең дә гомерен саклап калырга кирәк. Сез барыгыз да киләчәк Әфганстан өчен кирәк. Ул көн киләчәк. Кайчан да булса безнең халык урыс империясе китергән афәттән котылачак. Ә хәзер хушыгыз.

Ул, килеп, барысын да кочаклап чыкты. Аннан күрше бүлмәгә узды. Бераздан пистолет тавышы яңгырады. Аның артыннан шаһның тагын өч ярдәмчесе үз-үзләренә кул салды. Калган сугышчылар аптырап калдылар.

Комбат рота командиры Ткаченконы чакырып:

— Лейтенант, әнә теге зур йортны күрәсеңме?

— Әйе, иптәш майор!

— Бер остарак гранатометчыны ал да, аскарак төшеп, шул йортка томыр берне. Бәлкем, акылларына килерләр!

— Яхшы!

— Тиз бул!

Лейтенант китеп барды. 5–6 минуттан ике совет солдаты аска төшеп бара иде. Ахры, кышлактагылар да аларның ни кылырга теләгәннәрен сизделәр. Снайпер пулялары оча башлады. Ә лейтенант белән гранатометчы тагын да сакланыбрак ташлар артына кача-кача юлларын дәвам иттеләр. Бераздан аткан тавыш яңгырады. Башта теге йорттан тузан күтәрелде, соңрак ялкын бәреп чыкты.

— Молодцы, төгәл эшләделәр!

Бераздан кышлак эчендә ыгы-зыгы башланды. Хатын-кызлар тавышы, балалар елаганы ишетелде. Симаков мөҗәһитләрнең ни эшләргә теләгәннәренә төшенә башлады. Бала-чага, карт-коры артына качып котылу бугай ниятләре.

— Мөҗәһитләр көтүе тауга җитәрәк, илле-алтмыш метр калгач, ут ачабыз! Приказсыз атмаска!

— Иптәш майор, анда бит бала-чага, карт-коры, хатын-кызлар...

— Нәрсә, лейтенант, әллә алар урынына үзеңнең үләсең киләме?!

— Шулай да берни эшләп булмыймы?

— Була, аларның юлыннан китәргә.

— Соң, алайса, шулай итик. Соңрак берәр җирдә, үзләре генә калгач...

— Син нәрсә, лейтенант! Аларны юләр дип беләсеңме әллә? Алар бу тауда һәр тишекне, һәр ташны белә. Алар безне чүп үләне чүпләгән кебек чүпләячәкләр. Әзер булыгыз!

— Яхшы, иптәш майор!

Лейтенант аска күз салды. Анда бер көтү халык, алар артында мөҗәһитләр күренде. Көтү, төрле тавышлар чыгарып, тауга якынлаша. Симаков:

— Әзер булыгыз! Ут ачыгыз! — дип әмер бирде. Тауның тирә-ягы колак тондыргыч мылтык аткан, мина шартлаган тавышларга күмелде. Аста чарылдап кычкырган бала-чага, хатын-кыз, карт-коры тавышы ишетелеп китә. Бу кан кою озак бармады. Унбиш минут дигәндә, астагыларны кырып бетерделәр. Симаков Ткаченконы чакырып алып:

— Яралыларны, кышлакта калганнарны табып юк итегез. Аннан барысын да эз калмаслык итеп күмегез. Берәрсе исән калса, бөтен дөньяга сасытачаклар. Аннан шаһның үзен табыгыз! Мин аның дөмеккәнлегенә тәгаен ышанырга тиеш, — дип боерык бирде.

Лейтенант дәшми-тынмый китеп барды. Ул өченче генә аен хезмәт итә. Мондый сугышта беренче катнашуы. Шуңа күрә югалып калды. Чөнки җинаятьтә катнашканын аңлый иде. Ә хәзер ул тешләрен кысып, эшләгән җинаятьләрен яшерер өчен аска төшә. Анда — бала-чага, карт-коры, хатын-кыз мәетләре...

Хәсипнең мондый эшләрдә беренче катнашуы түгел. Тик бүген ул атмады. Чөнки бу — җинаять, ул күргән кабахәтлекләрнең иң шакшысы иде. Теге яктан да, бу яктан да бер гаепсезләр корбан ителде. Атыш башлануга, Хәсип ташка арты белән сөялеп, тынып калды. Сержант Меньшиков башта аны әллә яраланган инде, дип уйлады, сугыш туктагач, Хәсипнең исән-имин икәнлеген күреп:

— Габдуллин, син нишләп атмадың? Беләсеңме, моның өчен ни булганын? Син бит иптәшләреңне саттың. Дошманнарга булыштың, саттың.

— Мин палач түгел!

— Мин палачмы?! Бу сугыш, аның үз законнары!

— Мондый афераларда катнашасым килми!

— Димәк, без — аферистлар. Яхшы, Хәсип. Мин бу эшне комбатка әйтмичә калдыра алмыйм.

— Синең эш.

Икенче көнне кичке аштан соң Хәсипне Симаков чакыртып алды. Ул килеп кергәндә, комбат арты белән ишеккә басып, кулларын артка куйган хәлдә, тәрәзәдән карап тора иде. Ишектән кеше кергәнне ишеткәч, борылмыйча гына:

— Бу нәрсә инде, рядовой Габдуллин?! Беләсеңме, мондый эш өчен нишләтәләр? Хәрби трибуналга эләгәсең киләме әллә?

— Теләсә нишләтегез, минем андый пычрак эшләрдә катнашасым килми.

— Габдуллин, син мине уңайсыз хәлгә куясың, кадерлем. Инде артыгыздан төртеп диярлек Барсуков белән икегезне үстерәм. Ә син...

— Мине башка андый кабахәт эшләрегезгә алмагыз, комбат, мин, иң яхшысы, туалет чистартам, йә булмаса, «молодой»лар белән бәрәңге әрчергә йөрим. Мин бандит түгел.

— Димәк, синнән башкалар бандит.

— Ни өчен бер гаепсез кешеләр юк ителә? Ни өчен? Шушы булдымы батырлык?!

— Син мине гаҗәпләндерәсең, Габдуллин. Шундый селәгәй булырсың дип уйламаган идем. Алайса, ни өчен үзең теләп сугышка килдең? Әллә монда бушка гына майлы ботка ашаталар дип белдеңме?! Ят идең әнә авылыңда берәр мәткәңне кочып, аның янында герой булып...

— Иптәш майор, мин сездән кайда нәрсә эшләргә кирәк икәнен сорамадым. Әгәр мин сезгә монда караклык белән шөгыльләнергә комачаулыйм икән, җибәрегез мине кайтарып!

Хәсип шулай дип ычкындырганын үзе дә сизми калды. Элек тә аның теле каты иде. Инде монда нервыларының бөтенләй рәте калмады. Комбат урыныннан торды. Аның күзләренә кан йөгерде. Алар куркыныч булып яна башладылар, нәфрәт бөркеделәр. Симаков эчтән: «Тәки бу кеше минем башка җитә икән. Теге чакта дөрес сиземләгәнмен. Аны хәзер кайтарып җибәрергә дә ярамый. Алтыннарны белә. Монда да күз-колак булырга кирәк. Теге якка шылып бөтен күргәнен сатмасын», — дип уйлап куйды.

— Яхшы, Габдуллин. Син миңа дөреслекне ачтың. Ә хәзер кит!

Хәсип торып чыгып китте. Комбат телефоннан сержант Меньшиковны чакыртты. Сержант кергәч:

— Габдуллин белән булган хәлне ләм-мим. Алла сакласын,

трибуналга эләксә, безне дә чәчәргә мөмкин. Калганын күз күрер. Аңладыңмы?!

— Әйе, командир!

— Бар! Чыгышлый ашханәгә кагыл. Анда берәр нәрсә әзерләт. Мә, бу шешәне алып кереп, шунда көтеп тор. Мин полковникка керәм.

— Яхшы, иптәш майор!

Сержант чыгып китте. Шушы көннән башлап Хәсип белән Симаков арасыннан яңадан кара мәче йөгерде. Тора-бара берберсеннән шикләнүләр нәфрәткә әйләнде...

Тауларда сугыш бара. Совет гаскәрләре, каты бәрелешләрдән соң, бер биеклекне яулап алдылар. Уртада — тиз агымлы тау елгасы. Каршы якта — мөҗәһитләр, бу ягына совет гаскәрләре хуҗа булдылар. Монда инде танклар да, пушкалар да ярдәм итә алмый. Үзебезнекеләр үк ут астында калырга мөмкин. Болай атышып теге якка да, бу якка да файда юк. Тизрәк вертолетлар күренсен иде. Тик алары да ашыкмыйлар, дип уйлады Хәсип. Аның артында ташлар шыбырдаган кебек булды. Ул җәһәт кенә борылып карады. Анда Симаков күренеп китте. Хәсип, нидәндер шикләнеп, автоматын тотып күтәрелә башлады. Тик соңга калды. Пистолеттан атылган пуля Хәсипнең башына эләкте. Башта ул кулындагы автоматын төшереп җибәрде. Аннан артка таба чигенә-чигенә барып, ярдан түбән очты...

Менә болында Хәдичә чаба. Аны Хәсип куа. Каршыда чипчиста сулы, төбендәге ташларына кадәр күренеп торган елга ага. Ул Хәдичәне куып суга керде. Тотып иреннәреннән суырып-суырып үбә башлады. Үзе үбә, үзе сорый: «Син мине яратасыңмы?» Хәдичә дәшми, шырык-шырык көлә генә. Берзаман елга буенда башына ак яулык бәйләгән әнисе күренде. «Улым, чык инде, чык аннан, әнә караңгы төшә», — дип, аны ярга чакырды. Хәсип, әнисенә бер сүз дәшмичә, Хәдичә белән су сибешә бирде. Көтмәгәндә көн караңгылана башлады. Әнисе дә, Хәдичә дә каядыр юкка чыкты. Берзаман дусты Рафаэль күренде. Хәсип аңа: «Рафаэль, син исәнмени? Кая булдың син моңа кадәр?» — дип кычкырды. Тик Рафаэль бер сүз әйтмичә узып китте. Берзаман тирә-як дөм караңгыга әйләнде. «Әнкәй», — дип ыңгырашты ул...

## VIII

1992 елның көзе. Симаковның бүген 115 нче мәктәпкә очрашуга барасы бар. Бу кичәгә ул төшке аштан соң ук әзерләнә башлады. Яхшылап ботинкаларын чистартты. Аның күкрәгендә биш орден, өч медаль балкый. Погоннарыннан күренгәнчә, ул подполковник дәрәҗәсендә. Симаков үзенең йөзенә күз

салды. Бигрәк тә күзләре ошамады аңа. Ничектер нуры юк. Әйтерсең утлы күмер тыгып куйганнар. Ул йөзенә иман кертеп карар өчен елмайды. Авыз ерылды ерылуын, күзләр генә...Ярар, болай да бара, дип уйлады ул. Киресенчә, хәрби кырыслык күренәчәк болай. Бар да аңа сокланып караячак. Симаков азмы-күпме кеше психологиясен чамалый иде.

Ванна ишегеннән олы гәүдәле, тулы күкрәкле хатыны Тамара күренде. Симаков хәләл җефетеннән бер башка кыскарак булганга, берәр җиргә кунакка барсалар, үкчәле аяк киеме кия иде.

— Әйдә, мине дә алып бар инде очрашуга, берүзем өйдә ни эшләп ятыйм?! — дип ялынды аңа хатыны.

— Тамара, соң анда бала-чагалар янында ни эшлисең? Олылар табыны булса бер хәл.

— Соң, тик утырырмын шунда...

Тамараның, герой иренә ияреп барып, өстәл янында масаеп утырасы килә иде. Дөрес, аны башта Симаков ияртеп йөргәләде, тик хатынының һәр бармагына кыйммәтле йөзекләр киеп, муенына бриллиант ташлы муенсалар тагып, әллә кем булып утыруы, аннан сөйләшкәндә кысылып, килде-китте сүз әйтүләре туйдырды. Өстәвенә, өстәл артына утыргач, күп ашавы уңайсыз хәлгә калдыра иде.

Алар 1990 елны өйләнештеләр. Безнең гаскәрләр Әфганстаннан чыгарылгач, Симаков туган якларына кайтып төште. Соңрак Тамара белән кибеттә танышты. Аның булачак хатыны аракы бүлегендә эшли иде. Хәрби киемнән кергән Симаковны күргәч, Тамара: «Бераз буе белән кыяфәте дә булса, моннан ничава гына кияү чыгар иде», — дип уйлады. Симаков та аңа: «Гүзәл туташ, бүген кич белән ресторанга кичке ашка чакырсам, каршы килмәссезме? Мин әле яңа кеше, юньле танышларым да юк», — дип сүз катты. Тамара озак икеләнеп тормады.

— Ярый, минем эш сәгате кичке җидедә бетә. Килсәгез, карарбыз, — дип ризалашты Тамара.

— Кичкә кадәр, алайса, — дип, Симаков чыгып китте.

Башта ул яңа гына алган өч бүлмәле фатирына кайтты. Аны рәткә кертте. Соңрак кибеткә чыгып, төрле-төрле тәмтомнар алып кайтып буш суыткычына тутыргач, сәгать җиде тулар-тулмас зур роза чәчәкләреннән генә торган букет тотып, Тамараны каршы алды. Кибетче кыз бу кадәресен көтмәгән иде. Башта ул чәчәкләрне алырга уңайсызланды, чөнки, егерме җиде яшенә җитеп, кем дә булса чәчәк бүләк иткәнен хәтерләми иде.

Кибетче кыз, Володя белән ресторанда булып, бүлмәсенә кайткач, озак уйланып ятты. «Буе кечкенә булса соң, син сазаган кызга ярамаган ди. Күкрәк тулы бүләк, кесә тулы акча.

Ашатты, эчертте. Бер ямьсез сүз әйтмәде. Кайчан сиңа берәрсе чәчәк бүләк иткәне булды икән? Килеп аракыңны эчеп, икмәгеңне ашап үзең белән йоклыйлар да, иртә белән махмырдан акча сорап, юкка чыга торалар. Ә ул киресенчә. Бәлки, ул да берәр узгынчы гынадыр. Ярар, ни булса да булыр, китсә китәр, килсә килер. Ул беренчесе түгел. Соңгысы да ул булмас...»

Икенче көнне, һич көтмәгәндә, Володя яңадан пәйда булды. Озак тормады, бер савыт кыйммәтле конфет, бер шешә коньяк тоттырды да, кичкә сезгә мөмкинме, дип сорады. Тамара кабалана-ашыга адресын язып бирде. Симаков, ярый, кичкә кадәр, дип чыгып китте. Аңа Тамараның озын буйлы, тулы гәүдәле булуы ошый иде. Аннан туган балалар, Алла боерса, аналарына охшасалар озын буйлы булырлар. Минем кебек буй аркасында интекмәсләр, дип уйлады ул.

Кич белән Симаков килеп кергәндә, Тамара матур итеп өстәл әзерләгән иде, коньяк янына ике шешә аракы, кыйммәтле шәраб өстәлгән. Шунда ук икра, кызыл балык. Караватта Тамараның күршесе Надя утыра. Ул кияүгә бәя бирергә тиеш. Симаков моны үзе дә чамалады.

— О, нинди чибәр иптәш кызларың бар икән, әйдәгез, таныш булыйк, — дип, аңа кулын сузды. Тамара көлеп куйгандай итте. Аңа Симаковның иптәш кызын мактаганы ошамый иде. Ул хәтта Надяны чакырасы да калмаган, дип уйлады. Тик подполковник бүтән Надяга әллә ни күз салмады. Шулай да Тамарага карата аеруча игьтибарлы булды. Надяның аның саен эче пошты, көнчелек уты кабына башлады. «Килеп тора бит шушы дуңгызга. Подполковник. Орден-медальләрдән. Бу инде бала-чага түгел. Буйга озын булмаса, ярар иде әле тормыш итәргә», — дип уйлады ул.

Мәҗлес озакка сузылмады. Бер сәгатьләп утыргач, Володя:

— Сез мине гафу итегез инде. Рөхсәт итсәгез, мин китәр идем, — дип, урыныннан торды. — Тамара, мөмкин булса, ишеккә кадәр генә озатыгыз, — дип үтенде.

— Бәлкем, тагын бераз утырырсыз.

— Иртәгә эшләр күп шул, кызлар. Әле мин юньләп эшкә дә урнашып беткәнем юк. Икенче вакыт.

Тамара аны озата чыкты. Кире кергәндә, бүлмәдә Надя юк иде. Аңа керсә, ул караватында ята.

— Надя, нишләп чыгып киттең, әйдә, тагын бераз утырыйк инде, —дип, Тамара аны үзенә чакырды.

— Башым авыртып тора шул, — диде тегесе.

Надяда көнчелек чире башланган иде. Тамара бу хәлне тиз сизеп алды. Бүтән бер сүз әйтмичә, елмаеп чыгып китте.

Икенче көнне Володя аны үзенә кунакка чакырды. Тамара

килеп кергәндә, Симаков кухняда кайнаша иде. Тамараны күргәч:

— Карале, гүзәлем, хуҗабикә бул әле. Нишләптер миннән булмый, — диде.

— Яле, карыйм әле. Ни эшләргә кирәк соң монда?

Хуҗа кухнядан чыгып китте. Тамара ит кыздырырга тотынды. Барысы да әзер булгач, алар өстәл янына утырдылар. Симаков рюмкаларны коньяк белән тутыргач, торып басып:

— Рөхсәт итегез, сезнең исәнлеккә шушы коньякны күтәрергә. Мин сезнең белән танышуыма үтә дә шат, — дип тост әйтте. Алар эчеп куйдылар. Володя магнитофон кабызды. Аннары шкафны ачып, аннан бер матур шәл тартып чыгарды. Ул гаҗәеп бизәкләр белән эшләнгән сәнгать әсәре булганга, Тамара соклануын белдерде:

— Нинди матур!

— Әнигә дип алган идем мин аны. Тик ул мин кайтканчы гүр иясе булды. Сезгә насыйп булгандыр инде. Рәхим итеп алыгыз, ул сезнеке! Әфганстан бүләге. Һәм менә йөзек. Аның кашы чын алмаз.

— Алмаз?!

— Әйе, бу минем сезне ярәшү билгесе булыр. Сездән кулыгызны сорыйм. Әгәр риза булмасагыз, миннән бер истәлек булып калыр. Мин сезне ашыктырмыйм, риза икәнсез, әйтерсез.

Шулай итеп, Тамараның, ягъни Тамара Ивановнаның тормышы көтмәгәндә төптән үзгәрде дә куйды. Берничә кичтә ирле дә, байлыклы да булды. Хәзер аның бөтен нәрсәсе бар. Кибеттә эшләп, кешеләрне 100—150 граммга алдау исәбенә җыйган байлыгы Симаковныкы янында бик аз булып калды. Ләкин муеннан алтын-көмешкә чумган бу ике кешегә Ходай бәбәй бирмәде. Симаковның бар теләге үзенең мирасчысын күрү иде. Ул нервыланды. Тамарага барып тикшеренергә таләп итте. Әмма Симаков үзе авыру булып чыкты. Аңа Тибетка барып дәваланырга киңәш иттеләр. Симаков тәвәккәлләде. Каяндыр валюта юнәтте. Кәгазь-язуларын тапты. Тагын бер атнадан Тибетка китәргә җыенды.

## IX

Симаковның Тибетка китүе тоткарланды. Элеккеге Союзга кергән республикаларда сугышлар бару сәбәпле бу эш кичектерелде, чөнки шушы республикаларның тимер юллары сафтан чыгарылган, гомумән, алар аша узу куркыныч иде. Подполковник та вакытын бушка уздырмаска булды. Башта ул өр-яңа «Мерседес» алды. Аннан шәһәр читендә юнәткән унбиш су-

тый җирендә коттедж төзетә башлады. Киләчәктә балалары була калса, нәсел дәвамчысына бар нәрсәне әзер итү иде нияте.

Ә беркөнне ул төзелеш барган җирне карап кайтканда, машинасы артына ниндидер кара «Вольво» иярде. Башта аңа әллә ни игътибар итмәсә дә, бу машинаның бертуктаусыз ияреп баруын күргәч, шик туды. «Неужели мафиозниклар инде? Әгәр дә шулай булса, нишләргә?! Өйдәге алтыннарны кая яшерергә? Бәлки, алар бу турыда белмиләрдер, машинага гына кызыкканнардыр?» — дип уйлады ул. Бу турыда Симаковтан башка ике генә кеше белә иде. Аның да берсе — теге дөньяда, ә икенчесе исә эчкечегә сабышкан. Өстәвенә ул яшәгән шәһәр биредән еракта. Симаков машинасын үзенә кирәк булмаган урамнарга алып керде. Тик тегеләр арттан калмадылар. Инде шик калмады. Алар аның артыннан баралар. Нигә, нәрсәгә? Симаков газга тагын да ныграк басты. Үзе торган йорт янына килеп җиткәч, тиз-тиз генә машинасын бикләп, өенә ашыкты. Ашыга-кабалана ачкычларын табып, өенә кереп бикләнде. Тәрәзә кырыеннан сак кына аска карады. Теге машина 20—25 метр ара калдырып туктаган. Бер биш минутлап шулай карап торганнан соң, «Вольво»ның арткы ишеге ачылып китеп, аннан озын буйлы, таза гәүдәле, күн курткадан берәү чыкты. Кара күзлеге аша тирә-ягына бер күз салып алды да Симаков машинасына таба атлады. «Ни булыр инде бу?» — дип уйлады подполковник. Теге «күсәк» машинаның алгы ягына чыкты. Тәрәзә чистарткычка ниндидер кәгазь кисәге кыстырды. Аннан, кире борылып, берни булмагандай үз машинасына таба атлады. Машинага кереп берничә секунд үтмәгәндер, кузгалып китеп, күздән югалдылар. Симаков аларның китүләренә тәгаен инангач кына ишеккә юнәлде. Кулына теге кәгазьне алып караса, анда: «Иртәгә кичке сәгать сигездә «Шәрык» ресторанында көтәбез» диелгән иде. Нәрсәгә чакыралар? Нишләргә? Бәлкем, милициягә хәбәр итәргәдер? Тукта, ашыкмаска кирәк. Башта ниятләрен белергә. Бәлкем, ун-егерме мең генә сорарлар. Бер утыз мең итеп бирергә дә, чәнчелеп китсеннәр! Аннан тизрәк Тибетка сызасы иде. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, анысы да тоткарланды. Ә машинаны сорасалар? Менә дурак инде үзем дә. Нәрсәгә кирәге бар иде кыйммәтле машина? Аласы калган шунда үзебезнең үләксәне. Вәт дурак баш, дип, яңадан өенә кереп китте.

Икенче көнне кич белән сәгать җиделәрдә ул очрашуга барырга кузгалды. Хатынына: «Бер танышыма гына кереп чыгам, озакламам, кайтырмын», — диде. Сәгать сигез тулганда, ресторанга килеп җитте. Аскы катта бер-ике фахишә егетләр белән юк-бар сөйләшеп, тәмәке тарталар. Шул мәткәләрнең сары башлысы Симаковка:

— Абзый, бераз машинагызга утыртып йөрегез әле, күптән мондыена утырганым юк, — диде.

Полковник дәшмәде.

— Кара, кара, дәшмәгән була. Машина алгач, әллә кем булган, — дип, теге мәткә чәрелдәп калды.

Залда шактый кеше күп. Мондый җирләргә йөреп өйрәнмәгән Симаков үзен уңайсыз сизде. Бу ресторанның һавасы ошамый иде аңа. Шулай да сер бирергә ярамый. Ул үзен кемнәрнеңдер күзәткәнен сизде. Ике исерек егет бәрелә-сугыла залдан чыгып баралар, үзләре белән сәрхуш бер хатынны да сөйриләр. Теге хатын: «Барысы да әйбәт, барысы да әйбәт, малайлар», — дип мыгырдый. Бар җирдән кычкырып сөйләшкән тавышлар, шаркылдап көлгән йөгәнсез хатын-кызлар авазы ишетелә. Кыйммәтле хушбуй исләре аңкып тора. «Бер адәм рәтле кеше юк, ахры, монда», — дип уйлады ул. Түрдә өч кешелек ансамбль колак тондыргыч тавыш белән «Кайда син, минем иркәм?» дигән сүзләрне кат-кат кабатлап җыр башкара. Шушы көйгә, әллә нинди кыяфәт-хәрәкәтләр ясап, ун-унбиш кеше сикерә. Симаков уң яктагы бер өстәлнең буш булуын күреп, шул якка атлады. Ләкин утырырга да өлгермәде, официант килеп: «Сезне әнә теге өстәлгә кунакка чакыралар, рәхим итегез!» — диде.

Симаков официант күрсәткән якка карады. Анда җиде-сигез кеше утыра иде. Кайберләре күзлектән. Өстәл тулы ашамлык-эчемлекләр.

— Менә монда утырыгыз! — дип, кыска гына чәчле бер адәм урын күрсәтте. Симаков утырды. Теге егет рюмкаларга коньяк салып чыкты.

— Әйдәгез, сезнең белән очрашу хөрмәтенә!

— Рәхмәт! — Симаков, сер бирмичә генә коньягын эчеп, виноград кабып куйды. Тәмәке чыгарды. Тегеләрнең берсе, зажигалка кабызып, Симаковка сузды.

— Рәхмәт! Аңлавымча, теге кәгазьне калдыручылар сез буласыз?

— Әйе, сез ашыкмагыз, ашагыз, эчегез. Эш турында соңрак. Теләсәгез, кызлар китерербез, кайсын телисез? Әнә сайлагыз.

Симаков өстәл артында утырган дүрт кызга карады. Кыяфәтләренә караганда, 16—17 яшьлекләр булырга тиеш. Киемнәренең ялтыравы күзләрне чагылдыра. Кызлар Симаковка карап елмая башладылар.

— Рәхмәт, егетләр, кызлар икенче юлы.

— Юкка. Чир-мазарлары юк, шикләнмәгез. Без аларны бүген генә әле тикшертеп алдык. Чиста кызлар.

Теге шулай дигәч, бармак белән ишарәләп, кызларның берсен чакырып алды. Кыз чыннан да шәп иде.

— Менә, Таня, таныш бул, Әфган герое, подполковник Симаков галиҗәнапләре булыр.

— Мин бик шат, — дип, кыз матур булып күпереп торган арт саннарын Симаковның борын төбеннән боргалап алды.

— Таня, сезнең белән икенче юлы күрешербез. Ә хәзергә сау булыгыз!

Симаков шулай дигәч, теге шадра бәндә кызның арт санына җиңелчә генә сугып җибәрде. Тегесе елмаеп, тырт-тырт басып үз өстәленә китте.

— Егетләр, әгәр мөмкин булса, эшкә күчик.

— Ярый алайса. Эш шунда, иптәш подполковник, безнең матди яклар начарланып китте әле. Ә яшәргә кирәк. Эшләп кенә яшәп булмаганны үзегез беләсез.

— Аңлыйм. Ләкин мин сезгә нәрсә белән ярдәм итә алам? Соңгы тиеннәрне җыеп, муеннан бурычка батып машина алдым.

Каршыда утырган сары башлы ир-ат, авызын кыегайтып, елмаеп алды:

— Сез дөнья күргән кеше, Симаков. Ләкин без дә кайбер нәрсәләр аша үттек. Шуңа да уйнашмый гына сөйләшик.

— Соң, рәхим итегез! Тик мин бернәрсә дә аңламыйм.

— Хәзер аңларсыз! Безне тутыя табут кызыксындыра.

Симаковның әйтерсең башына китереп суктылар. Ул агарынып китте. Димәк, бу адәмнәр хәзинә турында беләләр. Аның юка иреннәре кысылып, күзләрен кан басты. «Ни дип сүз башларга икән?» — дип уйлады. Шулай да ул үзен кулга ала алды.

— Сез кызыксынган әйберләр күптән эшкә кереп бетте инде ул. Аны бит без шактый кешегә бүлдек. Өстәвенә миңа иң аз өлеше тигән иде.

— Симаков, алай безне акылсызга санап сөйләшмәгез инде. Без сезнең турыда туган көнегездән башлап кайчан бетәчәгегезгә кадәр беләбез.

— Әйттем бит, егетләр, ул нәрсәдән аз гына әйбер калды. Бер өлешен яшергән җирдән урладылар.

— Беләсеңме нәрсә, герой, әгәр үз теләгең белән ун миллион бирмәсәң, мин синең хатыныңны үзеңнең каршыңда ук сексмекс ясыйм. Һәм сезгә бернинди мент та ярдәм итә алмаячак. Аңладыңмы?!

Симаковны курку ала башлады.

— Егетләр, әгәр мөмкин булса, янамыйчарак сөйләшик әле.

— Барысы да үзегездән тора. Әгәр шул сумманы бирсәгез, бу шәһәрдә сезгә бармак белән дә чиртүче булмаячак. Кирәк икән, сезгә тән сакчыларына кадәр бирәм.

— Яхшы, мин уйлап карармын. Әгәр ул сумманы җыеп булса...

— Сезгә ике көн вакыт, — диде сары башлы ир-ат.

Иң зур вожаклары бусыдыр инде, дип уйлап куйды Симаков.

— Ярый, мин киттем! — Шулай дип, ул урыныннан торды.

Теге сары баш:

— Онытмагыз, ике көннән шушында, шул ук вакытта! — дип кычкырып калды.

Симаков өенә ашыкты. Тамара аның йөзен күреп:

— Ни булды? Төсең калмаган, — дип гаҗәпләнеп сорады.

— Юк, болай гына, һавасы шундый бугай бүген.

Симаковның яткач та күзенә йокы кермәде. «Нишләргә? Алтыннарны кая яшерергә?» — дип борчылды. Ул төрле-төрле юллар эзләп карады. Сикереп торып, зур бер дипломатны карават астыннан сөйрәп чыгарды. Аны ачып, эчендәге әйберләрне барлады. Ә анда автомат, патроннар, берничә граната, пистолет. Хәзер иң төп эш: алтыннарны әзерләү. Аларны яшергәч, милиция белән элемтәгә керергә.

Ул залга керде. Әкрен генә диванны урыныннан күчереп, идән такталарын балта белән каерып ачты. Анда яшерелгән төрле бизәнү әйберләрен, алтын-көмеш акчаларны зур чемоданга тутыра башлады. Шулай кызып эшләгәндә, сискәнеп китеп, борылып караса, Тамара басып тора.

— Син нишләп уяндың?

— Соң, дөбер-шатыр киләсең ич. Володя, бу кадәр байлык каян?! Нишләтергә җыенасың син аны?

— Яшерергә кирәк. Телефоннан мине сорасалар, мин өйдә юк. Ишек шакысалар, кем икәнен тәгаен белмичә ачма!

— Ни булды соң, Володя?

— Миндә байлык бар икәнен сизгәннәр.

— Кемнәр?

— Кемнәр булсын, жуликлар.

— Йа Алла, хәзер ни була инде?

— Бер Ходай белә, — дип, Симаков тирләп чыккан битен җиңе белән сөртеп алды. Хатынының кулына төртеп күрсәтеп:

— Бу йөзекләреңне салып куй, күзгә ташланмасын! — дип кисәтте.

Тамара бармакларындагы ялтыравыкларны салып иренә сузды.

— Бар, кереп ят. Йә булмаса, миңа булыш.

Алар икәүләшеп бар булган байлыкларын чемоданга тутырдылар. «Инде кая яшерергә икән, ни эшләтергә икән? Урмангамы? Юк! Ышанычлы түгел. Бәлкем, әнидән калган иске

йорткадыр? Юк, теге шакаллар кайтып казынулары бар. Әгәр яңа салына торган коттеджга яшерсәм? Подвалга чокыр казып, өстен бетонласам?»— дип баш ватты Симаков.

Төнге сәгать өчләрдә кара төстәге «мерседес» шәһәр читенә чыгып китте. Тагын ярты сәгатьтән машина анда-монда салынган, ә кайберләре әле салына гына башлаган йортлар янына килеп җитте. Симаков, машинасыннан төшеп, тирә-ягына карады. Кеше-мазар күренмәгәч, чемоданын чыгарды. Йөк шактый авыр иде. Подвалның тимер ишеген ачып, эчкә узды. Бераздан кире чыгып, «Мерседес»тан дипломатны алды. Подвалга төшеп, урта бер җиренә чокыр казырга кереште. Чокыр әзер булгач, чемоданны кадерләп кенә шунда күмде. Җир эшләре беткәч, бетон ясарга тотынды. Лачма тиргә батты, джинсылары цементка буялып, агарып калды.

Шулчак урамда машина кычкырткан тавыш ишетелде. Симаков сискәнеп китте. Ул калтырый башлады. Чабып барып, дипломатыннан автоматын суырып чыгарды. Ике гранатаны куртка кесәсенә тыккач, баскыч буйлап подвалдан өскә күтәрелә башлады. Мансардага менгәч, ян тәрәзәдән аска карады. Анда кызыл «девятка» тора. Ул әкрен генә тәрәзәне ачты. Тагын аска күз салды. Аның машинасы өстенә кеше башы сөяге куйганнар. Ул бар көчен җыеп, гранатаны «девятка»га томырды. Пыяла чылтырап коелды. Бераздан каты шартлау яңгырады. Симаков автоматтан машинаны теткәли башлады. Арткы ишектән канга баткан бер мафиозник килеп чыкты. Аның башыннан кан ага, үзе ике кулы белән эчен кысып тоткан.

— Алыгыз кирәгегезне, шакшы этләр! — дия-дия, Симаков атуын белде. Теге бәндә акырып җиргә килеп төште. Озак та үтмәде, дөрләп янган «девятка»ның бензин багы шартлады. Подполковникның борынына көйгән ит, резина, бензин исләре килеп бәрелде. Ул чабып кире подвалга төште. Чокырны казып чемоданны тартып чыгарды. Подвалдан чыгып, үз машинасына ташланды. Бәхеткә, шартлаулардан «Мерседес»ка зыян тимәгән. Симаков, әйберләрне салгач, кая барырга да белмичә кузгалып китеп барды. Кая барырга? Ни эшләргә? Милициягә барып әйтергәме? Бәлкем, әйтми торыргадыр? Машина юл буйлап чапты да чапты... Күпмедер вакыттан соң ул үзенең урман янына килеп җиткәнен күрде. «Алтыннар барын кем әйтте икән? Бу турыда бит ике генә кеше белә иде. Берсе — теге дөньяда, икенчесе — Барсуков, әллә кая яши. Ничек мондагы мафия белде икән? Симаков дипломатын арткы урындык астына яшерде. Берәр җирдә туктатып тенти башласалар... күз алдында тормасын. Ике сәгатьләп урманда торгач, шәһәр ягына юл алды.

Аның сизенүе юкка булмаган икән, шәһәр кырыенда авто-

мат аскан бер көтү милиционерлар машиналарны туктатып тикшерәләр иде. Симаков килеп җиткәч, машинасыннан чыкты. Алдан килүче милиционердан:

— Нәрсә булды? Нишләп тикшерәсез? — дип сорады.

— Анысы безнең эш! Сез кем шулхәтле, яле, документларыгызны! — дип таләп итте чандыр гына милиционер.

— Рәхим итеп карагыз. Мин берәр ярдәмем тимәсме, дип уйлаган идем.

— Сез кем соң шулхәтле?

— Әфган сугышында булдым, запастагы подполковник. Бу сүзләрне ишеткәч, омончының оятсыз аңгыра йөзе бераз үзгәрде.

— ЧП иптәш подполковник. Мафиозниклар атышкан. Машиналары белән янган дүрт мәетне таптык. Башта атканнар, аннары яндырганнар бугай.

— Әйтәм бөтен җирдә милиция.

— Әйе, шуңа. Хәрби билетыгызны алыгыз, иптәш подполковник, сезгә китәргә мөмкин!

— Рәхмәт! Уңышлар сезгә!

Симаков кузгалып китте. Заправкага кереп бакны тутырды. «Инде хәзер нишләргә? Машинада корал, чемодан тулы байлык», — дип уйлады.

## X

Тамараның ире менә икенче көн инде өенә кайтмый. «Кая йөри икән, исән микән?» — дип кайгырды мескен хатын. Өстәвенә бөтен массакүләм мәгълүмат чараларыннан теге хәл турында хәбәр итеп, хатынның болай да калмаган котын очырдылар. Шуңа бүген дә нык борчылып, төнге сәгать икеләрдә генә йокыга китте. Менә стенага эленгән сәгать икене сукты. Берзаман, тышкы ишекне ачып, кемнәрдер эчкә уздылар, өйгә әзмәвердәй өч бәндә килеп керде. Пистолетлар белән коралланган бу адәмнәрнең нияте билгесез иде. Алар пистолетларын әзер хәлдә тоткан килеш, алга уздылар. Залда кеше-мазар юк икәнлекне белгәч, йокы бүлмәсенең ишеге төбенә туктадылар...

Тамара нәрсәдәндер куркып уянып китте. Аның ятагы янында өч кеше басып тора иде. Тамараның куркудан тыны кысылды. Тегеләрнең берсе: «Уяндыңмы, сука, кая ирең?! Әйт, сука!» — дип кычкырды.

Тамара бер сүз әйтә алмаслык хәлгә килде.

— Нәрсә телсез калдың, ванючка? — дип, теге адәм китереп сукты. Хатынның күзләреннән утлар күренде.

— Әйтәсеңме, юкмы?!

Тамара көчкә:

—Белмим, — дия алды.

— Хәзер белерсең, сучка, — дип, бу бәндә чалбар төймәләрен ычкындыра башлады.

...Симаков шәһәрдән 120 километр ераклыкта яшәгән бер танышында ике көн буе ятты. Менә хәзер ул шуннан кайтып килә. Башында иксез-чиксез борчу. Аның шушы берничә көндә күз төпләре каралып чыгып, бите суырылып калды.

Бу вакытта аның өендә кабахәтлек кылына иде. Теге бандитларның берсе Тамараның авызын мендәр белән каплап тотты, икенчесе йокы күлмәген ертып, трусигын салдырып ыргытты. Алар алмаш-тилмәш Тамараны мыскыл иттеләр. Эш беткәч, берсе дипломаттан бутылка чыгарды, Тамараның авызына каерып тыгып шешәдән кислота агыздылар. Җан биреп яткан хатынның битенә калган сыекчаны сипкәч, өйдән чыгып киттеләр.

Симаков, өе янына кайтып җитәрәк, чит машина күрде. Тиз генә борылып икенче юлга кереп китсә дә, теге машинадагылар аны күрделәр. Шәһәр буйлап куыш башланды. Подполковник тегеләрдән ничек кенә аерылырга теләсә дә, алар калмады. Зур тизлек белән килгән ике машина ГАИ постын да выжлатып узып киттеләр. Шунда торган ике милиционер авызларын да ачарга өлгерми калды.

Володя пистолетын чыгарды. Тик ничек атарга? Ул рульне сул кулы белән тотып, гәүдәсен янга борып, уң кулын ишек тәрәзәсенә тыгып атып җибәрде. Пуля машинадагыларга зыян китермәде. Ә Симаковның машинасы юлдан кырыйга очты. Ләкин машина шуның кадәр уңай төште ки, берни булмагандай кыр буйлап чаба башлады. Алда — урман. Куа килүчеләр машиналарын борып аска төшкәнче, Симаков шактый араны узды.

Урман авызына килеп җиткәч, Симаков чемодан белән дипломатны күтәреп урман эченә кереп китте. Күпмедер йөгергәч, ике чемоданны күтәреп чабу кыен булганга, берсен куаклар арасына ыргытты. Озакламый бер аланга килеп чыкты. Шунда бер йорт күреп, эчкә керде. Йорт ташландык хәлдә иде. Күптән кеше тормаган, ахры. Володя чормага менде. Бераз хәл алгач, чорма тәрәзәләреннән урманга күз атты. «Бәлкем, таба алмаслар әле», — дип өметләнде. Шулай да автоматын җайлап янына куйды.

Унбиш минутлап вакыт узмагандыр, урманда кеше тавышлары ишетелде. Качкын тәрәзәдән күз салды. Анда, алан кырыенда дүрт кеше басып тора. Берсе йортка күрсәтеп нидер сөйли. Симаков автоматын тәрәзәнең пыяласыз өлешенә тыгып яхшылап төбәгәч, тәтегә басты. Урман эчендә автомат тавышы яңгырады. Теге дүрт бәндәнең берсе җиргә ауды. Калган өчесе агачлар арасына кереп югалды. Бераздан: «Симаков, иң ях-

шысы, чык. Син җиңелдең. Чемодан безнең кулда...» — дип кычкырдылар, агач артыннан чемоданны күрсәтеп.

Симаков: «Бөтен тырышлыгым бушка китте, бетте!» — дип ыңгырашты. Тегеләр тагын:

— Симаков, чык, әгәр үзең чыксаң, исән калдырабыз. Син мине танышсыңмы? — подполковникка бу тавыш таныш иде.

— Бу мин, командир, Николай Барсуков. Чык, үләксә ашаучы! Үзең чыксаң, исән каласың!

«Менә мине кем саткан икән», — дип уйлады Симаков. Ул шартлар дәрәҗәгә җитте. Барсуков кычкырган якка ата башлады. Бар булган патронын атып бетергәч, пистолетын алды.

Озак та үтмәде, урман эчендә тавышлар тагын да көчәйде. Берзаман тәрәзәдән күз салса, теге мафиозникларны берничә омончы һәм ике штатский урап алган. Аларны тентү бара. Симаковның эченә җылы йөгерде. Омончыларның берсе йортка карап: «Иптәш Симаков, чыгыгыз, монда эш бетте», — дип кычкырды.

Симаков өйдән чыгып төркемгә якынлашты. Килеп җитәрәк, пистолетын чыгарып, Барсуковка атты. Николай чайкалып торгач, җиргә чүкте. Ике омончы тиз генә Симаковның пистолетын алып, наручниклар кидерде. Барсуков өстенә иелгән кеше башын күтәрде.

— Ни эшләдең син, кабахәт җан?!

— Син кем? Мөмкин түгел! Сез бит күптән теге дөньяда булырга тиешле! — дип, Симаков артка чикте.

— Әйе, бу мин, иптәш подполковник, — дип, әлеге кеше күзлеген салды. Эшләпәсен җиргә атып бәргәч, маңгаенда пуля җөе күренде. Әйе, Симаков каршында рядовой Хәсип басып тора иде.

Симаков, акырып, җиргә капланды. Бу аның соңгы җиңелүе иде.

Барсуков аңына килде. Аның кыймылдаганын күреп, Хәсип яралы өстенә иелде.

— Коля, бу мин, танышсыңмы, бу мин!

— Таныйм, дустым, таныйм. Тик миңа, зинһар, хәзер омончыларның өлкәнен чакыр әле. Әйтәсе сүзем бар.

Шунда бер майор алар янына килде.

— Йә, нәрсә телисез?

— Иптәш майор, минем хәлләр хөрти, үзем беләм. Шуңа күрә әйтеп калыйм... — дигәч, ул хәл җыярга тынып калды. — Иптәш майор, менә бу кеше— хәрби җинаятьче. Ул Әфганстан җирендә үзебезнең ике солдатны суйды. Ә менә бу солдатның маңгаендагы җөе дә — аның «истәлеге». Симаков моны исерек баштан үзе мактанып сөйләде.

— Синең дәлилләрең юк! — дип кычкырып җибәрде Симаков.

— Бар, бар, Симаков. Менә берсе — Хәсип. Икенчесе — кеше суеп җыйган алтыннарың. Коляның күзләреннән яшь бәреп чыкты. Бераздан ул, хәл җыйгач, сүзен дәвам итте. — Теге ике солдатның берсен Симаков Хәсип белән бутап үтерсә, икенчесен госпитальдән качып чыгып барганда комачаулаганы өчен суйды. Калганын Хәсип туган үзе сөйләр. Хәсип...

Хәсип Коляга якынрак иелде.

— Нәрсә, Коля?

— Миңа күп калмады. Әни белән Машага, зинһар, минем ничек үлгәнне сөйләмә. Бандитлар пулясыннан, диярсең...

Бу Николайның соңгы сүзләре иде. Милиционер да, маңгаендагы тир тамчыларын сөртеп, бу сөйләшүне яздырган магнитофонын сүндерде.

# КАРГЫШ



# I

Безне, түләргә акча булмау сәбәпле, административ ялга җибәрделәр. Ни кылырга икән дип эч пошып йөри. Бакча туйдырды. Бер урында казыну минем өчен түгел. Ничек буш вакытны уздырырга? Шушы уйлар белән мин Бауман урамыннан атлыйм. Халык ташкыны ага. Безгә хәтле дә шулай кешеләр каядыр чапкан, бүген без, иртәгә бөтенләй башка кешеләр агылачак. Башка кыяфәтлеләр, башка киемлеләр...

Бу урамның өске ягында гына минем кадерле уку йортым — университет урнашкан. Бәхетле студент чаклар инде артта калды. Хәзер барыбыз да төрле җирләргә таралып дөнья куабыз.

— Әй, Хәниф, сәлам, брат, — дигән тавышка уйларымнан арынып киттем. Карасам, университетны бездән бер ел алдан тәмамлаган Рәкыйп басып тора.

— Ә, сәлам, Рәкыйп, хәлләр ничек?!

— Әйбәт, әле яңа гына «Татарстан яшьләре»ндә тагын ике шигырем чыкты, укыдыңмы?

Икесенең дә берәр юлын гына укып чыккан идем. Берсе аның «Авылымны сагынам» булса, икенчесе «Айсылу, син кайда?» дип атала иде бугай. Бу темалар чәйнәлеп бетеп, башка язар бизәкләр калмаганга, мин аларның бары берме, икеме юлын укуга ук эшнең нидән торганын шәйли идем. Рәкыйпнең дә күп кенә шигырьләре:

Менәр идем авылым тауларына,
Кайтыр идем мәңгегә яаннарыңа,
Мин гашыйк бит синең таңнарыңа.

Бу әле минем бераз яхшырак та чыкты кебек. Шулай да Рәкыйп талантсыз шәхес түгел, ул бик матур җырлый белә, шуңа күрә күңелен төшерәсем килмәде: «Дөресен әйтим, Рәкыйп, шигырьләрең начар түгел. Бигрәк тә теге «Айсылу, син кайда?» дигәне. Мәхәббәт темасы — ул мәңгелек! Әйе, туган. Карале, яшьти, теге синең белән студент кичәләрендә парлап җырлап йөргән Гөлсылумы әле, кайларда ул, күргәнең бармы?» — дидем.

Дөресрәге, бу сорауны мин тизрәк шигырьләр тирәсеннән китеп, башка темага күчәргә теләүдән биргән булсам, икенчедән, мине чыннан да теге кызның язмышы кызыксындыра иде.

Ошый иде ул кыз миңа. Кап-кара күзле, кара толымлы, йөзеннән нур бөркеп торган, моңлы тавышлы бу кызны мин бик еш уйлый идем.

— Сез бит, Рәкыйп, өйләнешергә йөрдегез шикелле?

Рәкыйп нишләптер үзгәреп китте. Агарды.

— Беләсеңме, Хәниф, ул бит вафат булды. Исеме аның Айсылу иде.

— Ничек?

— Дөресрәге, аны үтерделәр.

— Кит әле! Соң, андый чиста күңелле адәм баласын үтерергә ярыймыни?!

Чыннан да, миңа Айсылу бик кызганыч. Андый тәртипле, матур гаилә төзи алырдай кызлар сирәк була шул.

— Теге минем «Татарстан яшьләре»ндә чыккан «Кайда соң син хәзер, Айсылу?» дигән шигырем аңа багышланган иде.

— Авыр кайгыңны уртаклашам, дустым. Белмәдем, гафу ит!

— Шулай, — дип, Рәкыйп авыр сулады.

— Ә үтерүчене тоттылармы соң?

— Әйе.

— Кем инде ул?

— Яңа гына төрмәдән чыккан бер бәндә. Авылдашы...

— Бик кызганыч!

— Шулай! — дип, Рәкыйп яңадан авыр сулады.

— Карале, Рәкыйп, кечкенә шигырьләр язганчы, прозага күчеп кара. Яз шушы вакыйгага багышланган берәр әсәр. Калдыр Айсылу турында бер истәлек.

— Яза алмыйм.

— Алайса үзем алынам. Тик бар белгәнеңне миңа сөйлә!

— Булмый, искә төшерәсем килми! Кирәкми! Ярый, сау бул, мин киттем.

Ул шулай дия-дия, минем аптырашка калдырып, ничек кинәт килеп чыкса, шулай юкка да чыкты. Бу нәрсә булды инде тагын? Тик шулай да ниндидер шик уянып калды. Нишләп ул минем бу эштә казынуымны теләмәде?! Нишләп? Сәер. Ул үзе үк үтермәгәндер ич инде?! Тфү-тфү, Аллам сакласын! Рәкыйп турында начар уйлыйм. Кая инде аңа кеше үтерергә. Өстәвенә өйләнергә йөргән кызы. Куркак Рәкыйпкә тагын кеше үтерү!

## II

Рәкыйп белән күрешкәннән соң, ике көн вакыт үтте. Менә мин Айсылуның адресын табып, алар авылына барыр өчен автобуска утырдым. Кемне башта күрергә? Әти-әниләре белән ничек сөйләшергә? Үтерүченең туганнары белән ничек сүз башларга? Кая урнашырга? Кемдә тукталырга? Миңа калса, бу эш

күп вакытны алырга да тиеш түгел. Хәзер бер аем материал тупларга китсә, язарга бер ай вакытым кала. Аннан эшкә инде, Алла боерса. Инде күптән бер әйбер язганым юк. Иң соңгы әсәрем чыкканга да шактый гомер узды. Ходай Тәгалә миңа бераз талант бирсә дә, шуңа өстәп шактый гына зур ялкаулык та бүләк иткән. Шулай да үземне җиңеп, тик ятканчы дип, чыгып киттем. Тагын бер уңай ягымны онытa язганмын икән, миңа каршылыклар күбрәк очраган саен, мин үҗәтләнеп ныграк бара торган кеше. Тыныч диңгездә йөзәргә яратмыйм, дулкынлысы кирәк. Анысы күтәреп-күтәреп ыргыта, йә яр кырыена илтеп ташлый, йә төпкә алып китә.

Автобуста кеше күп түгел иде. Берничә маржа, ике исерек абзый. Тагын берничә кеше бар, алары телсезләр, ахры, сөйләшмиләр. Ярты сәгатьләп баргач, машина урман эченә килеп керде, алда кара тасма булып асфальт юл сузылган. Димәк, барып җитәргә дә әллә ни күп калмады. Әйтүләре буенча, Айсылу нәкъ шушы урманның бер төшендә көчләнеп, соңыннан кыйнап үтерелгән.

Менә Чишмәле авылы. Тиз киленде. Сәгать иртәнге сигез генә әле. Башлап кемне күрергә? Ә күрәсе кешеләр күп. Шулай да колхоз рәисеннән башларга ниятләдем. Беренчедән, хуҗа кеше, икенчедән, кунарга урын сорарга кирәк.

Бәхеткә каршы, ул идарәдә иде. Олы гына гәүдәле, ит белән аракыны күп кабул иткәне күренеп тора, кызыл зур борын, кабарынкы бит.

— Исәнмесез, Фатих Кәримович. Сезне Казаннар борчый әле...

Рәис селкенеп куйды.

— Яхшы, узыгыз! Тик минем вакытым күп түгел, ашап-эчәргә дә, районга китәргә, глава җыя.

— Фатих Кәримович, мин язучы кеше, Казаннан. Миңа бүген төн кунарга урын кирәк булачак, борчыганым өчен гафу итегез!

— Булыр. Минем исемнән әнә авыл сәвитенә әйтерсең. Сез ни турында язарга ниятлисез соң?

Мин кыска гына аңлатып бирдем. Рәискә бу тема ошамады, ахрысы, тыңлаганда «кхем-кхем» дип тамак кыргалады, боргаланып утырды. Мин сөйләп бетергәч: «Энем, бер дә кирәкле эш белән йөрмисең икән. Беренчедән, кызның туганнарының ярасын кузгатасың, икенчедән, гаепле малайның ялгыз әнисен борчыйсың. Йөрмә кирәкмәгәнгә! Әнә яз матуррак әйберләр турында! Ярый, хуш», — дип, ул торып чыгып китте. Кызык. Эшнең беренче минутыннан ук каршылык. Нишләргә? Тукта, авыл советын күрим дә Айсылуларның әниләренә барыйм әле.

Авыл советы чибәр генә бер ханым булып чыкты, елмаеп-

көлеп кенә сөйләшә. Күбрәк ул сөйли, мин сораштырам гына. Төп темага килеп җиткәч, ул җиңел генә аны әйләнеп уза да тагын үзенекен сөйли. Йөз баш сарыклары бар икән, илле каз бәбкәсе алганнар, Венгрия нәселеннән. Имеш, бавыры деликатес. Дүрт сыерлары, унсигез оя бал кортлары бар икән. Яшәргә бик авыр икән. Печәне, утыны кирәк, ял күргәне юк икән. Ул мине ташландык бер сарайга урнаштырып, чәй эчәргә дә чакырмыйча, казларымны ашатасым бар дип, өенә ычкынды. Мин өй эченә күз салдым. Тәмәке төтене сеңгән, ишегендә мәңге биге булмаган, стеналарына төрле хәшәрәт сүзләр, рәсемнәр төшерелгән бу бүлмәдә, белмим, кемнәр яши ала торгандыр, аңламыйм! Ярый әле, бер генә тәүлеккә килдем дип, эчтән шатланып куйдым.

Минем монда бер генә эш тә пешми әле. Рәкыйп качты, колхоз рәисе язганны теләми, авыл советы рәисе үзенекен лыкылдый. Сасы бүлмә. Әллә нинди сәер хәл әле бу...

Термостан чәй салып, колбаса белән ипи ашагач-эчкәч, кузгалдым. Авыл матур гына күренә. Йортлары да төз. Татар бай яшәргә, матур яшәргә ярата инде ул. Бая озата килгәндә, авыл советы рәисе Айсылуларның йортын күрсәтә киткән иде, аны табуы кыен булмады. Йорт таза күренә, димәк, мал җанлы, тырыш хуҗа яши. Капканы ачып эчкә үтәм. Ишегалдында кара «Жигули» тора. Үзләренеке микән, йә булмаса, берәрсе кайтканмы? Зәңгәргә буялган чолан ишеге янәшәсендәге кыңгырау төймәсенә басам. Озакламый аяк тавышлары ишетелә, ишекне ябык кына чырайлы, күз төпләре каралып чыккан илле-илле биш тирәләрендәге бер апа ача.

— Исәнмесез, апа! Мин кайчандыр сезнең Айсылу белән бергә укыган идем.

— Ә, шулаймы! — дип, апа тагын катып калды.

— Менә сезне күреп, хәлегезне генә белеп чыкмакчы идем. Әллә абый өйдә юкмы?

— Ул өйдә дә. Ни...

— Алайса, кереп, аны да күреп чыгыйм.

Өйдә илле яшьләрендәге бер ир кеше утыра иде. Басынкы гәүдәле, авыр эштән тупасланган юан, нык бармаклы, усал күзле бу кеше дә Айсылуга бик охшамаган.

— Нихәлләрегез бар?

— Ярый әле! — диде абый, башын да күтәрмичә.

— Мин сезнең кызыгыз белән бергә укыган идем.

Абый бераз башын күтәрде:

— Сезгә ни кирәк соң монда?! Үткән-беткәнне кубарып йөрисең!

— Бу коточкыч вакыйганы беләсем, хәлегезне генә уртаклашасым килгән иде.

— Нәрсәгә сиңа безнең хәл?

Бу сүзләр миңа бигрәк тупас булып яңгырады. Бу сүзләр, бар ычкын моннан, дигәннән бер дә ким түгел иде. Теге якта апаның үксеп алганы ишетелеп китте. Абзый шунда, теге бүлмәгә борылып: «Нәрсә анда үксегән буласың, зараза! Тагын бер генә ишетим!» — дип җикерде. Апа шым булды. Минем бүтән сүз әйтергә телем әйләнмәде. Нишләргә? Нәрсә соң бу? Әллә көне шулай туры килдеме?

— Ярый алайса, сау булыгыз! — дип чыгып киттем. Ишегалдындагы теге «Жигули» тагын да карарак, авыл урамы элеккедән шыксызрак булып күренде. Апаның ишегалдына хәтле озата чыкмавы гына да күңелгә әрнү өсти иде. Ничек итеп Айсылу шушы ата-анадан туды икән?! Менә хәзер Рәкыйпнең ачылып бетмәве аңлашыла. Ярый Рәкыйп йомшаграк кеше, миңа түзәргә кирәк!

## III

Искереп беткән бу йортка күптән ирләр кулы тимәгәне күренеп тора. Димәк, үтерүче шушы йортта үскән. Ишегалдына узам. Өй ишегенә йозак эленгән. Әллә мин килгәнне күреп чыгып качкан инде?! Бар микән бу авылда адәм рәтле бер кеше? Шулай да ындыр артларын карыйм әле. Сарайга керәм, мине күреп сарыклар өркелә, икенче капканы ачып артка чыксам, котым алынды. Каршымда кулына урак тотып бер апа басып тора. Мин артка чигенә башлаганны күргәч, апа телгә килеп:

— Ишек ачылганны ишетеп, кем керде икән дип, каршы алырга гына килүем, курыкма, улым. Әнә чүп үләннәрен утап, сарыкларга бирәм, яшь бәрәннәре бар.

Апаның миңа карата бернинди кара нияте булмавын төшенгәч, телгә килдем:

— Котларны очырдыгыз, апа!

Апа елмаеп җибәрде. Йөзе матураеп, ачылып китте. Яхшылабрак карагач, аның чыннан да элек бик чибәр, шул чибәрлеген әле хәзер дә югалтып бетермәгәнлеген чамаладым.

— Апа, мин сезнең авылда булган хәлләр белән кызыксынып килгән идем. Без Айсылу белән Казанда бергә укыдык.

Апа күз яшьләрен сөртеп:

— Алтын кыз иде, бәгърем. Трай типмәде. Килде-китте белән йөрмәде. Чибәр, тырыш, укымышлы иде... — диде.

— Шулай да сезнең малаегыз...

— Юк, улым, ул үтермәде аны. Ул андый эшне эшли алмый. Ул аны яратты гына.

— Ничек?!

— Улым, син бик ашыкмыйсыңдыр ич?

— Юк, иртәгә генә китәм.

— Алайса әйдә, чәй дә куйган идем, ташып ята торгандыр, кереп башта чәй эчик, шунда сөйләшеп утырырбыз. Үзең кая туктадың соң, улым, колхоз хуҗаларындамы?

— Юк, апа, кунакханәдә.

— Кем кертте инде анда сине?

— Колхоз рәисе.

— Оятлары да юк икән. Бер көнгә килгән кешене. Ярар, әйдә, чукынсыннар.

Без кергәндә газга куелган чәйнек дөбер-шатыр кайнап утыра иде. Әллә ни байлыгы булмаган бу өйнең чисталыгына шаккаттым. Әллә апаның җылы каршылавы тәэсир иттеме, миңа бу өйдәге тәртип ошый иде.

— Син, улым, әнә түргә уз. Менә монда. Илсур улымның яраткан урыны.

Апа суыткычтан сөт, каймак, кәрәзле бал, аертылган бал чыгарды.

— Балны колхоздан аласызмы, апа?

— Безнең кебекләр ала алмый аннан, улым. Сөте дә, мае да, балы да үзебезнеке. Унике оя кортым бар. Иремнең истәлеге. Ул үлгәч, үземә калды. Илсур кайтканчы саклый алсам. Үлеп ярата иде бал кортларын. Нәкъ атасы инде. Бал кортының чисталыгы, уңганлыгы, осталыгы башка беркемдә дә юк дия иде. Дөресе дә шулай аның, улым. Агуы да, балы да, башка нәрсәләре дә файдалы. Әйдә, суынганчы чәеңне эч, бәрәкәте китмәсен.

— Апа, Илсур элек тә утырып чыккан идемени?

— Әйе, ике елга утырттылар. Бер елдан чыкты.

— Ә ни өчен?

— Казанда бер кешене чишендерделәр. Берсе әнә шул колхоз рәисе малае, берсе склад мөдиренеке. Өченчесе — Илсур.

— Тегеләре күпме утырды?

— Утырмады. Илсурны күндерделәр. Бер генә кеше эшләгән булса әзрәк бирәләр, диделәр. Үзләре талаучыга балын, итен, милициягә 3 миллион да — вәссәлам. Ә безнең мескен, тегеләргә ияреп кенә йөрсә дә, утырып кайтты.

— Хәзер сезнең хәлне килеп белгәлиләрме соң? Әтиләре булышамы?

— Кемне әйтәсең, колхоз хуҗасынмы? Нишләп килсен ул безгә? Миңа үпкәле ул.

— Ни өчен?

— Ирем үлгәч, көн саен бәйләнеп йөрде. Нинди генә явызлыклар күрсәтмәде, үзенекен эшләр өчен. Улыма укырга керергә язу бирмәде. Күпме хезмәт хакыбызны кисте. Сөйләсәң чиге юк. Барыбер үз дигәненә ирешә алмады. Илсур гына кызганыч...

— Шулай да, нидән чыгып Илсур үтермәде дисез?

— Бер-берсен яраткан, инде өйләнешергә дип йөргән кешеләр үтерәме бер-берсен? Әйт әле шуны?

— Ничек өйләнешергә?!

— Әйе!

— Соң, Айсылу бүтән кешегә, бергә укыган егеткә чыгарга йөрде!

— Әйе. Ата-анасы белән дус кызлары башын бутадылар Айсылуның. Имеш, төрмәдә утырган! Имеш, атасыз бала! Төрмәдә дә утырмады бит инде ул, теге «условно» дигәнендә. Соңыннан барыбер ярату җиңде.

— Монысы бөтенләй яңалык. Алайса нишләп Илсурны алдылар?

Апа бераз уйланып калды. Күзләрен яшь пәрдәсе каплады.

— Йа Ходаем, берсен — теге дөньяга, берсен төрмәгә озаттылар! Ни өчен?! Алардан явызраклар яши бит! Ни өчен?! Кемгә начарлыгыбыз тиде икән? Кем каргады соң? — Апа алъяпкычы очына күз яшьләрен сөртте. — Төрмәдән кайткач, Айсылуның бүтән кеше белән йөрүен Илсурга сөйләгәннәр. Ә ул салган баштан бөтен клубка: «Әгәр дә Айсылу бүтән кешегә чыга икән, мин аны үтерәм», — дип кычкырган. Айсылу үләсе көнне Казаннан кайтырга тиеш иде, Илсур каршы алырга китте. Авыл башындагы урманда Айсылуны таба. Ул вакытта әле үлмәгән булган, җан кисәгем, урман эченнән юл кырыена шуышып чыккан. Илсур аны барып кочаклап ала, күлмәкләре канга буяла, бармак эзләре кала. Ул бит аны үтерергә түгел, каршы алырга гына киткән иде...

Хуҗа хатынның күзләреннән яшь ага. Аның кайгысының чиге юк. Нindидер кабахәт, күпме кешегә кайгы китергән. Мин бу апаның сүзләренә ышандым. Чөнки ышанмаска мөмкин түгел.

— Тынычланыгыз, апа! Барысы да әйбәт булыр. Бәлкем әле Илсур гаепсез булса, котылыр, — дип, тынычландырырга тырышам...

— Белмим инде, улым.

— Апа, мин хәлемнән килгәннең барысын да эшләрмен.

— Рәхмәт, улым! Булыр микән?!

Димәк, Илсур үтерүче түгел. Ә кем? Очраклы бер явызмы, Рәкыйпме? Нигә теге көнне куркып качты ул? Нигә минем язарга теләвемне өнәмәде?! Шикле әйбер бу! Бәлкем, кызның әти-әниләрен дә куркытканнардыр? Шуңа күрә мине каршы алулары да... Аларны да аңларга була. Сизәм, бу эш катлаулана бара. Хәзер нишләргә? Тикшерүчене күреп сөйләшергәме?

— Апа, бу эшне кем тикшерде соң?

— Әскәров дигән кеше. Үзебезнең районнныкы.

— Миңа иртәгә аны күрергә кирәк. Иртән районга берәр автобус йөриме?

— Юк. Иртән сөт машинасы белән китсәң генә инде, улым.

Яхшы. Димәк, иртәгә районга, әгәр анда эшләр бетсә, Казанга. Соңрак ничек тә булса Илсур белән көрешергә кирәк. Бу эштә булышырга милициядәге дустым Гамил ярдәм итә алыр дип уйлыйм.

— Ярый, апа, бик зур рәхмәт, кайтып ятарга кирәк. Караңгы да төшеп килә.

— Улым, шул ташландык өйдә ятканчы, әйберләреңне җый да, монда гына кил.

— Яхшы булыр микән соң?

— Булмаган кая, бар, бар, әнә Илсурым урынына ятарсың. Бер белмәгән кеше булсаң да, ышанычлыга охшагансың. Бар, бар, улым!

Мин, бу апаның олы күңеллелегенә шаккатып, чыгып киттем. Теге ташландык өйгә кайтып җиткәндә тәмам караңгы төшкән иде. Термосны алып дипломатка тыктым, ашамлыкларны нәрсәдер тетеп салган. Күсе дусларга бәйрәм булган, күрәсең. Инде утны сүндереп китәргә җыенганда, тәрәзәдән өй эченә ярты кызыл кирпеч килеп төште. Утны тиз генә сүндереп, өй почмагына чумдым. Димәк, минем монда килүем кемгәдер бик ошап җитмәгән, тик кем ул? Әкрен генә тәрәзә кырыена килеп урамга күз салдым. Еракта төшкән ут яктысында беркем дә күренми. Кара ниятче бәргән дә качкан, йә булмаса берәр җирдә посып ята. Нишләргә? Ничек чыгып китәргә? Берәр җирдә качып торып башка тондыра күрмәсеннәр. Ишек төбенә килеп, тирә-якны тыңлыйм. Йөрәк дөп-дөп тибә. Бер 10—15 минуттан, ул-бу ишетелмәгәч, әкрен генә ишекне ачып, тәвәккәлләдем. Иелеп кенә, рәшәткә артларына кача-поса, Илсурларга таба киттем.

Өйгә шулай дулкынланып кайтып кергәнне күргәч, хуҗа апа:

— Ни булды, улым, әллә әйберләреңә тигәннәрме? — дип сорады.

— Юк, тәрәзәгә кирпеч җибәрделәр.

— Булмас ла, бездә алай җүләрләнеп йөрүчеләр юк. Бәлкем, берәр исерек башы, йә булмаса бала-чага бу йортта барыбер кеше тормый дип ташлагандыр.

— Анда бит мин ут кабызган идем.

— Белмим, алайса кем булыр икән?

Без тагын ярты сәгатьләп сөйләшеп утыргач, йокларга яттык. Шулай да минем күңел тыныч түгел, сизәм, бу әле башы гына. Күзгә һич йокы керми. Ике-өч сәгать вакыт үтмәгәндер, чаң кага башладылар. Апа: «Йа Алла, ни булды икән, — дип, тәрәзәгә капланды. — Йа Хода, кунак йорты яна! Ярый әле, улым, монда килеп калдың!» — диде.

—Минем сезнең авылга килеп төпченеп йөрү, кемнәрнең-

дер тынычлыгын бозган, күрәсең. Очраклы гына хәл түгел болар!

Апа авыр сулап:

— Кемнәр булыр икән? — диде.

— Кем белгән инде аны. Апа, минем сездә икәнне беркем дә белергә тиеш түгел! Сорасалар караңгы капкач китеп барды, диярсез. Ә иртәгә иртүк кузгалырга булыр. Уен чынга китте!

— Яхшы, улым. Безнең бәрәңге бакчасыннан туп-туры олы юлга чыгып китәргә мөмкин. Аннан районга баручы берәр машинаны туктатырсың.

## IV

Таң сызылып атып килә. Әтәчләр берсен-берсе уздыра-уздыра кычкыра башлады. Илсурларның арт капкаларыннан бик сагаеп кына чыгып, бәрәңге түтәлләре арасына иелә-иелә, бакча башындагы талларга таба чаптым. Таллык уртасында әллә ни зур булмаган чишмә ага. Суда чәчелеп яткан ташларга баса-баса, ниһаять, ярның теге ягына сикердем. Тагын ун минуттан олы юлга чыктым. Алланың рәхмәте яусын, өченче машина туктап мине алды. Бу үз машинасы белән районга баручы урта яшьләрдәге бер ир кеше булып чыкты. Абый кеше бик сүзчән булмаганлыктан, үз уйларыма чумдым. Кем булды икән ул кичә кирпеч ыргытучы, ут төртүче? Бәлки, бу эшне бөтенләй туктатыргадыр. Юк, мин бу эшне барыбер ачыкларга тиеш.

Менә район үзәгенә дә килеп җиттек.

Мин абыйга акча биргәч, милиция бүлеген сорадым. Ул әллә ни ерак булып чыкмады.

Иртәрәк иде әле. Кече лейтенант Әскәров килмәгән. Район үзәге болай җыйнак кына күренә. Әллә ни урамнары да чүпле түгел, яшеллек тә җитәрлек. Бер сәгатьләп йөргәч, кире килсәм, дежурный Әскәровның килүен әйтте.

Әскәров дигәннәре кечкенә генә буйлы, кара чәчле, өстәл артында әллә кем булып утырырга ярата торган бер авыл егете булып чыкты. Мине күргәч, бер кирәкмәгәнгә телефон номеры җыйган, ниндидер кәгазьләр актаргалаган итте. Мондый бәндәләрне мин хезмәт иткән җирдә кепкасы белән бер метр дип үртиләр иде. Шушы нәрсә исемә төшеп, үзем дә сизмәстән көлеп җибәрдем.

— Сез нәрсә, гражданин, монда маймылланып утырасыз? Цирккa килмәгәнсездер ич. Бу сезгә кәмит күрсәтә торган урын түгел, бу районның Эчке эшләр бүлеге!

— Гафу итегез, иптәш лейтенант, бер кызык хәл искә төште дә...

Теге боргаланып-сыргаланып алгач, бәлки, лейтенант дип эндәшү дә тәэсир иткәндер, тынычлана төште. Мондый бәндә-

ләрне яхшы беләм мин, алар — үртәлүчән, гарьчел, үчле бәндәләр. Алар белән үзеңне мескенрәк, түбәнрәк тотсаң әйбәтрәк. Әгәр үзеңнең өстенлегеңне әз генә сиздерденме, ул синең кан дошманыңа әйләнергә мөмкин.

— Сезне бик яхшы эшли, тырыш егет, диделәр. Шуңа күрә сездән бер эштә ярдәм сорап керүем иде, иптәш Әскәров.

Теге үзгәрде, димәк, минем «борчак патроннар» кирәкле урынга тиде.

— Әйе, әйе, әйтегез! Тартынмагыз.

Мин эчтән генә каян җыеп бетерәләр икән шундый йолкышларны дип уйласам да елмаеп:

— Рәхмәт сезгә, иптәш лейтенант. Мине Чишмәледә булган Айсылу вакыйгасы кызыксындыра.

Әскәровның йөзе тагын үзгәреп китте. Бу сорау аңа ошамады, ахры. Нигә икән?

— Ул җинаять инде ачылды. Монда сезне нәрсә кызыксындыра соң? Кичә миңа хәбәр иткәннәр иде шул бер язучы килгән, нидер язмакчы була, дип, димәк, ул сез инде.

Менә мин шушы урында кичермәслек зур хата ясадым, үземнең уен картасын ачып салдым. Бу хата әле миңа киләчәктә үзен искә төшерәчәк.

— Иптәш лейтенант, менә мин кайбер кешеләрне күреп сөйләшкәч, шуны аңладым. Илсур бит берничек тә үтерүче була алмый. Алар бит 15 көннән туй ясарга җыенганнар. Мөмкин хәлме бу?!

— Нишләп мөмкин булмасын? Ачуланышканнардыр. Йә теге Айсылуы хыянәт иткәндер.

— Ничек хыянәт иткән?!

Әскәров шунда үзенең секста да белемле икәнен күрсәтеп алды.

— Ничек дип, берәрсе белән йөри башлагандыр.

— Ә сезнең дәлилләрегез бармы соң, иптәш лейтенант?

— Бу булырга мөмкин хәл генә.

— Булырга мөмкин хәл, булган хәл түгел бит әле.

Әскәров бөтенләй чыгырдан чыга башлады. Ул ярсып:

— Гражданин, сез әгәр ул хәлләрне язарга килдегез икән, языгыз. Ләкин тикшерүчеләргә ничек эшләргә икәнен өйрәтеп йөрмәгез. Үтерүче билгеле, Айсылу янында Илсурның аяк эзләре, күлмәгендә — бармакларыныкы. Үз күлмәгендә — Айсылу каны. Монда Отелло белән Дездемона хәле кабатланган. Ә хәзер, зинһар, минем вакытны алып утырмагыз, эш күп.

Димәк, бу кеше нәрсәдер яшерә. Илсурның гаепсезлеге ачыклана башлады. Мин лейтенантка:

— Ярый, алайса Казанга кайткач, бу эшне яңадан торгызып тикшерүләрен сораячакмын, — дидем.

Лейтенант торып ук басты:

— Яхшы, барыгыз! Без дә сезнең өстән эш ачтык. Чишмәле кунакханәсенә ут төрткәнсез. Әгәр тикшерү кабат башлана икән, сез йә йорт бәясен түлисез, йә шул ук Илсур янына бер камерага...

Менә инде монысы минем өчен көтелмәгән хәл иде. Каян китереп сугасын беләләр. Иң яхшысы — дәшмәскә, китәргә кирәк.

— Сау булыгыз!

— Хушыгыз, гражданин Хәниф иптәш!

Мин урамга чыктым. Әлеге сөйләшүдән миңгерәп калган башны саф һавада җилләтеп алырга уйладым.

Тирә-якта йортлар, кибетләр. Мәдәният сарае янында ике исерек сугыша. Район базары. Кеше кайный, гөр килә. Төрле кешеләр. Сары чәчле, кара чәчле, сакаллы, түбәтәйле, шәлле... Тукта, нинди таныш йөз булды әле бу? Кем иде соң? Мин тирәякка күз салып танышымны эзли башладым. Әнә ул ашыга. Нигә ашыга? Ул бит мине белә. Ә ник исәнләшмәде? Өстендә шул ук кара костюм. Бу бит Рәкыйп! Димәк, бу эшне эшләүче — ул. Йортны яндыручы да, кирпеч бәрүче дә. Мин аның артыннан ашыгам. Тотып, телен ачтырасы иде. Теге, минем тизләгәнне сизеп, тагын да ашыга. Менә ул ниндидер ишегалдына кереп китте. Артыннан керсәм, юк. Ух, ычкынды кабахәт. Ычкынды. Менә килеп каптым мин суның болганган җиренә. Тукта, иң яхшысы Казанга кайтып, Черек күлдәге Гамил дус белән киңәшергә кирәк.

## V

Юлны сорашып, мин автовокзалга киттем. Анда кеше күп түгел иде. Кереп билет алдым да, урамга чыктым. Автобус тагын 12 минуттан китәргә тиеш. Җилкәгә таза гына гәүдәле берәү бәрелеп китмәсенме. Дәшмим. Мин дәшмәгәч, ул тукталып:

— Нәрсә, бик тазамы әллә син, — дип бәйләнә үк башлады. Мин карап торам, ләкин бер сүз дәшмим. Хәзер килеп сугыша башласа, иягенә тартам инде бу хайванның. Ул чыннан минем эчкә китереп сукты. Шәп суга, ләкин колхозча.

— Энем, алай сукмыйлар аны, менә болайрак, — дип, мин аңа уң кул белән башына суккандай итәм. Теге, саклык чарасы күреп, башын артка алды. Миңа шул гына кирәк иде, бөтен гәүдә авырлыгымны салып сул кул белән тегеңәргә сугуым булды, ул бөгелеп төште. Уң кул белән яннан сугып, аны җиргә сузып салдым. Шулчак икенче бер адәм минем үземә дә арттан китереп томырмасынмы. Борылып саклык чарасы күрергә өлгермәдем, икенче берәү эчкә китереп типте. Күз алларым караңгыланып, җиргә егылдым.

## VI

Аңыма килгәндә кемнәрнеңдер сөйләшкәнен ишеттем.

— Юк өчен бер гаепсез кешене кыйнап ташладылар, кабахәтләр! Менә хәзерге яшьләр!

— Тукта, ул үзе беренче сукмадымы соң?

— Юк, юк, теге бозау үзе бәйләнде, үзем күрдем.

Кая соң мин? Ниндидер утыргычта утырам. Автобус түгелме соң бу? Шул, үзе. Әнә шофер утыра.

Минем селкенгәнне күреп бер апа:

— Улым, хәлләрең ничек соң? Без аралап калмасак бөтенләй имгәтеп ташлыйлар иде бит, звирләр! Дипломатыңны гына алып калып булмады, чаптылар. Акчаң күп идеме соң? — дип сорады.

— Юк, апа. Кәгазьләр генә. Рәхмәт сезгә!

— Ярый, улым, үзең исән булгач анысы гына табылыр.

Ну, Рәкыйп, синең шундый икәнеңне элегрәк белгән булсам. Нинди кабахәт кеше булып чыктың. Башта Гамилне күреп кисәтеп куярга, аннан ни генә булмасын, Рәкыйпне эзләп табачакмын. Мин ул интеллигент булып кыланып маташкан урам этен акылга утыртмасам, бернәрсәгә яраксыз булып калачакмын. Аннан миңа фаҗигале төстә үлгән адәм балаларына бәетләр чыгарып ятарга гына кала.

Казанга якынлашабыз. Гамилне каян тотып булыр икән? Эшендәме, өендәме, бакчадамы? Атна уртасында бакчада ятмас ич.

Гамил — минем күптәнге дус. Ул университетны бетергәнче үк милициягә кереп, ярыйсы гына эшләп ята. Вакытында дәрәҗәсен алды, фатирын, бакчасын. Машинасы бар, аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче. Майор. Без аның белән бергә бокс түгәрәгенә йөрдек.

Гамилгә шалтыратканда, ул, бәхеткә каршы, өендә булып чыкты. Минем тавышны ишеткәч:

— Кая югалдың син, абзый, — ди. Без үзебезчә бер-беребезгә абзый дип эндәшәбез. Мин аңа бер җитди эш бар икәнен әйткәч, сөйләвемне сорады. Ләкин бу турыда телефоннан сөйләшергә ярамый иде, без очрашырга булдык.

Ярты сәгатьтән мин аның белән кухняда кофе эчеп утыра идем. Мине тыңлап бетергәч, ул: «Әллә кайларга барып кысыласың син, абзый. Ярый, хәзер боз кузгалган инде, ахырынача барырга кирәк. Миңа калса, аларны син нык куркыткан. Сак бул! Алдыңны-артыңны карап йөр! Хәзерге заманда кеше гомере берни тормый. Теге Илсур янына берәр көнне икәү барып килербез», — диде.

Минем эчкә җылы кереп китте. Ул минем сүзне элек тә аяк астына салып таптамый иде, Аллага шөкер, бүген дә шулай булды.

Өйгә кайтып барам. Башта мең төрле уй. Иртәгә ничек тә булса Рәкыйпне эзләп табарга кирәк. Кичектермичә. Адресны белешмәләр өстәленнән алып булыр шикелле. Таба алырга тиешләр. Шулай да башта Гамил белән киңәшергә булыр. Менә үзебезнең кварталга җиттем. Кайтып яхшылап ял итәргә дә, иртәгә иртүк эшкә керешергә кирәк.

Үзем атлыйм, үзем каяндыр үкереп өскә машина килгәнен сизәм. Бөтен көчемә сикереп, тайпылып калдым. Теге машина ничек килгән, шул көе үкереп узып та китте.

## VII

Иртән телефон шылтыраган тавышка уянып трубканы алдым. Кем булыр бу?

— Әй, син! Яхшылап тыңла, — ди. — Әгәр тагын кирәкмәгән җирләргә кысыласың икән, син күз алдыңа да китерә алмыйсың ни булачагын, аңладыңмы?

— Аңладым, — мин әйтәм.

— Аңласаң шул, тыныч кына яшә, башкаларга да комачаулама. Без хәзер синең һәр адымыңны күзәтәчәкбез, — ди.

— Рәхмәт!

— Син нәрсә, козел, шаяртып сөйләшәсең. Ярты сәгатьтән тагын шылтыратачакбыз, уйла.

— Кирәкми, акчаңны әрәм итмә.

— Без шаяртмыйбыз, тварь!

— Ә нигә шаяртмыйсыз?

— Ну, кара аны, шакал, үзеңә үпкәлә! — дип, теге трубканы куйды. Әллә артыграк кыланып ташладым инде. Минем бу телне кисеп кенә ыргытырга. Гамилне кисәтим әле. Тик ул да урынында булып чыкмады. Тукта, эшеннән кайтканын көтәргә кирәк. Мин китәргә җыенып йөргәндә ишек кыңгыравы шалтырады. Әкрен генә барып, ишек күзеннән карыйм. Ниндидер ике ят адәм басып тора. Кире аяк очларына гына басып, балконга чыксам, аннан өскә дә, аска да, янга да китеп булмый икән. Мин бау эзли башладым, ә тегендә, ачкыч яратып, ишек ачарга маташалар. Менә мин инструментлар шкафыннан бау табып алдым. Кире залга узганда, тегеләр ишекнең ачкыч белән бикләнгән йозакларын ачканнар, эчтәге бикне, каерып керергә азапланалар иде. Балконда бауны бәйләргә ыграк урын эзләп кабаланганда бавым кулдан ычкынып аска төшеп китмәсенме. Беттем! Нишләргә? Ишекнең бигe менә-менә каерылып чыгарга гына тора. Аны-моны уйлап торырга вакыт калмаганлыктан, йокы бүлмәсенә кереп карават астына чумдым. Озак та үтмәде, теге ике бәндә ишекне җимереп, эчкә дә үттеләр. Йа Ходаем, үзең сакла! Ичмасам, берәр төрле корал-мазарым да юк. Тегеләрнең тавышлары ишетелә.

— Балкон ишеге ачык. Чыннан да моннан шылган. Аста төшкән бавы да ята.

— Алайса тизрәк, ерак китә алмагандыр әле ул!

Менә алар чыгып киттеләр. Аяк тавышлары тынгач, әкрен генә балконга чыгып, ярыктан аска күз салсам, тегеләр өй янында кая барырга да белмичә аптырашып торалар. Кара курткалысы:

— Ычкынды, ахры. Әз генә соңга калдык. Яңадан эзенә төшәргә кыенрак булачак. Ярый, киттек. Барыбер өенә кайтачак, — диде. Алар юл кырыенда торган ак төстәге «Волга» машинасына таба киттеләр. Мин ничек кенә тырышсам да, номерын күрә алмадым.

## VIII

Гамилне эзләп тапканда кичке сәгать алтылар тулып килә иде. Ул мине тыңлап бетергәч:

— Ярый, алайса бездә торып торырсың. Теге ике кешенең йөзләрен хәтерләп калмадыңмы? — дип сорады.

— Рәтләп карап булмады шул. Ну, «Волга»лары ак төстә иде.

— Шәп! Хәзер меңләгән ак «Волга» арасыннан табарсың инде син аны. Йә, ярый, авызыңны салма, әйдә, кайтып капкалап киләбез.

— Ә Илсур янына?

— Анда барудан әле бернинди мәгънә күрмим. Аның үтермәве билгеле бит инде. Синең арттан бөтенләй башка кешеләр эзәрлекли. Шуңа күрә бу эш ачыкланганчы, бик күзеңне акайтып, авызыңны ачып йөрмә. Бераз өс-башыңны үзгәрт. Күзлек ки. Чәчеңне кистер, поп булырга җыенмыйсыңдыр?!

— Чәчне? Соң болай да ярты баш пеләшләнеп килә.

— Аннан бөтен белгәннәреңне минем ярдәмчегә сөйләрсең. Үзеңнән чыгып берни эшләмә! Аңладыңмы, абзый!

— Аңладым, абзый!

## IX

Иртән Гамил эшкә китүгә мин горсправкадан Рәкыйпнең адресын эзләтеп алдым. Аннан Флераны күптән күргән юк. Ул минем өйләнергә йөргән кыз. Аны күреп аңлашып алырга кирәк. Мине күргәч, Флераның авызы кыегайды.

— Бөтенләй килеп йөрмәсәң дә ярый иде. Өч көн буе ни исәнме, ни сау бул.

— Мин командировкада идем, Флера.

— Соң син түләүсез ялда түгелме?

— Шулай да... Бер эш килеп чыкты.

— Миңа әйтеп китәргә буладыр иде бит.

— Була иде дә...

— Аңлашылды... Тагын берәр хатын-кыз белән чуалгансыңдыр инде?

— Юк, дим.

— Булды, җитте! Инде 30 га җитәм сине көтеп. Хуш! — дип, Флера борылып китеп барды.

— Флера, тукта әле!

Ул, артына борылып та карамыйча, үзе эшли торган идарәгә кереп китте. Үпкәләгән. Аның белән аңлашырга да вакыт юк. Ярый, соңыннан. Хәзер иң мөһиме Рәкыйпне эзләп табарга, табып телен ачарга кирәк. Шул уйлар белән мин 9 нчы трамвай тукталышына киттем. Беломорский урамында тора теге хәсрәт. Тукталыштан ерак түгел икән. Йорты «хрущевка»ның 3 нче катында булып чыкты. Ишек кыңгыравына басам. Эчтә аяк тавышлары ишетелә. Бикләвечне ачалар. Ишектә Рәкыйпнең суырылып калган йөзе күренде. Бер мәлгә ул аптырап калды, аннан бар көченә ишекне ябарга көчәнә башлады. Тик аңа кадәр мин сул аякны ишек арасына куярга өлгергән идем. Бар көчемә ишекне этеп, бүлмәгә бәреп кердем. Теге мөртәт атылып идәнгә барып төшмәсенме. Мин Рәкыйпнең якасыннан тотып күтәрә башладым, ул минем беләкне тешләде.

— Ах, кабахәт, әле син тешлисеңме, — дип, уңлап-суллап моңа китереп томыргач, теге үкереп елап җибәрмәсенме. — Сезгә миннән нәрсә кирәк, нәрсә? Ник миңа тынычлык бирмисез? Ник?

— Син, тере хәсрәт, Айсылуны кем үтерде? Әйт, кем? — дип, мин Рәкыйпне буа башладым. Теге тыны кысылган килеш:

— Каян белим мин аны? Ул соңгы вакытта миннән качып йөри башлаган иде. Авылларына да качып кайтып китте. Шул кирәк аңа, кайтмасын иде. Алдакчы, себерке ул. Минем бөтен сәламәтлегемне бетерде. Оятка калдырды. Инде без өйләнешергә тиеш идек. Балдаклар, күлмәкләр алдык. Әти-әни туйга әзерләнде. Ә ул теге бандиты төрмәдән чыгуы булды, сәгате белән үзгәрде. Сука... Шул кирәк аңа! Минем каргыш төште!..

— Кем үтерде аны, кем? — дип, мин тегене ыграк кыса башладым. — Кем, әйтәсеңме, юкмы? Югыйсә бетәсең. Сине беркем коткара алмаячак.

— Мин үтермәдем аны, мин, ми...

Тегенең тыны кысылганнан-кысылды.

— Кем? Кем, дим? Илсурмы?

— Белмим.

— Алайса ни өчен районда йөрдең? Кунакханәгә утны кем төртте?

— Мин бернинди кунакханәне дә белмим. Районга тикшерүче Әскәров чакырткач кына бардым.

— Нәрсәгә?

— Ул миннән бер-беребезне ярата идек, өйләнешергә йөрдек дигәч, тагын бер язу яздыртты.

— Ә син яздың инде.

— Язмыйча кая барасың? Ул, әгәр кул куймасаң, үзеңне үтерүче санап кулга алабыз, — диде.

— Син яздыңмы, хайван?

— Кая бара алам соң мин? Мин бит бик йомшак кеше...

— Йомшак түгел, куркак кеше син. Шул язуны язып, син Илсурны бөтенләй батырганыңны аңлыйсыңмы?

— Белмим, мин бернәрсә аңламый башладым. Тимәгез миңа! Мин бик бәхетсез кеше.

— Рәкыйп, шулай да кем үтерде Айсылуны? Син дә түгел, Илсур да түгел. Син бит нәрсә булса да белергә тиеш.

— Юк, белмим. Аңлыйсыңмы, белмим. Бәлки, Фурсилә беләдер.

— Ул кем тагын?

— Айсылуның тулай торакта бергә торган кызы.

— Кая тора?

Ул миңа торып адрес язып бирде. Үзе дер-дер калтырый. Минем бу өтек шагыйрьдән күңел болгана башлады. Университетта әллә кем булып төрле җәмәгать эшләрендә катнашкан, укытучыларга ялагайланып йөргән бу адәм кызганыч түгел иде миңа. Адресны кесәгә тыккач, күзлекне кидем. Димәк, бу мөртәт тә үтермәгән. Шулай да Илсурны утыртышырга булышкан. Ярый, чәнчелеп китсен! Озакламый мин Фурсиләне эзләп, автобуста бара идем инде. Эш тагын да катлауланды. Үтерүче билгесез... Автобус миңа кирәкле тукталышка да килеп җитте. Тулай торакка кергәч, вахтада утыручы апа миннән:

— Кем буласыз? — дип сорады.

— Бергә укыган идек, — дидем.

Сәгать кичке уннан да соңга калмыйча чыгыгыз. Әгәр тоткарлансагыз, паспортыгызны милициягә тапшырам.

— Аңлашылды, апа.

— Аңлашылса, барыгыз!

Башка тулай тораклардагы кебек үк монда да вахтер утыра, бар нәрсәңне төрмәдәге кебек тикшерә. Ничек кенә тикшерсәләр, сакласалар да, барыбер монда да Рәсәй икәнлеге сизелеп тора. Этаж саен чүп, сасы ис, стеналарында оятсыз сүзләр. Бар тулай тораклардагы кебек лифт эшләми. Бүлмәләрдән музыка, сүгенгән, чәрелдәп көлгән тәрбиясез, әнчек кызлар тавышы яңгырый... Кирәкле ишекне шакуга, эчтән, керегез, бикле түгел, дигән йомшак кына тавыш ишетелде. Ишекне ачып эчкә үтсәм, анда сары чәчле, ябыграк кына бер кыз кер үтүкләп маташа. Мине күргәч, аптырабрак калды.

— Исәнмесез! Гафу итегез, сез Фурсиләме?

— Әйе, мин ул. Ә сез кем буласыз?

— Ничек дип әйтим. Гафу итегез, бәлкем, утырып сөйләшербез?

— Утырыгыз.

Ул шулай дип, дивандагы керләрен алып, өстәлгә куйгач, мин утырдым. Кыз миңа аптыраулы, шикле караш ташлап:

— Әйе, тыңлыйм сезне, — диде.

— Ничек дип әйтим икән, сез Айсылу белән бер бүлмәдә яшәдегезме?

Фурсилә ничектер сискәнеп киткәндәй булды. Ул миңа курку катыш сораулы караш ташлап, пышылдап кына:

— Әйе, — диде.

Гафу итегез, сез аны соңгы тапкыр кайчан күрдегез?

— Авылга кайтасы көнне, — диде ул, теләр-теләмәс кенә.

— Аның сезгә берәрсенең янавын, йә булмаса куркуын әйткәне булмадымы?

— Юк, белмим, әйткәне булмады кебек.

— Рәкыйптән башка бүтән кеше белән очрашмый идеме?

— Юк, Илсур төрмәдән чыкканчы Рәкыйп белән яхшы гына йөрделәр. Соңыннан, элеккеге мәхәббәте яңарып, Илсур янына ял саен авылга кайта торган булды.

— Сез Илсур үтергән дип уйлыйсызмы?

— Белмим, әйтә алмыйм.

Шулай да Фурсиләдә ниндидер эчке киеренкелек сизелә. Күзләрен еш-еш йома. Нидәндер каушый.

— Соңгы көнне Айсылу авылга үзе генә киттеме?

— Әйе...

Шулай да бу кызның нидер әйтеп бетермәгәнлеге күренә. Ничек итеп телен ачарга, ничек? Мин үземнең сорау алуымны дәвам итәм.

— Айсылу авылга киткәндә Рәкыйп монда идеме соң?

— Әйе.

— Алар ничек аерылыштылар?

— Рәкыйп ялынып карады. Әти-әниләре туйга әзерләнгәнен, бөтен авыллары аның туе булачагын белгәнен әйтте. Оятка калдырма инде, дип ялынды.

— Ә Айсылу?

— Айсылуның күзләрендә яшь иде. Бертуктаусыз гафу үтенде. Рәкыйпнең бик ошаганын, тик Илсурны яратуын аңлатты.

— Рәкыйп аны озата киттеме?

— Юк. Тулай торак төбендә калды.

— Шуннан?

— Рәкыйп үксеп елый-елый өенә кайтып китте.

— Шул гынамы?

— Әйе.

— Син бернәрсә дә төшереп калдырмадыңмы?

Фурсилә өстәл өстендәге керләренә капланып елый башлады.

— Тынычлан, сеңлем, тынычлан!

Мин аңа чәйнектән су салып эчердем. Бераздан ул, шактый гына тынычлангач:

— Абый, зинһар, миңа бәйләнмәгез, зинһар! Мин сезгә барысын да әйттем. Башка берни дә белмим. Зинһар, минем үземне генә калдырыгыз, — дип, калтырый башлады. Шулай да бу кыз нәрсәдер белә, ниндидер хәлне яшереп калдырган кебек тоела. Мин тагын аның телен ачарга омтылып:

— Сеңелем, син яхшылап уйла! Кеше үтерелгән! Икенче гаепсезе төрмәдә. Ике гөнаһсыз кешенең бәхете киселгән. Ниндидер кабахәт җан иректә йөри. Ашый-эчә, ләззәтләнә! Айсылу япь-яшь килеш гүрдә ята. Уйла яхшырак, иптәш кызыңның каргышы төшмәсен, дим.

— Юк, дим, абый. — Бүтән берни дә ала алмаячагымны аңладым. Йә ул чынлап та бернәрсә белми, йә булмаса аны куркытканнар.

— Яхшы, мин китәм, сеңлем. Сиңа телефон номерын калдырам. Бу бик яхшы тикшерүченеке. Әгәр берәр әйтер сүзең булса, шылтырат, курыкма. Кирәк чакта без сине яклый алачакбыз, тик ышан гына.

Телефон язылган кәгазьне диван өстенә куйгач, мин Фурсиләгә карадым. Ул, мескен, бер сүз дә әйтә алмыйча, калтырап тик тора иде. Мин әкрен генә ишекне ябып аска төшеп киттем. Астагы апа паспортны биргәч, арттан:

— Инде әллә кайчан өйләнергә вакыт үзенә, ә ул һаман тулай торакка чаба, — дип калды.

— Әби, тулай торакка йөрсәм дә, синең янга түгел бит, — дип чыгып киттем. Соңрак барыбер эчтән борчылып, нигә кирәк инде шул надан бер хатын белән әйткәләшергә, дип уйладым.

Бүген Гамил өйгә кайтмады. Икенче көнне туп-туры Гамилнең эш урынына юнәлдем. Ул мине күрүгә:

— Синең теге Рәкыйп дигәнеңнең фамилиясе Гайнуллин түгелме? — дип сорады.

— Әйе. Адресы да бар.

— Ничек?

Мин аңа адресны кабатладым. Ул миңа бераз карап торды да:

— Аны кичә үтергәннәр. Туганнары хәбәр итте. Зур микъдарда наркотик кадаганнар. Көч кулланган урыннары күренеп тора. Шактый гына каршылык күрсәтеп маташкан,— диде.

— Әле кичә генә исән килеш күрдем мин аны.

— Күрдеңме?! Йә, нәрсә ачыклап кала алдың?

— Миңа калса, ул үтермәгән. Шулай да нәрсәдер белә кебек тоелды.

— Менә шул белүе башына җиткән дә инде аның. Шаһитларны юкка чыгару бара. Тагын кайларда булдың, абзый, — дип, бу миңа ирония белән дәшә. Күз алдына Фурсиләнең ябык гәүдәсе килде. Юк, юк, булмас ла, шул чебеш хәтле генә кызга кул күтәрергә! Юк! Гамил, каһәр, сизә минем нидер уйлаганымны.

— Булдым инде шунда.

— Тизрәк сөйлә!

— Айсылуның бүлмәдәш кызында.

Гамил бүлмәдә утырган шоферына:

— Сәфәров, машинага, киттек тизрәк! Бәлкем әле исәндер, кем белә, — дип боерык бирә.

Ике-өч минут үтмәгәндер, сержант Сәфәров машинасы тулай торакка таба чаба иде, мин юлны күрсәтеп барам. Вахта әле алмашынып өлгермәгән икән, теге апа мине күргәч:

— Ә, яңадан килдеңме? Кичә нәрсә дип киткән идең әле, бәбкәм?! Керми генә тор әле, яме! — диде.

Апа минем ялынганны көтеп, ахры, кыегаеп ук утырды. Шунда Гамил, апага:

— Җиңги, мин — тикшерүче майор Гарипов, — дип, таныклыгын күрсәтте. Апа рөхсәт бирде. Чабып менеп Фурсилә бүлмәсенең ишеген шакыйбыз. Җавап бирүче юк. Безнең арттан теге апа да менеп җиткән.

— Апа, Фурсилә тулай тороктан чыгып китмәдеме?

— Киткәне күренмәде.

Гамил кырыйда басып торган шоферына:

— Сәфәров, ват ишекне! — диде.

Сержант, ишекнең тоткасын кулы белән ныклап тотып, җилкәсе белән бар көченә эчкә этте. Ишек ачылып китте. Идәндә ябык гәүдәле Фурсилә бөгәрләнеп ята иде. Аны кичә үзе үтүкләгән сөлгесе белән буып үтергәннәр. Гарипов кызның кулын тотып карагач, авыр сулап:

— Монда да соңга калдык, — диде.

Бу хәлләрне күреп торган апа:

— Йа Алла, ул баланың кемгә зыяны тигән икән инде, — дип кычкырып елап җибәрде.

Гамил, шоферына борылып:

— Сәфәров, бар, рациядән экспертларны чакырт! Ә син, апа, әйт әле, кичәме, бүгенме бу бүлмәгә кемнәр керде?

Апа:

— Йа Алла, балакаем, йа Алла, — дип ухылдаганнан соң, менә бу иптәштән башка кергән кеше булмады, — дип, миңа карады.

— Апа, алайса үтерүче каян кергән булырга мөмкин?

— Соң, кайчакта икенче этаждан менеп кергәлиләр.

Гарипов, апага:

— Күрсәтегез, — дип, миңа борылды. — Син монда гына кал, бернәрсәгә кагылма, кеше кертмә, — диде.

Мин идәндә ятучы кемнеңдер кадерле баласы булган Фурсиләгә карап тора башладым. Бу кыз миңа бигрәк тә кызганыч иде. «Их, кызый, нәрсә өчен үтерделәр икән сине? Бар белгәнеңне үзең белән алып киттең бит, сеңелем! Ә үтерүче иректә». Бераздан Гамил кереп:

— Икенче каттан кергәннәр, абзый. Эш әле башлана гына. Ике шаһит юкка чыгарылды. Нидән башларга, бер Ходай гына белә. Әгәр монда да ябышырлык дәлил табылмаса, кыенга туры киләчәк, — диде.

Безнең монда килгәнгә өч сәгатьләп вакыт үтсә дә, эш башларлык чыганак табылмады. Тикшереләсе тикшерелеп беткәндә Гамилнең кәефләр шәптән түгел иде. Ул миңа карап, үзең күрәсең, әлегә ябышырлык әйбер табып булмады дигәндәй җилкәләрен җыерып куйды. Бераздан Фурсиләне моргка алып киттеләр. Гамил тикшерүче экспертка:

— Әгәр берәр мөһим нәрсә чыкса, шундук хәбәр ит, — дип, миңа баш белән генә ымлап, ишеккә юнәлде. Ишек төбендә бер көтү кеше җыелган, хатын-кызларның кайберләре елашып тора иде.

Гамил өйгә кайтып җиткәнче ник бер сүз әйтеп карасын. Минем сорауларга да «юк», «ярар», «карарбыз» кебек җаваплар гына бирде. Әле аны мондый хәлдә күргән юк иде. Бер көнгә ике мәет! Күп түгелме? Өстәвенә, Гамил бу эшкә минем аркада кереп батты. Мин үземне гаепле сизәм. Ул да минем уйларымны аңлаган кебек: «Кайгырма, абзый, нәрсә булса да килеп чыгар әле. Кайсы вакытта бөтенләй көтелмәгәнчә була. Иң яхшысы, хәзер кайтып ял итик, иртәгесе көн, бәлкем, берәр нәрсә күрсәтер», — дип тынычландырды.

Минем күз алдымнан һаман ябык Фурсиләнең бөрешеп каткан кечкенә гәүдәсе китми. Ачудан тешләрем кысыла. Бер гөнаһсыз бу кызга кул күтәргән явызларга Ходай Тәгалә бер күрсәтер әле үзләренә дә. Күрсәтми калмас.

## XI

Иртән телефон шылтыраган тавышка беренче мин сикереп тордым. Трубкадан майорны сорадылар. Мин Гамилне чакырып, трубканы аңа тоттырдым. Бераздан ул җиңел сулап куйды, соңыннан миңа карап:

— Ябышырлык әйбер чыгар кебек, абзый, бар, каты итеп чәй пешер әле, син аны шәп кыландырасың, — дип, ванна бүлмәсенә юнәлде.

Мин чәй куярга киттем. Чәйнекне газ өстенә куйгач, кайнап чыкканчы буш вакыт бар әле дип, Флерага шылтыратырга булдым. Вакыт 8 сәгать 10 минут, димәк, эшендә булырга тиеш. Ничек итеп җайларга икән үзен? Трубканы Флера үзе алды.

— Кем бу? — дип сорады.

— Мин әле бу, Флера! Ник дәшмисең?!

Ул шактый гына паузадан соң:

— Нәрсә, тулай торакларда йөрүдән туйдыңмы? — дип куймасынмы. Мин эшнең әле ни турында барганын да төшенеп бетермичә:

— Нинди тулай тораклар? — дип сорагач, ул миңа ярсып:

— Хәниф, синең кебек аферистны минем әле очратканым юк иде, — диде.

Мин аңа:

— Туктале, Флера, аңлатканны көт, мин бит анда эш белән генә кергән идем, хәзер аңлатам, — дидем. Ул тагын да котырыбрак:

— Бүтән шылтыратасы булма! — дип, трубканы ташлады. Каян күреп торалар диген, инде минем тулай торакта булганны да ишеттергәннәр. Нинди тар бу дөнья! Әй, чукынып кына китсен лә, утызга җитте, ә акыл кермәде. Шулай була ул, әби-бабай, әти-әнигә иркә бер кыз булгач.

## XII

Азат бүген мәдәният институтында укучы ике кызны «Казан утлары» ресторанына алып килде. Әйбәтләп ял итеп алырга иде нияте. Кызларның берсе аның күптәнге танышы Оля булса, икенчесе Оляның иптәш кызы Оксана иде. Азат бу бәйрәмне Оксана өчен оештырды. Олядан иптәш кызың Оксана белән кил дип үтенгәч, Оля аңа: «Нәрсә, ошадымы әллә, ә мине кая куясың?» — дип карышты. «Йә, бала-чага булма әле, син бер генә көнгә Илшат белән ял итәрсең инде, яңа әйбер яңача була инде ул», — дип, Оляны күндерде. Аннан Оля да, егетнең кирәк чакта үзен төрле эшләргә кулланауына күнеккән иде. Азатның үтенечен кире кагасы килмәде, чөнки Азат аңа еш кына кыйммәтле бүләкләр биргәли, кирәк чакта машинасы белән авылына да алып кайтып килгәли иде.

Өстәлгә коньяк, ак аракы, фанта, йөзем, груша куелган. Азат дүртесенә дә коньяк салып чыккач:

— Әйдәгез, кызлар, сезнең белән дуслашу хөрмәтенә,— дип, савытын күтәрде. Барысы да бердәм эчеп куйсалар да, яңа кыз иренен дә тидермәде. Бу инде Азат өчен көтелмәгән хәл иде. Азат беразга аптырап калды, чөнки кызның эчмәве аңа ошамады. Ничек тә булса исертергә кирәк бу кыланчык сучканы, дип уйлады ул.

— Оксана, матурым, әз генә булса да эч инде. Безгә дә, үзеңә дә күңеллерәк булыр.

Кыз елмаеп:

— Юк шул, Азат, рәхмәт, мин бит бөтенләй эчмим! — диде.

— Йә, кыланма инде, Ксюша, монда бит чит кешеләр юк, гаеп итүче булмаячак, эч инде. Югыйсә без рәхәтләнеп ял иткәндә, син күңелсез утырачаксың. Оля, син дә кыста әле иптәш кызыңны!

Оля Оксананың аракы эчмәгәнен, эчмәячәген белсә дә, кыстаган итте:

— Оксана, әз генә булса да тотып куй инде, егетләрнең күңеле булыр.

Оксана, гаҗәпләнеп, Оляга карады:

— Соң, син, Оля, күпме генә кыстасагыз да эчмәгәнемне беләсең ич инде. Егетләр, сезгә бик зур рәхмәт! Ант итеп әйтәм, миңа сезнең белән эчмичә дә күңелле.

Кыз шомырт кара күзләрен чепелт-чепелт китереп барысына да күз салып чыкты. Азатның йөзе чытылган, Оля хәзер нәрсә булыр икән инде, дигән кыяфәт ясаган. Илшат исә, авызын кыегайтып, мәсхәрәле елмая.

Азат торып басып өч рюмкага кабат коньяк тутырды:

— Дуслар, әгәр дә чынлап та минем дуслар икәнсез, минем табынымны мыскыл итмәскә тиешсез. Әгәр дә инде, чыннан да, биредә мине дус итмәүче кеше бар икән, шул кеше генә эчмәсен!

Бар да эчеп куйды. Тик Оксананың гына рюмкасы ничек бар шул килеш калды. Азат гасабилана башлады. Аның ни хәлдә икәнен иптәше Илшат кына чамалый. Һәрбер кешенең аңа гына буйсынганын, ни теләсә шуны эшләргә яраткан Азатның хәзер берәр хәл эшләве мөмкин иде. Ни булыр икән, дип Илшат та тынып калды. Азатның планнары чәлпәрәмә килеп маташа. Шулай да ул соңгы ихтыяр көчен җыеп, кызга:

— Оксана дустым, йә хәзер син эчәсең, йә шушында безнең юллар аерыла! — диде. Азатны икенче тапкыр гына күргән, аның гадәтләрен белмәгән Оксана кызарып, гаепле кеше кебек ялварып:

— Егетләр, мин бит чынлап та эчмим, аңлагыз! Эчкәнем юк. Әгәр инде бераз шампанский гына булса, йотып куяр идем, — диде.

Азат урыныннан торды:

— Шампанский дисең инде алайса. Хәзер, ясап бирәм мин сиңа аны, — дип, ул өстәлдәге коньяк бутылкасын алып арт санына куйды, аннан шешәне кызга сузды. — Мә, эч, колхозница, мә, газланды хәзер, эч ванючка, — дип, шешәне кызның авызына көчләп тыга ук башлады. Оля сикереп торып Азатның кулына ябышты.

— Азат, нишлисең син, җүләрләндеңме әллә, кешеләр карап тора, тавыш чыгарма, зинһар! Илшат, әйт әле аңа!

Илшат исә, әле булып үткән тамашадан шаркылдап көлә иде.

— Соң, шампанский ясап бирде ич, тагын ни кирәк инде аңа, эчсен, ник эчмисең, овца безмозглая, эч инде, эч!

Оксана бу хәлләрдән телсез калды. Аның бу тамашадан еларлык рәте дә калмаган иде. Ул торып, беркемгә бер сүз әйтә алмыйча торгач, шок хәлендә залдан чыгып китте. Азат берни булмагандай зур бокалга ак аракы салып, бер сулышта эчеп бетергәч, Илшатка карап:

— Син Оляны озатырсың, минем кәеф юк, өйгә кайтып ятам, — дип ишеккә юнәлде. Ул залдан чыгып китүгә, Илшат иптәш кызы өчен кайгырып утырган Оляга карап:

— Әйдә, юк өчен кайгырып утырма, башта гына шулай кылана ул, соңыннан үзе үк эзләп йөри башлаячак. Азатны әйтәм, ну комик та инде, билләһи. Коньяктан шампанский ясап бирде бит, — дип шаркылдап көлә башлады. Оляның ачуы чыгып:

— Сезгә бөтен кыз бер инде. Оксанадан яхшы түгел, иртәгә ничек күзенә карармын. Әйбәт кыз ул. Эчми, тартмый. Минем кебекләр беткәнмени сезгә? Мәдәният институтында берничә генә андыйлар.

Илшат һаман шаркылдавын дәвам итте:

— Әйдә, оныт әле шул сучка турында. Барыбер берәрсенә бирәчәк. Башта гына кыланасыз барыгыз да. Оля, әйдә, сиңа кайтабыз

Оля сумкасыннан сигарет чыгарып кабызгач, төтенен Илшатның битенә җибәреп:

— Үзең кара, миңа барыбер, — диде.

— Алайса син урамга чыга тор, мин хәзер тагын берәр ярты алам да, куып җитәм. Такси тота тор, — дип, буфет ягына таба китте.

## XIV

Без Гамил белән 9 тулырга биш минутта Гамилнең эш урынында идек. Дежурныйны күргәч, Гамил:

— Йә, яңадан бер ачыграк итеп ни булганын сөйлә әле, — диде. Лейтенантның дикциясе бик начар иде. Негрларныкы кебек калын иреннәре гаепле булгангамы, әллә бик нык ашыгып сөйләгәнгәме, сүзләр йотылып, аңлашылып бетми. Шулай да аның сөйләвеннән шуны аңладык. Имеш, ниндидер бер кыз шылтыраткан. Фурсиләнең дус кызымы ди. Исемен, кем икәнлеген әйтмәгән. Айсылуның үләсе көнне үз авылы егетләре машинасына утырып китүен әйткән. Берсенең исеме Азат, икенчесенең Илшат икән.

Гамил, дежурныйга якын килеп:

— Ул кызны тиз генә табарга кирәк! — диде.

Лейтенант кызның үзен эзләмәүләрен, бөтен белгәнен әйткәнен, башка берни дә белмәвен, үзен бу эшкә катнаштырмаска үтенгәнен әйтте.

Гамил лейтенантка:

— Рәхмәт сиңа, туган, ярый, ул кызга монысы өчен дә рәхмәт! Бәлкем, чыннан да үтерүчеләр шушы ике егеттер. Ябышыр урын бар. Сезгә китәргә мөмкин, лейтенант, — дип, сүзен йомгаклады.

Ярты сәгатьтән без Азат белән Илшатның авыл хуҗалыгы институтында укыганын, икесенең дә бер авылдан — Чишмәледән икәнен белә идек.

— Аңлашылды, үтерүчеләр билгеле, — дип куйдым мин, бик күп белгән, күргән кеше кебек.

— Ашыкма әле, абзый. Зинһар, хәзер син кысылып эшне боза күрмә. Миңа калса, эш шактый катлаулы. Аларның бик зур ярдәмчеләре булырга мөмкин. Шулай җиңел генә күпме кешенең башына җитә алмаслар иде. Сак булырга кирәк. Бар эшне алар көтмәгәндә эшләргә. Шул чакта гына без отачакбыз. Аларга хәзер сулыш алырга да ирек бирергә ярамый! Булды, әйдә, хәзер кайтып чәйләп килик, — дип, Гамил урыныннан кузгалды.

## XV

Икенче көнне мин Гамил белән өйне карап килергә булдым. Ишекне ачып бүлмәгә керсәк, анда бар әйбер чәчеп ташланган, ватыласы ватылган. Гамил бүлмәне карады да:

— Да, малай, кыйммәткә төште бу эш сиңа. Ярый, кайгырма, башың исән булса, калганы табылыр, — дип куйды.

Мин идәндә яткан язу машинасын алып, өстәлгә куйдым. Бүлмәне тагын бер кат күздән кичергәч:

— Ярый, Гамил, әйдә, китик. Мондагы эш әле миңа бер айга җитәчәк, — дип, ишеккә таба атладым.

Без урамга чыгып өлгермәдек, юл кырыенда туктап торган ак «Волга» кинәт газ биреп кузгалып китмәсенме. Мин Гамилгә:

— Әнә теге машина, — дип әйтергә өлгермәдем, ату тавышы яңгырады. Гамил өскә сикереп мине җиргә аударды. Бер ун секунд яткач, без торып өсләребезне кага башладык. Мин Гамилгә:

— Бәлкем, куып тотып булыр, әйдә тизрәк машинага! — дип, кабалана башладым. Гамил елмаеп куйды.

— Хәзер куып тота алырбыз дип уйлыйсыңмы инде син аларны. Соң инде хәзер, абзый. Бу бит сиңа детектив кино түгел, анда гына ул көне-төне куышалар. Ярый, әйдә, отделга кайтабыз, берәр яңалык юк микән?

## XVI

Ә яңалык чыннан да бар иде. Ниндидер кызны көчләмәкче булганнар. Гамил өстәлендәге гаризаны карап чыккач:

— Тукта әле, тукта. Хәниф, теге Айсылуның авылдаш егетенең исеме дә Азат түгелме соң?

— Әйе.

Гамил өстәлдәге кәгазьгә бармагы белән төртеп:

— Соң, бу көчләргә маташучының да исеме Азат бит.

— Кызык. Яле, карыйм әле.

Гамил, миңа кәгазьне сузгач, кнопкага басты. Бераздан дежурный керде.

— Лейтенант, бу гаризаны язган кызны күрергә кирәк иде.

— Соң ул монда, китмәде әле.

— Алып кер алайса!

— Яхшы. Тик ул үзен бик начар хис итә. Бераз җайлабрак сөйләшегез инде!

— Яхшы, бар, алып керегез, лейтенант!

Ишектә башта лейтенант, аның артыннан зыян күрүче кыз күренде. Гамил кызның каршысына барып:

— Узыгыз, уз, сеңелем! Менә монда утырыгыз! — диде.

Кыз Гамил күрсәткән җиргә барып утырды. Аның сул як күз төбе күгәргән, уң як ияге дә шешкән кебек тоела.

— Сеңелем, сез бар нәрсәне яшермичә, курыкмыйча сөйләгез.

Кыз ничек ресторанда утырганнарын, ничек аны аракы эчәргә кыстаганнарын һәм Азатның ничек итеп мыскыллаганын сөйләп бирде. Мин түзмәдем:

— Аларның исемнәре ничек соң, сеңелем? — дип сорадым.

— Берсе минем иптәш кызым Оля, икенчесе Азат һәм аның авылдашы Илшат, анысын Илюша дип кенә йөртәләр.

— Аңлашылды. Ә теге...

Шунда Гамил түзмәде, ирененә бармагын куеп, мине туктаткач, Хәниф, әлегә мин тикшерүче, дип, кызга эндәште:

— Рәхмәт, сеңелем! Үзеңнең исемең ничек соң?

— Оксана.

— Оксана, ә соңыннан ничек булды?

— Мин рестораннан чыгып, өйгә кайтып барганда, ул куып җитте. Үзен начар тотканлыгын аңлаганын әйтте, гафу үтенде. Соңыннан без Кабан күле тирәсенә килеп чыктык. Анда бер кеше дә юк, тыныч урын иде. Ул миңа яратам, миңа кияүгә чык, без бәхетле булачакбыз дип, үбә, җиргә яткыра башлады. Мин карышам, ә ул аның саен... Соңрак ул миңа уңлап-суллап китереп сукты. Ярый бәхеткә каяндыр кайтып килүче яшьләр төркеме күренде. Мин бар көчемә: «Коткарыгыз», — дип кычкыргач кына, ул торып йөгерде.

Оксана кабат кычкырып елап җибәрде. Гамил аның янына килеп, чәченнән сыйпады:

— Тынычлан, сеңелем. Син бик әйбәт кыз икәнсең. Барысы да әйбәт булыр. Шулай да, сеңелем, сиңа әлегә укырга йөрергә дә, тулай торагыңа кайтырга да ярамый. Минем фатир өч бүлмәле, шуның берсендә торып торырсың. Хатын белән малай авылда, алар бер атнадан соң гына килә. Аннан, Оксана, син ашарга пешерә беләсеңме? Безнең менә бу абыең белән инде күптән җүнләп ашаганыбыз юк. Үзең күрәсең, менә абыең ничек ябыгыбрак киткән, — дип, минем яңа гына төртеп чыга башлаган бүксәне чәбәкләп алды. Кыз бераз елмаеп куйгандай итте, күтәрелеп миңа карады. «Нинди матур күзләр бу кызда, нинди чибәр кыз», — дип уйлап куйдым мин.

— Йә, сеңелем, син ризамы инде безнең шартларга?

— Әйе, абый.

— Алайса менә бу абыең сине хәзер өйгә озатып куяр. Сазаган егет булса да, ышанычлы кеше. Яше утызга җитсә дә, типсә тимер өзәр чагы әле. Йә, ярый, анысын үзең карарсың инде. Хәниф, нәрсә, агач матрос кебек каттың, озат кызны өйгә.

— Хәзер нитәбез. То есть, кайтабыз.

Гамил миңа карап-карап торды да:

— Ә нәрсә, ошыймы әллә бу кыз сиңа, бөтенләй телсез калдың. Матурлыкны күрә беләсең тагын үзең. Сеңелем, башын әйләндер әле шул язучы кисәгенең. Күптән күзле-башлы булырга вакыт инде аңа!

Чыннан да, бу кыз миңа ошаганнан-ошый бара. Тик яшь аралары гына шактый булырга тиеш безнең. Бер 8—10 яшькә тарта бугай. Шулай да, урыслар әйтмешли, шайтан ни белән шаяртмас. Гамилнең, ахры, бөтенләй түземлеге бетте:

— Бетердең, Оксана, малайны, болай да хатын-кыздан коты алына иде, сине күргәч бөтенләй чәчелде.

Кыз беренче мәртәбә матур итеп көлеп куйды. Мин бар кыюлыгымны җыйдым:

— Ярый, әйдә, ни, э, то есть, кузгалыйк.

Без урамга чыктык. Икебез дә бер сүз дәшмичә атлыйбыз. Мин үземне эчтән: «Булмаган тәре. Күпме хатын-кыз күрдең, ә бер яшь-яшь кыздан телсез калдың. Әйт инде шуңа бер сүз, агач матрос», — дип сүгәм.

— Оксана, ни, э, теге, сез миңа бик ошыйсыз. Гафу ит инде син мине, карт шайтанны. Әллә нәрсә булды сине күргәч, — дип ычкындырдым да куйдым. Тел белән әйткәнемә колакларым ышанмады. Ничек булды соң әле бу? Үзем сизәм, битем генә түгел, бөтен тәнем кызарды кебек. Оксана миңа тутырып бер карады да:

— Сез дә миңа, — дип куймасынмы. Минем аяклар атла-

мас булды. Әллә ялгыш ишетәмме, — дип аңа карыйм. Ул исә, минем ни уйлаганымны аңлап алды бугай.

— Чынлап, Хәниф абый, — ди.

«Алай булгач мин бит әле бөтенләй беткән кеше түгел икән. Димәк, әле мин күпмедер торам», — дип уйлап куйдым.

— Оксана, ә сез каян шулай татарча яхшы беләсез?

— Мин бит татар кызы.

— Керәшен кызымы?

— Юк, чын татар кызы, исемне генә әти шулай кушкан.

— Оксана, чык миңа кияүгә.

Кыз, минем сүзләргә аптырабрак карап торганнан соң:

— Хәзер үкме? — димәсенме. Мин аңа:

— Хәзер үк булмаса да, мин сезнең кулыгызны сорыйм.

Оксана минем шаяртып сөйләшмәгәнне аңлагач:

— Уйлап карарга туры килер, — диде.

Менә без, ниһаять, өйгә кайтып җиттек. Мин алдан, Оксана минем арттан баскычтан менәбез. Бәлки, чыннан да минем булачак кәләшем менәдер, кем белә? Ә Флера? Ярата идемме соң мин аны? Ошый, ләкин шуннан артыгы юк иде. Ә ни өчен йөрдем? Үзеңнең дә, кешенең дә вакытын алдың. Кемгә булса да өйләнергә кирәк булганга. Яшем утызга җиткәнгә. Аның ата-аналары дәрәҗәле кешеләр булганга. Флера үзе дә төскә-биткә күркәм булганга. Ләкин Оксана уяткан хисләрне Флера беркайчан да кузгата алмады. Мин үземне 18—19 яшьлек гашыйк хәлендә тоя идем.

— Оксана, теге хәшәрәтләрнең берсе кара күн куртка киеп йөрмиме?

— Әйе.

— Ак «Волга»лары да бармы?

— Бар. 42—02 номерлы. Азатныкы.

Минем өчен кайбер нәрсәләр ачык иде. Димәк, телефоннан шантаж ясаучы да, өйгә килеп эзләүчеләр дә шулар. Фурсилә белән Рәкыйпнең җанын кыючылар да шулар булуы бик мөмкин. Шунда Оксана миңа күңелсез уйларымны бүлеп:

— Хәниф абый, бәлкем, сезгә берәр нәрсә әзерләп бирергәдер? — диде.

— Яхшы булыр иде, тиздән Гамил дә кайтыр. Әйдә, кухняны күрсәтәм. Азык-төлек суыткычта, үзең карарсың, сеңелем.

— Хәниф абый, зинһар, миңа сеңелем димәгез. Оксана дисәгез бик җитә. Мин сез уйлаганча бик яшь түгел. 23 яшь була көзгә.

— Яхшы, Оксана.

Гамил кайтканда, без Оксана белән рәхәтләнеп йомырка тәбәсе ашап, чәйләп утыра идек. Ул безне күргәч:

— Сезнең эшләр пешкән бугай, дуслар. Миндә дә яңалык бар. Иртәгә Азатны кулга алабыз. Рөхсәт кәгазе кесәдә. Алар-

ның икесен дә үткән елны тулай тороктан куган булганнар. Хәзерге көндә Калинино поселогында ниндидер бер кешенең йортында торалар. Теге ак машина Азатныкы ди.

Мин эчтән: «Ничек болганчык булып тоелган эш, көтмәгәндә бетте дә куйды», — дип уйладым.

## XVII

Икенче көн иртәнге дүрттән торып, без Гамилнең эш урынына киттек. Анда бөтен әйбер әзер иде. Җинаятьчене тотарга 2 оперативник, махсус ротадан 2 метр да 20 сантиметр буйлы, 120 килограмм авырлыктагы Вася Слонны алдылар. Ул чыннан да куркыныч күренә. Аның башы гына да атныкы кадәр. Мин һаман аны күзәтәм. Ул үзе латыш малае икән. Ишекмазарны ватарга, куркыныч җинаятьчеләрне тотарга күбрәк ул бара ди. Аның хисабында дистәләгән уңышлы тәмамланган операция бар диләр. Вася минем бирелеп үзен күзәткәнне сизеп алды да, миңа карап:

— Яп авызыңны, карга кәк итмәсен, — дип куймасынмы. Минем уңайсызланып калганымны сизеп, шаркылдап көлеп үк җибәрде, әйтерсең лә айгыр кешни. Башкалар да борылып карады. Гамил:

— Вася, кешнәмәле, җинаятьчеләрне куркытасың, — дип шаяртып алды.

— Ярый, егетләр, әйдә, кузгалдык! — дип, команда биргәч, барысы да УАЗикка керә башладылар. Вася артка, без Гамил белән уртага утырдык.

Безнең машина олы юлдан борылып, поселокка юл тотты. Шоферның бу юлларны яхшы белүе сизелә.

Машина кирәкле урынга килеп җиткәч, Гамил:

— Син, абзый, шофер белән машинада гына кал, сез, егетләр, йортны арт ягыннан, без Вася белән алдан томалыйбыз. Йокыларыннан айныганчы бәйләп салырга кирәк. Илшатын каршылык күрсәтте дип алабыз. Чөнки аңа бәйләнерлек урын юк әлегә, — диде.

Ике оперативник Калашников автоматларын җайлап җилкәләренә салгач, йорт артына йөгерделәр. Йорт шактый таушалган, хуҗалары үзләре икенче җирдә торып, монысын фатирчыларга гына биреп торалар. Минем түземлегем бетте, машинадан чыгып Гамилләр артыннан киттем. Шофер гына арттан:

— Сак бул, анда бармасаң да ярый инде сиңа, анда атыш булырга мөмкин, — дип калды. Мин Гамил белән Вася киткән якка атладым. Гамил бер каен артына посып йортны күзәтә. Мине күргәч, ачуланып:

— Машинада гына утырсаң да ярый иде, абзый, — дип мыр-

лап куйды. Мин, Гамил янына посып, йортка күз салдым. Аның тәрәзәләрендә ут бар иде. Мин Гамилдән:

— Нишләп болар иртә тордылар икән? — дип сорадым.

Гамил миңа борылып:

— Эчтә ниндидер ят бәйрәм бара. Туры килә бит анасын сатыйм. Ничә кеше икән инде анда алар. Тагын бер-ике егетне аласы калган. Беркайчан да җиңел уйларга ярамый шул. Ярар, икенче вакыт сабак булыр. Өстәвенә, син йөрисең сөйрәлеп. Синең белән берәр хәл булса, ә, аңлыйсыңмы, нәрсә дип әйтим мин туганнарыңа? — диде.

— Гамил, бәлкем, берәр ярдәмем тиеп куяр, ә?!

— Тик монда түгел, кайткач кухняда табак-савыт юганда булышкан булыр идең.

Мин Гамилнең юморларын яхшы белгәнгә, әллә ни үпкәләмәдем. Ләкин бүтән дәшмәскә булдым. Бераздан Вася, урамда өелгән утыннар артыннан чабып чыгып, капканы тибеп ачты.

— Син шушында гына кал, селкенәсе булма! — дип, рәшәткә баганасының артына барып чүгәләгәч, өйдәгеләргә: — Әй, өй эчендәгеләр, мине тыңлагыз, йорт камалган, кулларыгызны баш артына куеп берәм-берәм урамга чыгыгыз! Кем дә кем каршылык күрсәтә икән, кисәтеп тормыйча атачакбыз! — дип кычкырды.

Өй эчендә ут сүнеп, тавышлар тынып калды. Бераздан эчтән:

— Әй, сез кемнәр, нәрсә кирәк сезгә? — дигән тавыш ишетелде.

— Без оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш бүлеге хезмәткәрләре, иң яхшысы, каршылык күрсәтмичә бирелү! Сез барыгыз да вакытлыча кулга алынасыз!

Гамил кычкырган якка мылтыктан аттылар. Рәшәткәнең йомычкалары очып тирә-якка чәчелде. Гамил кире багана артына посты.

— Әй, коралларыгызны ташлагыз, шаярмагыз! Үзегезнең хәлегезне генә начарлыйсыз! Тагын биш минуттан чыкмасагыз, ут ачабыз! Вася, әзер булып тор!

Вася, яхшы дигәндәй, сул кулын өскә күтәрде. Вакыт бик әкрен үтә. Ә ишектән чыгарга җыенучы күренми. Гамилнең дә нервыланганы сизелә. Ул бер сәгатенә, бер өй ягына күз сала. Ләкин тегендә тынлык. Ниһаять, вакыт җитте, ахры, Гамил Васяга кул селекте. Теге гигант шуны гына көткән иде, күрәсең, уң аягы белән борылып ян тәрәзәгә китереп тибүе булды, тәрәзәнең рамнары сынып, пыялалары чәчелде. Эчтән тагын ату тавышлары яңгырады. Вася, «лимонка» кебек бер әйбер чыгарып, ватык тәрәзәдән тегеләргә томырды. Эчтә йөткергән, чабышкан тавышлар ишетелә башлады.

Вася кулын күтәрде, бу Гамилгә ниндидер билге иде. Шуны гына көткәндәй, Гамил пистолетыннан ут ачты. Аңа тагын арткы яктагы автомат кушылды. Ату тавышлары ничек кинәт башланса, шулай кинәт тынып та калдылар. Вася ату тавышлары тынып калуга, чолан ишеген ватып эчкә кереп югалды. Аның бу җитезлегенә карап, 120 килограмм дип әйтә алмассың. Бераздан Гамил эчкә ташланды. Өй эченнән Вася кычкырган,ниләрдер ауган, ватылган тавышлар ишетелде.

— Барыгызга да ятарга! Кемгә әйтәм, тараканнар, ятарга!

Аның куркыныч тавышыннан өй селкенгән кебек булды. Эчтә тагын ату тавышы яңгырады. Нәрсәдер ишелеп төште.

Мин кергәндә анда эш беткән диярлек иде. 4 бандит идәндә ята. Берсенең бите карарлык түгел, бөтенләй яньчелгән. Икенчесенең авызыннан кан ага. Өченчесе эчендәге пуля ярасын кулы белән томалап тоткан. Дүртенчесендә ул-бу күренми. Гамил бер оперативникның кулын бәйли, димәк, безнең дә яралanучылар бар. Вася һаман тынычлана алмый бугай, теге бите тетелгән бәндәнең башын идәнгә бәрә.

— Ну, ничек, атарга өйрәндеңме инде, тирес корты?! Өйрәндеңме, дим, хәшәп?!

Гамил Васяны тынычландырырга тырышып:

— Ярый, ярый, Вася, булды! Җитәр бүгенгә! — дигәч, идәндә ятучыларга карап: — Әй, сез, дебельләр, кайсыгыз Азат атлы, сезгә әйтәм?! Синме?!

— Юк, мин түгел. Мин Игорь.

Шунда икенче оперативник:

— Егетләр, монда без кергәнче күңелле генә бәйрәм булган икән, менә карагыз, — диде.

Ул тимер караватастыннан бер тартма тартып чыгарды. Анда шприцлар һәм кечкенә генә берничә пакетта ак порошок та бар иде. Гамил килеп порошокны бармак очына гына алып теленә тидереп карады. Шуннан теге бәндәләргә:

— Күңелле яшисез, егетләр, күңелле, — диде. Аннары наркотиклар белән шприцларны кире тартмасына салгач: — Шәп утырдыгыз сез дусларым. Ә хәзер, әйтегез, кайсыгыз Азат инде сезнең?! Азат дигәнегез торыгыз!

Тегеләрнең берсе селкенеп куйды.

— Ул монда юк. Ул качты, яңа гына.

— Ничек качты, кайдан?!

— Чоланда тагын бер ишек бар иде, ә сез, аңгыра ментлар, шуны да белмәдегезме?!

Гамил, ярасыз оперативникка карап:

— Әнфис, тиз генә карап кер әле, бәлкем, ерак китә алмагандыр. Әгәр дә качкан булса, рациядән машиналар чакырт, болар безнекенә генә сыеп бетмәячәкләр, — дигәч, оператив-

ник: «Яхшы», — дип, чыгып чапты. Гамил кабат теге кулга алынучыга борылды:

— Аңгыра ментлар, дисең инде алайса, син әйт инде хәзер, акыл иясе, үзеңне кем дип белик соң?

— Мин аның авылдашы Илшат. Юкка тырышасыз, майор. Безне иртәгә үк чыгарып җибәрәчәкләр. Ә сез эшегездән очачаксыз, ант итеп әйтәм.

— Бик яхшы, дустым! Бик әйбәт сөйлисең, һәм дә дөрес сөйлисең, рәхмәт! Вася, бу калган өч акыл иясенә наручниклар кидерегез дә, алып чыга торыгыз, мин менә төп акыл иясе белән сөйләшеп алам әле, — дигәч, миңа үзендәге наручникны сузды. — Мә, театр карарга килгән тамашачы кебек торма, булыш әнә егетләргә!

Мин теге яралыга наручниклар кидергәч, калган икесе аны җитәкләп Васяга ияреп урамга чыгып киттеләр. Алар артыннан кулындагы ярасы бәйләнгән оперативник та атлады.

Гамил теге Илшат дигән хәсрәткә:

— Абзый, синең өстә ике мәет ята, берсе Фурсилә, икенчесе Рәкыйп. Синең анда бармак эзләрең калган. Айсылуны үтерүчеләрнең дә берсе син булуы бик мөмкин, — диде.

Теге бәндә бераз каушап калса да, үзен кулга алып:

— Ә сез, дәлилләгез, мин сезгә ышанмыйм. Сез берничек тә дәлилли алмаячаксыз. Сез җиңелдегез, майор. Сез безне шушы порошок өчен генә утырта аласыз. Ә без бер айдан чыгабыз.

Шулчак оперативник Әнфис килеп керде:

— Иптәш майор, эзе суынган аның. Безнең шофер бер ак «Волга» чыгып китте, — ди.

— Эх, шайтан, иң кирәклесе ычкынды. Инде эш бетте дигәндә генә. Бар, ГАИга хәбәр ит.

Әнфис, яңадан чыгып киткәч, Гамил теге Илшат дигән мөртәтнең якасыннан сөйрәп алды.

— Әй, син, уйнаштан туган хайван, синнән сорыйм, кем үтерде, дим? Дәшмисең, да? Яхшы. Теге дөньяга Азат белән икәү бергә китәрсез.

Гамил кесәсеннән яулыкка төрелгән шприц чыгарды да, Илшат янына килеп:

— Менә бу әйберне таныйсыңмы, синекеме бу, юкмы? — дип, тегенең кулына тоттырды. Теге шприцны әйләндереп-әйләндереп карагач: «Юк, минеке түгел», — дип кире кайтарды. Аның шулай диячәге көн кебек ачык иде инде миңа. Нәрсәгә кирәкмәгәнгә вакытны суза инде бу Гамил, дип уйлап алдым. Гамил, яңадан шприцны яулыкка чорнап, кесәсенә тыккач: «Менә шушы шприц белән Рәкыйп үтерелгән иде, анда хәзер синең бармак эзләрең. Ант итеп әйтәм, акыл иясе, сиңа Рәкыйп янына китәргә күп калмады. Ә синең Азатың каберенә чәчәкләр

ташыячак, бигрәк вакытсыз киттең дип, күз яшьләрен түгәчәк. Түксә, әлбәттә. Түксә, түкмәсә дә, ул исән калачак. Чөнки хәзер синең Рәкыйпне үтерүең ачыклангач, Фурсиләне буучы да син буласың. Хәзер синең Айсылуны да көчләп, соңыннан кыйнап үтерүеңне дәлилләп бирү миңа аягы сынган чебешне тотып алган кебек кенә булачак. Ә синең теге дөньяга тизрәк элэгүең Азат өчен шатлык кына. Чөнки җинаятьче билгеле һәм ул үзенә тиешлесен алды. Азат өстеннән бөтен авырлык төшәчәк», — диде.

Илшат, бар көченә:

— Мин үтермәдем аларны, мин түгел! — дип кычкырды.

— Кем алайса, әйт, яшисең килсә, әйт, хайван! — Гамил кесәсеннән диктофонын чыгарып кабызды.

— Фурсиләне дә, Рәкыйпне дә Азат, Азат үтерде!

Гамил тегеңә якынрак килеп, инде хәзер кычкырмыйча гына:

— Ә Айсылуны? — дип сорады.

— Анысын да Азат. Ул Айсылуга кызыгып йөрде. Ул хәтта аңа өйләнергә дә риза иде. Тик Айсылу теләмәде. Азат аны бары минеке булачаксың дип, тотып көчләде дә, соңыннан кыйнап үтерде. Мин карап кына тордым, үтермәдем.

— Яхшы. Ә авылыгыздагы кунак йортына утны кем төртте?

— Без менә бу кеше килгәндә авылда идек. Азатның әтисе аның нигә килгәнен әйткәч, Азат белән без эшләдек.

— Бик яхшы, бик шәп. Синең тавышың язып алынды. Алла боерса, озак көтмәссең, берәр көнне үзеңә дә тыңларга туры килер. Киттек, дусларым, алда безне зур эшләр көтә!

Аның кәефе Азат кулдан ычкынса да яхшы иде. Аңа гына түгел, хәзер безгә дә аңлашыла башлады. Алда Азатны тотасы гына калды. Әллә ничә кешенең башына җиткән бәндәнең иректә булуы үтәли куркыныч. Шулай да, безнең күңелләр күтәренке, чөнки ярты эш эшләнде. Үтерүчеләр билгеле. Илсурның гаепсез икәнлеге ачыкланды. Их, тизрәк аның әнисен шатландырасы иде. Шушы күңел күтәренкелегеннәнме, минем кинәт Оксананы кабат күрәсем, аның битләреннән үбәсем килеп китте. Тик бу хыял гына...

## XVIII

Илсурның төрмәгә эләгүенә дүртенче ай китте. Бернинди яклаучысы, дуслары булмаган авыл малаена монда яшәүләре коточкыч сынауга әйләнде. Өстәвенә, хатын-кыз көчләп эләккәннәргә караш элеккечә үк катлаулы һәм кыен. Шулай ук, кеше сатып керүче адәмнәргә дә яшәү юк монда. Әле бер атна элек кенә Саша Никулин үз-үзенә кул салды. Аны үз иптәш-

ләрен ментларга сатканы өчен, кыйнап көчләделәр. Ул, мескен, бу түбәнчелекне күтәрә алмыйча, алюминий кашыктан пычак ясап үз-үзен кадап үтерде. «Үз-үзен үтерде» дип туганнарына хәбәр җибәрделәр дә, вәссәлам. Гаеплеләрне эзләүче дә, белергә теләүче дә булмады. Төрмәдәге бүре законнары ментларның үзләренә дә файдалы бугай. Алар шушы ерткычлар өерен бер-берсенә талатып, хәлсезләндереп торыр өчен үзләре үк сөяк ыргыткалыйлар. Үзләренә каршы дәшкән, буйсынмаган бәндәләрне дә шушы этләрне өстереп талатырга, мыскыл иттерергә тырышалар.

Илсур төрмәгә эләккәннең беренче аеннан ук начар агымга эләкте. Аның нинди статья белән эләккәнен белгәч, әкрен генә читкә кага, тора-бара бәйләнә үк башладылар. Берни эшли алмаган Илсур үз эченә бикләнеп, читләшеп яши башлады. Бу инде аның тиздән йә «Маша», йә «петух»лар арасына күчәргә тиешлегенең беренче билгесе иде. Ул күп вакытын кайгырып, урын өстенә яткан килеш үткәрә башлады. «Йа Ходаем, нинди гөнаһларым өчен?! Мин бит үтермәдем, көчләмәдем, ни өчен шушы хәлгә калдырдың. Бәлкем, теге чакта без талаган кешенең каргышы төшкәндер? Алай дисәң, Азат белән Илшат иректә. Теге мужикны алар чишендерде бит. Юк, бүтән түзәрлегем калмады. Үз-үземне чалырга да, Айсылуым янына китәргә. Әнкәй, мескен, гомере буе шатлык күрмәде. Әгәр, әнкәй, син булмасаң... Юк... Түзәргә!» — дип уйлады Илсур. Эченнән генә Ходай Тәгаләдән үзен бу тәмугтан котылуын, ялгыз әнисенә шатлык китерүен сорады.

## XIX

Ләкин төрмәдә бар бәндә дә ерткыч түгел. Арада ялгышып җинаять юлына баскан кешеләр дә очраштыргалый. Шуларның берсе Илсур белән бер бригадада эшләгән Ярул иде. Аның фамилиясе Яруллин булганга, Ярул дип кенә йөртәләр. Ул ниндидер бер коммерция директорын кыскан өчен эләккән. Күп сөйләшми. Кайсы вакытта картасын да, доминосын да суга. Илсур күбрәк аның белән аралаша башлады. Буйга озын булмаган, ләкин нык гәүдәле Ярул беркемнән дә курыкмый. Өстәвенә, башка камераларда да дуслары күп. Илсур, нишләптер, шушы тәртипле, акыллы, ниндидер зур энергия агылган бу кешегә күбрәк тартылды. Үзе белән булган хәлләрне беренче аңа сөйләп бирде. Ярул аны тыңлап бетергәч:

— Мин ышанам сиңа, Илсур! Үзем булганда сиңа бер генә шакал да кул күтәрмәячәк, гарантия бирәм. Тик миңа чыгарга күп калмады. Өстәвенә, бу камерада безнекеләр дә юк. Сак бул! Сиңа тешләнүчеләр күп.

Әйе, Илсурга тешләнүчеләр шактый иде. Бигрәк тә ике метр-

лы, үгез хәтле Мәскәү урысы — Леша этләнде. Берәр очрак туган саен, кәефе булмаган саен:

— И, син, козел, син әле без булмаганнан файдаланып кызлар көчләп яттыңмы, ә?! Син алайса минем әнине дә, әбине дә, сеңелләрне дә можешь. Хатын-кызларга көчең җитә, да?! Ә нигә мине дә көчләмисең соң син?! Әйдә, көчлә, козел! Ник дәшмисең, колхозник?! Хатын-кызлар янында герой булгансың бит, — дип, Илсурны якасыннан сөйрәп торгызды. Илсур: «Саша Никулин хәленә калыр вакытлар җитте. Беттем», — дип уйлады. Шунда көтмәгәндә өченче нардан бер тавыш ишетелде.

— Леша, калдыр малайны, кагылма аңа!

Бу инде төрмәчеләр өчен бөтенләй көтелмәгән хәл иде. Үгез хәтле Леша Москвинга каршы әйтергә кемнең йөрәге җитте икән? Бар да нәрсә булыр икән дип көтә башладылар. Леша башта аптырап калса да, соңыннан:

— Не понял кто это там?! Не понял, Ярул, ты что ли?! Ну ты даешь, друг! Кемне яклыйсың, шушы козелнымы? Бәлкем, ул синең хатын-кыз туганнарыңны да көчләгәндер, — дип җикеренде.

— Юк, ул беркемне дә көчләмәгән, мин аңа ышанам. Просто аңа ментлар срок чәпәгән. — Ярул торып басты.

— Син шушы козелны яклап миңа каршы чыгасыңмы?! Аңлашылды! Татар татарны яклый.

Ярул исә Лешага:

— Тынычлан әле. Мин аны белгәнгә яклыйм. Аннан минем әти генә татар, әни урыс. Эш анда түгел.

Леша күптән Казанның бу буйсынмас, үз бәясен белүче егетенә кызыгып йөри иде. Кайчан булса да мин аны үз урынына утыртам әле дип уйлады. Менә хәзер мөмкинлек туды. Леша гаҗәпләнгән кеше кебек кулларын җәеп, артка чигенде:

— Арт саныма утырттылар мине, егетләр. Кем кемне яклый. Менә сиңа мә!

Шунда Леханың ялагае Никсон утка керосин өстәде:

— Леха, бәлкем, аның бусы да шундыйдыр.

Леша:

— Тәгаен шулай. Икесе дә бер калыптан болар, козеллар, — дип кычкырды.

Ярул алга атлады.

— Нәрсә дидең син, Леша?! Козел дидеңме? Хәзер үк сүзләреңне кире ал.

Леша боксер алымнары, төрле хәрәкәтләр ясап, Ярулга:

— Бәлкем, урыс йодрыгын татып карыйсың киләдер, пипичка Батый хана! — дип кычкырды. Ярулның битенә кызыллык йөгерде, ул алга атлады. Шунда Леша бер аршинлы кулын сузып Ярулга китереп сукты. Ярул иелеп калып, шул ук миз-

гелдә тегенең иягенә шундый көчле итеп сукты ки, аю хәтле Леша аңын югалтып идәнгә сыгылып төште. Әле төгәл генә нәрсә булганын да төшенеп җитмәгән Леханың дуслары, ялагайлар Ярул өстенә килә башладылар. Арада кулына ясалма пычак тоткан Никсон да бар. Ярул көтмәгәндә борылып, тегенең битенә китереп тибүе булды, ялагай башы белән стенага бәрелеп, идәнгә егылды. Аның авыз кырыеннан кан ага иде. Башкаларга шушы җитә калды, алар тукталып, ни эшләргә белмичә аптырадылар. Ярул аларга карап:

— Тагын берәрегезнең теләге бармы? Карагыз аны, җегетләр, бу малайга берәрегез генә кагылып карасын, — дип, урынына барып ятты. Бар да карап торышка сабыр гына булган бу кешегә гаҗәпләнеп, кайберләре сокланып тора иде. Камерада менә шулай яшен тизлегендә үзгәрешләр булып алды. Леха Москвинның ни теләсә шуны кыла ала торган көннәре бетте. Ул аның саен котыра, ялагайларны, «петух»ларны тагын да күбрәк изә башлады. Беренче мөмкинлек туу белән бөтен эшәкелеге Илсурга төшәчәге көн кебек ачык иде. Һәм ул көн якынайганнан якынайды. Ниһаять, Ярул тулырак итеп әйтсәк, Яруллин иреккә чыгып китте. Камера тулысынча адәм рәтле берни эшләмәгән, эчү, караклык, карта уйнау белән генә шөгыльләнгән Леша Москвинга калды. Илсур исә һәр көн, һәр сәгать берәр эшәкелек көтте. Теге үгез дә көннән-көн этләнә барды. Башта: «Бар, моны алып кил, бар, тегене алып кил», — дип бәйләнсә, бер төнне аның янына гомосексуалист әрмән егете Каспаренны җибәрделәр. Илсур төш күреп ята иде. Имеш, алар Айсылу белән язылышып кайттылар. Аларның беренче төннәре. Менә алар бер-берсен иркәли, назлый. Шулчак алар яткан бүлмәгә ниндидер кара кеше кереп карап тора башлады. Илсур аптырап:

— Сезгә нәрсә кирәк, сезгә нәрсә кирәк? — дип сорады. Кара кеше дәшмәде. Ул да түгел, кара кеше Азатка әйләнде. Илсур бар көченә:

— Азат, чыгып тор, комачаулама, чык! Күрмисеңмени безнең Айсылу белән беренче төн! — дип кычкырды. Азат аларны мыскыл итеп көлә башлады. Шулчак Илсур янында кеше барлыгын сизеп сикереп торды. Теге бәндәне чәченнән эләктереп алып, икенче кулы белән бар көченә тукмады. Идәнгә егып та шактый типкәләде. Чөнки ул бөтенләй чыгырыннан чыккан иде.

## XX

Бу вакыйгадан соң Лешаның ялагайлары бераз вакытка тынычланып калсалар да, соңыннан Илсурга бәйләнү янә яңа көч белән башланды. Ул ут йотып яши башлады, бөтенләй бер-

кем белән аралашмый, сөйләшми торган булды. Кеше күрмәгәндә генә төнлә кашыктан пычак ясады. Әгәр берәр хәл эшләргә маташсалар, башта теге үгезне суям, аннары калган шакалларын, дип уйлады ул.

Ә көннәрдән бер көнне камерага кечкенә картны керттеләр. Аны озата кергән төрмә каравылчысы:

— Рәхим итегез, Василий Чикләвекович, сезне яңадан безнең йортка әләгүегез белән, — дия-дия, озата ук керде. Леша Москвиннар бу вакытта өстәл артында домино суга иделәр. Бу бетерешкән картны күргәч, исләре дә китмәде. Камерада теге үгезнең генә тавышы яңгырап торды.

— Аһ, хана сезгә! Сез мудакларга! Аһ, ананңны шулай итим. Әле сез шулаймы, без менә болай! Ну кәҗә калдырам барыбер! Кәҗәләр күзгә күренеп артачак. Саварга гына кешеләр яллыйсы кала. Манчыдым! Беттегез сез, аңгыра сарыклар, — дип, домино сукты.

Яңа кергән бабай бүлмәне күзәтә башлады. Аның күзе Илсурга төште. Әкрен генә килеп, Илсурның янәшәсендәге караватка утыргач:

— Улым, нишләп бик күңелсез? Әллә чирлисеңме? — дип сорады. Илсур исә, инде монысы нинди хәшәрәт икән, дип уйлап алды.

— Улым, син курыкма, мин начар кеше түгел. Кем рәнҗетте сине, курыкма, сөйлә. Ни өчен эләктең, сөйлә, улым! Василий бабаң дөнья күргән кеше, бәлкем, берәр ярдәмем тияр. Ничек эләккәнеңне сөйлә инде, улым. Нинди статья белән эләккәнең кирәкми. Ничек булды, шуны сөйлә.

Илсур теләр-теләмәс кенә хәлнең ничек булганын хикәяләп бирде. Ул сөйләп бетергәч, карт:

— Аңлыйм мин сине, улым, аңлыйм. Бик кыендыр сиңа! Синекенә охшаган хәл элек тә булды ул! — дип, сүзен дәвам итте. — Шулай төнлә бер егет кызын озатып куеп, күтәренке күңел белән өенә кайтып бара. Бер йорт янында, канга баткан яралы ята. Бу яшь егет аңа ярдәмгә ташлана. Ләкин күтәреп бара алмагач, көче җитмәгәч, яралыны куеп, «ашыгыч ярдәм» машинасы чакырта. Юлда теге кеше үлә. Бу ярдәм итәргә теләгән яшь егетнең күлмәгендә мәрхүмнең каны, корбанның күлмәгендә егетнең бармак эзләре кала. Кыз озатып кайтып килгән җиреннән бер гаепсезгә 15 елга төрмәгә ычкына. Менә шулай, улым! Була ул андый хәлләр.

Шунда Леха, Илсур белән бабайның сөйләшеп утыруын күреп:

— Карагыз әле, кара, теге козел үзенә иптәш тапкан. Кочаклашмыйлар гына. Ха-ха-ха, — дип, акырып көлә башлады. Аңа ияреп ялагайлар хихылдый. Бабай берни булмагандай сүзен дәвам итте:

— Була ул, улым, төрле хәлләр. Шулай да син, улым, бирешмә.

— Теге егет чыга алдымы соң төрмәдән?

Бабай карап торды да, авыр сулап куйды:

— Чыгуын чыкты, улым, тик кабат керер өчен. Чөнки ул унбиш ел утырып чыкканда башка кеше иде инде. Яраткан кызы кияүдә. Бар да аны үтерүче саный. Хәтта үзен тудырган ата-аналары да. Чыкты ул, улым, чыкты. Исән-сау ул. Менә синең каршыда утырган бабаң, шул егет инде ул. Бабай дисең инде, улым, ә? Ә миңа бит илле беренче генә, улым!

— Илле бер яшь кенә? Гафу итегез, зинһар, мин...

Бабай торып Илсурның җилкәсеннән кагып:

— Борчылма, улым, борчылма, — дигәч, өзлексез йөткерә башлады. Леха, картның бертуктаусыз йөткергәнен күреп: «Җыен козел, җыен туберкулезникны безнең камерага тутыралар. Инде хәзер СПИД белән чирләүчеләрне генә көтәсе калды, — дип җикеренде.

Карт тагын берни ишетмәгәнгә салынды.

— Улым, сине шушы хайваннан яралганнар рәнҗетә торгандыр инде. Кичер син аларны, улым. Алар бит үзләрен хайван дип уйламыйлар. Кеше санийлар. Бөтен хаталары шунда гына аларның, улым. Кайсысы, улым, иң әшәкесе, әйт. Әйтмисең инде алайса. Дөрес эшлисең, улым. Төрмә сүз йөрткәнне ярат-мый ул. Шулай да син бик кайгырма әле, улым. Без бит икәү хәзер.

Илсурның күзләреннән яшь бәреп чыкты, ул нервыланып калтырый ук башлады, сикереп торып:

— Миңа берсе генә якын килеп карасын, шушы пычак белән үзем үлгәнче суячакмын, — дип кычкырды. Бабай:

— Тукта әле, улым, тынычлан! Бир әле пычагыңны, бир, — дип, Илсурның кулыннан пычагын алды да: — Әрәм иткәнсең кашыкны, улым. Бу нәселсез этләргә кызганыч ул. Алар үзләренең эт үлеме белән үләчәк болай да. Аларның бөтен көче, энергиясе шакшылык, бозыклык эшләргә генә китә. Син бит андый түгел. Кеше булып кал. Сакла кешелегеңне, киләчәктә кирәк булачак!

Леха белән ялагайлар Илсурның гасабиланганын күреп, яңадан шаркылдый башладылар. Бабай, урыныннан торып:

— Улым, мин теге өстәл янында утыручылар белән дә исәнләшеп килим әле, бергә яшисе бар бит әле алар белән дә, — дигәч, өстәлгә юнәлде.

Бабай, өстәл янына басып уенны күзәтә башлады. Леша аның карап торганын күргәч:

— Нәрсә, бабай, синең дә аппетит уянды, ахры, уйнарга. Нәрсәдән уйныйбыз соң, алыштанмы, салыштанмы? Бәлкем, салыштан, ә? Ха-ха-ха, — диде.

— Салыштан уйнарбыз, улым, салыштан. Тик, зинһар, карт кешедән көлмә инде син, улым. Рәнҗетмә.

Леха Москвин һаман шаркылдавын белеп:

— Әйдә алайса, бабай, салыштан. Ха-ха-ха. Олы кешене рәнҗетмим инде мин. Ха-ха-ха. Тәрбиям кушмый. Ха-ха-ха, — диде.

— Карале, улым, син ни өчен әләктең соң монда, шундый югары тәрбия алгач?

— Ну бабай, мин ни өчен әләккәннәрне санасаң, калган чәчләрең дә агарыр. Ходай бирмәсен мин күргәннәрне сезгә, бабай! Әллә кайчан кәкрәеп каткан булыр идегез инде сез.

— Шулай дисеңме, улым. Каткан булыр идегез дисеңме? Ант итеп әйтәм, син чын козел булырга тиеш. Анысын соңрак ачыкларбыз. Ә хәзер барыгыз да басыгыз, сасы кәҗәләр! Кемгә әйтәм, хайваннар!

Илсур бабайны танымады. Бая гына йомшак итеп сөйләшкән бабайның эзе дә калмыйча, кечкенә генә карт, куркыныч тавышлы кешегә әйләнде дә куйды. Өстәл янындагылар гына түгел, бүлмәдәге башкалар да бабайның бу тавыш куптаруына сәерсенеп, эшнең ни белән бетәчәген көтә башладылар. Леха да зур итеп авызын ачты. Шулай да өстәл артындагыларның берсе дә урыннарыннан торырга җыенмады. Ниндидер кечкенә генә картның тузынуы аңлашылмый иде. Бабай бар көченә тузынып өстәлне әйләндереп каплады.

— Нәрсә, сасы кәҗәләр, атагызны танымыйсызмы?! Шушы сасы сезнең котыгызны алып ятамы, — дип өстәл астында яткан Леша Москвинга күрсәтте.

Бер төрмәче картны танып алды, ахры.

— Йа Хода, бу бит Василий Антонович Чикләвеков түгелме соң? Василий Антонович, җанкисәгем, зинһар, кичерегез, билләһи танымадым, менә мин аңгыра! Зинһар, кичер, ничә ел бит инде сезне күрмәгәнгә! Бу, җегетләр, вор в законе Василий Антонович.

Камерада тынлык урнашты. Төрмәгә яңа эләгүчеләр шушы кечкенә генә картның шундый зур көчкә ия булуына шаккатса, аны ишетеп, йә булмаса элек күргәннәре өннәре китеп калды. Бабай Леха Москвинга:— Әй, дуңгыз, тор аннан, чык монда! Бабаңның синең белән гәпләшәсе килә! Кил каршыма, диләр, уйнаштан туган хайван! — дип кычкырды. Мескен хәлдә Леша Москвинны күргәннәре юк иде камерадагыларның. Үгез хәтле бу бәндәнең үзенә килеп терәлгәч куркаклыгын күреп, исе-акыллары китте. Бөтен камераны тоткан Леша бабай янында ит массасы булып кына калды. Бабай яңадан:

— Син киләсеңме, юкмы, ишәк тәрбиясе алган хайван! — диде.

Леха, калтырый-калтырый, тезләнгән килеш бабай каршына килеп:

— Гафу ит, зинһар, атакай, кичерә күр! — дип, елый ук башлады.

— Башта әнә теге адәм баласыннан гафу сора, дуңгыз, соңыннан карарбыз!

Леха Илсур янына килеп:

— Гафу ит, туган, — дип кичерүен сорады.

— Тезләнеп сора, мисез хайван, синең аркада ул чын җинаятьчегә әйләнә язды. Тезлән!

Москвин тезләнде. Чөнки тезләнми мөмкин түгел, башың бетәчәк. Илсурга исә картның алар бүлмәсенә керүе ышаныч өстәде. Бабай яңадан Лешага карап:

— Ә хәзер каты итеп чәй әзерлә, нишләптер баш авыртып тора, карт кешегә күп кирәкми ул. Менә минем яшькә җитегез әле! Ә сез мине нервыландырасыз. Аннан мин сезгә шуны әйтәм, әгәр кем дә кем менә бу балага әшәкелек кыла икән, үзегезгә үпкәләгез! Ул хатын-кыз көчләмәгән, кемнәрнеңдер тырышуы аркасында монда эләккән. Аның урыны безнең арада түгел. Язмыш аны рәнҗеткән икән, без бераз булса да мәрхәмәтлерәк булыйк, — диде.

Соңыннан бабай Илсурны гына үз янына чакырып, икәүләшеп чәй эчтеләр. Бабайның үзе белән алып кергән төенчегендә шикәр, конфет, яхшы колбаса белән дуңгыз мае җитәрлек иде.

Илсур тынычлап яши башлады. Аның хәзер буш вакытында кайгырырга мәрхүмә Айсылу белән ялгыз әнисе генә бар. Үзе өчен кайгырулар артта калды. Кирәк чакта таяныч булырга хәзер Василий Антонович бар. Бабай да аны нишләптер үз итте. Бәлкем, язмышлары охшаш булгангадыр, кем белә. Ничек булса да тагын сигез елны түзәргә кирәк, әнкәй генә исән булсын инде, җанкисәгем, дип уйлады ул. Әнисенә озын итеп хат язып салды. Ә күңеле һаман иреккә омтыла иде.

## XXI

Азат, машинасына утырып, туп-туры туган авылына юнәлде. Чөнки анда аның кирәк чакта яклаучысы, саклаучысы булган атасы бар. Атасы кулында булган колхоз малы аны күп тапкырлар төрмәдән йолып алды. Нәрсә өчен бүген аларны алырга уйладылар икән? Кемдер наркотиклар белән эш иткәнне ачканмы? Ул элек үзләре белән йөргән Андрейдан шикләнде. Чөнки алар Андрейны бер ай элек уртак акчаны урлашканы өчен кудылар. Теге киткәндә янап китте. Шул козел гына саткан. Ярый, ментлар белән генә эш бетсен, кәҗә маен чыгарам мин аның. Иң мөһиме, әти исән булсын да, аның ит белән бал ярата торган түрә дуслары яшәсен!

Азат Айсылу аркасында кулга алына язуын башына да китерә алмады. Чөнки бар булган шаһитларны теге дөньяга олактырды. Ә теге вак-төяк, Оксана белән наркотиклар мәсьәләсе аның өчен чүп кенә...

Ул ГАИ хезмәткәрләре булмаган юллардан Казаннан бернинди каршылыксыз чыгып сызды. Казаннан ундүрт-унбиш чакрым тирәләрендә урнашкан авылга кереп, караңгы капканчы иптәш малаенда кәеф-сафа кылгач, иптәшенең: «Кал инде бүген, гудить итеп алыйк әле», — диюенә карамастан, «Эшләр бар әле», — дип, авылына ашыкты. Кичке сәгать уннарда ул үзләренең капка төпләренә кайтып туктады. Машина тавышына өйдән әтисе чыкты. Бер сүз дәшми Азатка карап тора башлады. Чөнки малаеның кинәт кайтулары беркайчан да юньлегә булмый торган иде. Азат әтисен күргәч:

— Нихәл, картлач! Эшләр барамы? — дип сорады.

— Тагын ни булды? — дип, каршы сорау бирде әтисе. Азат, машинасының ишеген ябып, ачкыч белән бикләгәч, әтисенә карамыйча гына:

— Ә, вак-төяк шунда, — диде. Атасы эчендәге нәфрәтен тыярга тырышып:

— Тагын нинди вак-төяк, хайван! — дип чәчрәде. — Сине төрмәдән коткара-коткара күпме сәламәтлегем бетте. Күпме мал әрәм китте. Инде нәрсә эшләдең, хайваннан яралган нәрсә?! Гарип урыс. Мисез сарык. Урод. Оешмаган нәрсә. Чүп савыты.

Азат атасына якын килде:

— Әти, йә, чәрелдәмә әле, зинһар, гарык синең акылсыз фәлсәфәңнән! Үзеңне бел дә телеңне тешлә инде. Акыл сатма, зинһар. Нәкъ үзеңә охшаган инде мин, койган да каплаган. Күршеләреңә түгел. Ул яктан бәхетле син.

Азатның авызыннан аракы исе Фатыйх Кәримовичның борынына килеп бәрелде.

— Фу, дуңгыз, — дип, борынын каплады. — Шушы килеш машинада йөрисеңме инде син?! Тагын берәрсен бәрдереп үтерәсең генә калган. Ярый теге чакта син бәрдергән картның туганнары гади кешеләр иде, ике миллион биргәч, авызларын йомдылар. Синең аркада әнә әниең чирләшкәгә әйләнде. Хайван!

Азатның түземлеге бетте:

— Син үзеңне бел, карт хайван! Әнине кем бетергәнен мин яхшы беләм. Гомерең буе әни өстеннән йөрдең. 18 яшьлек кызга да бәби ясаганыңны оныттыңмыни, карт шайтан! Без нәрсә күреп үстек соң, без ничек яхшы булырга тиеш соң? Апа, мескен, синең аркада кияүгә чыкмады. Чөнки ул гаилә төзергә курка. Чөнки ул минем кебек синең гаугаларыңны күреп үсте. Син нәрсә теләсәң шуны эшләдең. Син Казандагы сөяркәңә дә квартира алып бирдең. Хәзер аның кызы буй җиткән. Чат саен синең балалар. Үтерәм мин сине тагын бер сүз әйтсәң, ычкындырам!

Фатыйх Кәримович артка чигенде. Элек тә аларның бу те-

мага бәрелешләр булгалый иде булуын, ләкин бүгенге кебек ярсыган Азатны беренче күрүе. Аны курку басты. Чөнки аның улы Азат чит кешеләрне генә түгел, кирәк булса, ике дә уйламыйча, аны да олактырырга мөмкинлеген аңлады. Ул куркып, Азатны тизрәк тынычландырырга ашыкты:

— Булды, булды, тынычлан! Әйдә, өйгә кереп сөйләшик, кешеләр ишетмәсен.

Азат та тынычлана төшеп аңа иярде. Аш бүлмәсенә кергәч, Фатыйх ага суыткычтан бер шешә коньяк чыгарып өстәлгә куйды. Ашарга ит, колбаса, каймак чыгарып куйгач:

— Аш ашыйсыңмы, җылытам? — дип сорады. Азат өстәл янына килеп, коньякны кулына алды:

— Бу өч тиенлек коньякны эчкәнче, берәр агың юкмы соң? Аш та ашамыйм. Ит булганда, аш ашамыйм мин.

Ата кеше суыткычтан бер шешә акны чыгаргач, ачып, стаканнарга бүлде. Берсен малаена сузды:

— Улым, минем хаталар бар инде ул. Ләкин ни генә булмасын, мин сезне ташладыммы? Юк. Дөрес, каты булган чаклар да булды. Нишлисең, тормыш булгач, төрлесе була. Тик син минем хаталарны кабатлама. Инде яшең бар, өйлән! Хатын-кыз бетми ул!

Азат үзенә салган өлешне авызына каплады да зур бер ит кисәгеn алып сыптыра башлады. Бераз ашагач, әтисенә:

— Әти, әйдә калдырыйк әле бу теманы. Эш турында сөйләшик, — диде.

— Нәрсә, тагын теге Айсылу эшеме?

— Юк! Монысы наркотиклар өчен булырга тиеш. Минем белән йөргән Андрей саткан, ахры. Ну, мин ул сатлык җанны акылга утыртмасам!

— Төгәл шуның өчен дип уйлыйсыңмы?

— Төгәл булмыйча. Бүтән теге эшне белүче шаһитлар калмады, — дип, стаканны бушатты. Ата кеше, эчәм дигән стаканын кире куйды:

— Ничек инде калмады?

— Шулай.

— Соң мин сиңа куркытырга гына кушкан идем бит. Баш та юк инде үзеңдә. Ярый, бар, ят, иртәгә иртүк бер яшь тананы суйдырып Казанга китәрбез. Билләһи, Зөфәр Халиковичтан оят. Аның безгә эшләгәне инде.

— Бушка түгел бит, әти. Ел саен бер-ике сыерың китеп тора!

Бүлмәгә Азатның әнисе Әкълимә ханым килеп керде. Аның ап-ак чыраеннан, хәлсез-нечкә бармакларына карап та сәламәтлегенең начарлыгын сизеп була иде. Әкълимә ханым, малае янына килеп, хәлсез куллары белән чәченнән сыйпады:

— Улым, тагын нинди явызлык кылдың инде?

— Юк, әни, барысы да әйбәт. Берни юк.

Азат, торып, әнисен кочаклап алды.

— Барысы да әйбәт, әни. Хәл белергә генә кайтуым, — дип, әнисеннән күзләрен яшерде. Ул бары тик әнисен генә хөрмәт итә, калган бар дөнья аңа күңел ачу урыны гына иде.

— Улым, алдашма! Мин сезнең бар сүзегезне ишетеп тордым. Саклый алмадым шул мин сезне, улым! Апаңны да, сине дә! Сезне атасыз калдырмыйм, дип яшәдем. Нәтиҗәсен үзегез күрәсез! Хәзер соң инде. Зинһар, кичерегез мине, саклый алмадым! Иң кадерле нәрсәләремне саклый алмадым шул, — дип, Әкълимә ханым ишеккә юнәлде. Ләкин барып җитә алмады, йөрәген тотып идәнгә егылды. Азат, тиз генә килеп, әнисен идәннән күтәреп алды, йокы бүлмәсенә алып кереп, караватка салды. Арттан Фатыйх Кәримович кереп, Әкълимә ханымга валидол бирде, су эчерде. Ананың хәле яхшырмады. Ата кеше эшнең начар икәнен сизеп нык дулкынлана, борчыла иде. Ни эшләргә икән, дип уйлады ул.

— Улым, син өйдә кал, мин әниеңне Казанга, хастаханәгә илтәм!

— Мин дә, эти!

— Юк, улым! Син өйне сакла! Мин үземнең таныш табибларга илтәм. Әниең белән эшләр начар... — Фатыйх Кәримович беренче мәртәбә Әкълимә ханымның үзе өчен иң кадерле җан икәнлеген аңлады. Ул, хатыны үлсә, малаена да, кызына да кирәк түгеллеген белә иде. Шуны уйлап аның коты алынды. Ашыгырга кирәк, югыйсә соң булуы бар!

— Улым, тиз бул, бар, машинаңны кабыз да, арткы утыргычка юрган җәй! Ашыгырга кирәк!

Әнисен генә яраткан бозык малайның коты очты. Ул нәрсә эшләргә белмичә кабаланды. Күпме кешенең башына җиткән бу мөртәт җебеп төште. Атасы аңа:

— Нәрсә җебеп торасың, бар, машинаны кабыз! — дип яңадан кычкырды.

Азат чыгып китте. Ата кеше, хатынының янына чүгеп:

— Әкълимә, бәгърем, ач әле, ач күзләреңне, бу мин, синең Фатыйхың бит! — дип эндәште. Тик ана кеше һушсыз иде. Фатыйх Кәримович аның йөрәк тибешен тыңлап карады. Ул сизелер-сизелмәс кенә иде. Тизрәк-тизрәк, дип типте хуҗаның йөрәге. Каты бәгырьле бу кешенең дә күзләреннән яшь акты.

Әкълимә ханымны арткы урындыкка яткырып, Фатыйх Кәримович Казанга ашыкты, Азат сыгылып төшкән килеш чолан ишегенә сөялеп калды. Авырлыклар күрергә өйрәнмәгән малай бүген бик кайгырды, ул үзенең дә, туганнарының да кайчан да булса бу якты дөньядан китәчәген уйлап та карамаган иде. Үлем аларны уратып узар, аларга тимәс кебек иде. Ул үзен мәңгелек, башкалардан аермалырак итеп күрә иде.

## XXII

Фатыйх Кәримовичның машинасын ГАИ постында милиционерлар уратып алды. Аның үзенә автомат терәп куйдылар. Фатыйх Кәримович эшнең, ниһаять, нидә икәнен төшенә башлады. Милиция капитаны аңа:

— Машинадан чыгыгыз, сез кулга алынасыз! — дип кычкырды. Һәр секунд кадерле булганга, ул машинадан төшеп:

— Сез, Азат Фатыйховичны эзлисез булса кирәк, ул монда юк, мин аның әтисе. Менә әниебез чирләп китте, хәле начар, тизрәк больницага илтергә кирәк, аңлагыз шуны! — диде. Капитан машина эчен күзәтеп:

— Ә малаегыз кайда? — дип сорады.

— Ул авылда калды, өйдә.

Капитан машинаның арткы өлешен игътибар белән карагач, һушсыз яткан хатынны күреп:

— Ярый, алайса, хәзер сезнең хатыныгызны илтәргә машина чакыртабыз. Ә «Волга»гыз биредә калачак, — диде.

Бер сәгатьтән Фатыйх Кәримович белән Әкълимә ханымны республика клиник хастаханәсенә алып киттеләр.

Азат ишек төбендә бераз утыргач, өйгә керде. Яшереп куйган урыннан шприц алып, үзенә наркотик кадады. Аңа рәхәт булып китте. Соңрак, әтисенең кабанга йөри торган карабинын алып, магазинына патрон тутырды. Ну, Андрей, кара аны, иртәгә башың бетәчәк синең, дип уйлады ул.

## XXIII

Оксана безгә тәмле пылау әзерләп куйган. Без Гамил белән кызны мактый-мактый бер казан пылауны сосып салдык. Оксана безгә шаккатып:

— Болай ашый торган булсагыз, сез 40—50 яшьтә соами көрәшчеләренә охшап калачаксыз, — диде.

Гамил:

— Безгә положено, без — эш кешеләре. Ярый син өйдә тик утырасың, — дип, Оксанага күз кысты.

— Алайса мине дә үзегез белән алыгыз.

— Син анда нишләмәк буласың соң, дустым? Анда бит дискотека ясамыйлар, — ди Гамил.

— Ясамасалар соң, мин анда яраланучылар булса, ашыгыч ярдәм күрсәтермен. Безне өйрәттеләр, мин беләм. Ярыймы?

Гамил сикереп торды:

— Юк, не позволим, ач каласыбыз килми әле. Безгә тагын пылау пешереп куй. Тик күбрәк!

Шулчак телефон шылтырады. Гамил барып трубканы күтәрде:

— Әйе, әйе... әйе... Кайчан? Шәп булган! Дөрес эшләгәннәр. Хәзер үк машина җибәрегез, көтәм.

Гамил трубканы куйгач, безгә борылды:

— Башлана эшләр, Азат авылларында! Аны алырга барабыз. Их, бәхетле дә кеше инде син, Хәниф. Нинди чибәр кыз белән берүзең каласың. Әллә минем урынга син барасыңмы? Булмый дисең инде алайса. Ну, тыныч йокы сезгә, абзый! — дип, ишеккә юнәлде. Мин дә тиз генә торып аңа иярдем. Ул минем бу батыр адымымны күреп: — Әллә ычкына башладың инде син, — диде. — Фәрештә кебек кызны берьялгызын калдырып миңа ияреп йөрисең! Бу эшләр беткәч, сезнең туйда бер рәхәтләнеп эчәрмен дигән идем, булмады. Стрессны кайда бушатырмын мин хәзер?

— Кайгырма, аны гына бушатырга урын табарбыз. Оксана дустым, мин дә барып кайтыйм инде? Мин сиңа чәчәкләр җыяр идем.

— Бар, лачыным, мин сине көтәчәкмен, — дип, Оксана битемнән үбеп алды. Гамил безнең бу эшебезне күреп:

— Их, үтермәгез мине, югыйсә авылдан хатынны чакыртып алам, — дип, чыгып китте.

Фатыйх Кәримович соңга калды. Хастаханәгә килеп җиткәндә, Әкълимә ханым үлгән иде. Баш табиб тикшереп карады да, гаепле төсле: «Берни эшләп булмый, соң инде. Тагын 30 минут элегрәк килгән булсагыз да... Соң...» — диде.

Фатыйх Кәримович үкереп елап җибәрде. Гомере буе муллыкта яшәргә яраткан, кая барса, шунда сүзе үткән бу кешегә дөньяның мәгънәсе бетеп, тирә-як бушап калгандай тоелды. Ул үлгәч кенә кадерлегә әйләнгән хатынының җеназасын авылга алып китәргә сорады. Тик аңа моргка алып бармыйча ярамаганын аңлаттылар. Бары дусты Зөфәр Хәлимович ярдәм иткәч кенә, мәетне моргка илтмичә алып кайтырга рөхсәт бирделәр. Иртәнге бишләрдә шәһәрдә аның эшләре беткән иде. Зөфәр Хәлимович мәрхүмәне үзе дә озатыша кайтты.

## XXIV

Менә машина урман буйлап алга чаба. Фатыйх Кәримович хәлем бераз яхшырмасмы дип, аракы эчеп караса да, ярдәме тимәде. Ул эчте дә елады, эчте дә елады.

Менә машина бер ел элек кенә Айсылу үтерелгән урынга җитсә дә, бу хәл Фатыйх Кәримовичның башына килеп тә карамады. Югыйсә ничә тапкыр тикшерүчеләр белән килеп, шушы тирәләрне айкадылар. Бер-ике йөз метр алдарак корыган имән агачының зур бер ботагы сынып төшеп, юлга аркылы ятты. Машина йөртүче кисәк кенә тормозга басса да, машина

теге зур ботакка килеп бәрелде. Автобусның арткы утыргычларына салынган Әкълимә ханымның җансыз гәүдәсе, кинәт туктаудан, шуып идәнгә килеп төште. Фатыйх абзый белән Зөфәр Хәлимович җеназаны кире үз урынына урнаштыргач, юл уртасында яткан ботакны алып ыргытышырга, шофер янына чыктылар. Шунда гына Фатыйх ага бу урын — Айсылуның канга батырылган гәүдәсе табылган урын икәнен аңлады.

— Айсылу, Айсылу сеңелем, зинһар, кичер, гафу ит! — дип пышылдады ул. Аның колагына каяндыр шомырт кара күзле, озын кара толымлы Айсылуның тавышы ишетелгән кебек булды.

— Соң инде, Фатыйх Кәримович, соң, — дип, шаркылдап көлә иде кебек кыз. Шулвакыт Айсылуга охшаган ап-ак күлмәк кигән бер хатын-кыз урман эченә кереп киткәндәй тоелды аңа.

— Айсылу, сеңелем, зинһар, кичер!

## XXV

Айсылуны кем үтергәнен тәгаен белүче авылда берничә генә кеше бар иде. Аның берсе Фатыйх Кәримович үзе булса, икенчесе Айсылуның әти-әниләре. Азат әллә ничә тапкыр Айсылуларга килеп, кызның кулын сорады. Картлар үзләре шатланып риза булсалар да, кыз каршы булды. Ә өлкәннәр кызларының муллыкта яшәвен теләделәр. Чөнки икесе дә бик уңган кеше булсалар да иркенлектә яши алмадылар. Өстәвенә, үзләреннән өзеп, тиенләп җыйган машинага дигән җиде мең акча да үзгәртеп кору башлангач, көннән-көн бәһасен югалта барып, машина коры бер хыял гына булып калды.

Азат Айсылуны үтергәннән соң, дусты Илшат белән эт булганчы эчтеләр. Исерек Азат Илшатка карап:

— Мин дөрес эшләдем бит, шулаймы, дөрес. Минеке булырга теләмәде, бер кешенеке дә булмасын, шулай бит, — диде. — Мин беркемнән дә курыкмыйм, белсеннәр кем үтергәнне, сабак булсын. Телисеңме, хәзер Айсылуның әти-әниләренә дә барып әйтәм. Миңа барыбер.

Ул лаякыл исерек килеш Айсылулар өенә юл тотты. Илшат куркып калды, чөнки Азатның үзсүзле икәнен яхшы белә иде.

— Тукта, җүләрләнмә әле, безне икебезне бергә утырталар бит хәзер, — дип туктатып азапланды. Тик тегесе каршы төшеп маташкан иптәшенә китереп берне сукты да:

— Мин бернәрсәдән дә курыкмыйм, аңладыңмы! — дип, Айсылулар капкасын ачып, рәшәткәләргә бәрелә-сугыла эчкә кереп китте. Коты алынып, бу хәлдән шактый гына айнып киткән Илшат, борыныннан аккан канын кулъяулык белән сөртә-сөртә Фатыйх Кәримович янына чапты. Калган эшне колхоз рәисе үзе җайлады. «Үлгәнне кире кайтарып булмый инде, хәзер бу тинтәкне утыртудан гына берни дә үзгәрми, хәлдән кил-

гәнчә сезгә булышырбыз. Менә Азатның бу кара «Жигули»ен сезгә бирәбез, кеше сораса, сатып алдык, диярсез инде», — дип үтенде. Фатыйх Кәримовичның шулай Айсылуның әти-әниләренә кайгылы көннәрендә булышып йөрүен күргән авылдашлары алдында хөрмәте артты. Ә Айсылуның әти-әниләре бер «Жигули» хакына авызларын йомдылар. Ә тикшерүчегә килгәндә, ул өстән ни кушсалар шуны гына үтәүче бер кеше иде.

## XXVI

Төнге сәгать дүрттә, Фатыйх Кәримовичның йорты камап алынган иде. Өйгә бәреп керергә ашыкмадылар, чөнки Илшатның әйтүе буенча, өйдә карабин бар, өстәвенә, Азат оста атучы да икән. Бу вакытта Азат теге башланмаган коньякны да бушатып утыра иде, урамда машина тавышлары ишетеп, тәрәзә каршына килде. Андагы милиция машиналарын күргәч, исерек Азат эшне аңлап алды. Димәк, аны алырга килгәннәр. Милиционерлар арасында Илшат та күренгәч, Азатка бар нәрсә дә ачык иде:

— Саткан, барысын да шул саткан, тварь!

Исерек Азат мансардага менеп, ачык тәрәзәдән мылтыгын Илшатка төбәде. Менә бер милиционер Илшатка тавыш көчәйткеч бирде, Илшат мегафон аша йортка карап:

— Азат, чык, безнең эшләр турында барысы да билгеле! Иң яхшысы, каршылык күрсәтмәскә! Чык, Азат, чык! — дип кычкырды.

Шулчак исерек Азат тәтегә басты. Илшатны ниндидер көч артка бәреп екты. Аның сул як күкрәгеннән шыбырдап кан ага иде. Гамил, милиционерларга:

— Тиз булыгыз, авыл халкын өйләренә таратыгыз, җыелмасыннар монда, югыйсә корбаннар күп булачак! — дип әмер бирде. Бар төркем белән урамдагы шау-шуга җыелган халыкны өйләренә таратырга тырыштык. Ә Азатның ни өчен кулга алынуын инде бөтен авыл белә иде диярлек.

Азатлар өендә ниндидер хәрәкәт сизелде. Ул, тәрәзә төпләренә газ баллоннары китереп куеп, соңыннан ниндидер савыт белән стеналарга сыекча сибә башлады. Безнең аңлавыбызча, анда бензин иде. Гамил хәлнең нидән гыйбарәт икәнен аңлап, мегафоннан:

— Азат, бирел, кирәкмәгән эшләр эшләмә! Үзең бирелсәң, синең файдага гына. Чык әйдә! — дип кычкырды.

Шулчак эчтән тагын ату тавышы яңгырады. Бу пуля Вася Слонның аягын яралады. Азат башын тәрәзә кырыеннан тыгып:

— Терелә ала алмаячаксыз, козлы! Мин сезгә күрсәтәм әле! — дип үрсәләнде.

Гамилнең эшләре бер дә шәптән түгел иде. Вася яралы. Каядыр артта мәет янында туганнары елаша, Вася янында да

бер оперативник ярдәм күрсәтә. Вася яралы булуына карамастан, шаяртып:

— Бүген, гомердә булмаганны, хатын белән йокламакчы идем, кая инде хәзер бу аяк белән, булмады бу. Туры килә бит, — диде.

Гамил, алай-болай теге бәндә өйне шартлатса дип, машиналарны арткарак чигертте. Алла белә, теге хәшәрәтнең ни кыласын. Өстәвенә, исерек. Ни булыр икән дип, тирә-як тынып калды.

## XXVII

Айсылуның әтисе Гариф абый, бүген рәтләп йоклый алмады. Әллә нинди ямьсез төшләр күреп уянгалады. Берничә мәртәбә Айсылуы төшенә кереп:

— Әти, син мине шушы кара «Жигули»га алыштырдың, шулай бит, әтием? — дип сорады. Карт саташып:

— Юк, юк, кызым, сине алыштырып буламы соң, Айсылуым! — дип ыңгырашты.

Картның Айсылуым, Айсылуым, дип саташып ятканын күргән бәхетсез хатыны үксеп-үксеп елады, Азатны каргады:

— Башың гына бетсә иде, Азат, бер гөнаһсыз сабыебызның җанын кыйганга. Айсылуым, кызым, бердәнберем минем!

Ана кеше ирен төрткәләп уятты:

— Тор әле, дим, Гариф, саташасың бит, тор! Айсылу белән саташасың, — дип, үзе һаман күз яшьләрен койды. Гариф карт, горур Гариф, эшне аңлап алгач, гомерендә беренче мәртәбә хатынын чын күңелдән кочаклап, үзе дә үксеп елады. Бүтән вакыт булса, бер генә кычкыра, йә булмаса берне сугып җибәрүдән дә тартынмаган кырыс ир, балалар кебек күз яшьләрен койды. Бераздан соң ул торып, тәмәкесен алгач, урамга чыкты. Шулчак авылның икенче очында мылтык аткан, кешеләр шаулашкан тавыш ишетелеп китте. Ул урамдагы берәүдән:

— Ни булган анда, әллә ут-мазар бармы? — дип сорагач, теге кеше:

— Ничек инде белмисең, сезнең Айсылуны үтерүчене кулга алалар, — дип, ашыгып китеп барды. — Айсылуны, Айсылуымны?! — Карт яңадан ишегалдына керде, кара «Жигули»ның ишеген ачып, алгы урындыкка утырды. Кызы Айсылуның рәсемен алып, сурәткә карап катты. Айсылуым, кадерлем минем!

## XXVIII

Исерек Азат аска төшеп, калган коньякны авызына каплады. Ул гына җитмәде, залга кереп стенкадан тагын бер акны алып чыгып, яртысын эчеп бетерде. Шуннан икенче катка ме-

неп, тирә-якка күз салды. Бәрәңге бакчасы аша берничә милиционер кача-поса йортка якынлаша иде. Ул атып җибәрде. Пуля беркемгә дә тимәде бугай. Кире аска чабып төшеп газ баллоннарын ачты. Бу хәлне күзәтеп торган Гамил мегафоннан:

— Барыгызга да өйдән читкәрәк китәргә! Шартлау куркынычы бар. Барыгызга да китәргә, шартлау куркынычы бар! — дип кычкырды. Азат исә, урам якка карап:

— Керегез, кер, сасы ментлар, көлегез күккә очасы килсә, керегез! — дип кабатлавын белде. Гамил аптырап калды. Ни эшләргә? Инде таң атты. Кешеләргә көтү куарга вакыт җитсә дә, берәү дә ашыкмады. Ул да түгел, районнан теге минем таныш тикшерүче Әскәров килеп төште. Башымнан «бигрәк тиз хәбәр иткәннәр» дигән уй үтте. Әскәров безнең барыбызны да күз карашы белән барлап чыккач, игътибары майорга тукталды. Гамил янына килеп:

— Иптәш майор, район эчке эшләр бүлегеннән тикшерүче Әскәров! — диде. Гамил аңардан теге Илсур дигән егетне гаепсезгә төрмәгә тыгучымы? — дип сорагач, Әскәров бераз уңайсызланып торды.

— Соң, иптәш майор, ни бит... — дип сүз башлаган иде, Гамил тиз туктатты.

— Соңыннан, лейтенант, сезнең белән сүз күп булачак! Сезнең аркада күпме кеше әрәм булды!

Теге өтелгән тавык, бераз басып торгач, бөкрәеп, машинасына таба китеп барды. Аның милиция карьерасы беткән иде инде. Шулвакыт урамның арткы ягыннан үкереп килүче машина тавышы ишетелде. Бу — Гариф абый утырган кара «Жигули» иде, бар куәтенә килеп, Азатларның ишегалдындагы нарат бурага барып бәрелде. Бераздан ут капкан машинаның бензин багы шартлады. Йортка ялкын үрмәләде. Бераздан тагын өч шартлау яңгырады, бу инде Азатның газ баллоннары иде. Азат кулына карабинын тоткан килеш, яна-көя күккә очты. Мәһабәт бина, тирә-якка чәчелеп яна иде. Ул башка йортлардан читтә булганга, кешеләр нигезенә зыян килмәде. Шулай итеп вәхши үз үлемен үзе сайлады. Йорт каршындагы бүрәнәдә Гамил утыра. Аның тирәсендә без, баскан килеш зур учакны күзәтәбез. Күпме кешенең башына җиткән бу адәм актыгы үзе дә эт үлеме белән үлде. Ләкин кешеләргә күпме бәхетсезлек, кайгы калдырып китте бу хәшәрәт. Мине бу уйларымнан машина килеп туктаган тавыш аерды. Бу Фатыйх Кәримович белән Зөфәр Хәлимович Әкълимә ханымның җеназасын алып кайткан машина иде. Фатыйх Кәримович, машинадан төшеп, безгә якынлашты. Ул безгә карамыйча гына:

— Азат андамы? — дип сорады.

Гамил йорт урынына караган килеш:

— Әйе, — диде.

— Улым, нишләп бу эшләрне эшләдең, ни җитмәде сиңа?!

Фатыйх Кәримович, йорт янына килеп, җирдә яткан фоторәсемне иелеп алды. Анда ул үзе, Әкълимә ханым, кызы һәм 14 яшьлек Азат иде. Ул сурәткә озак кына карап торды да, аны күкрәгенә кысты. Соңыннан борылып, авылдашлары каршына килеп:

— Кичерегез мине, зинһар, кичерегез! Сезнең алда берәр гаебем булса, кичерегез! — дип гафу үтенде. Ул арада Әкълимә ханымның җәсәден машинадан төшереп, Зөфәр Хәлимович, саубуллашмыйча да Казанга ычкынды. Бу авылның аңа хәзер кирәге беткән иде.

## XIX

Бу хәлләр булып үткәнгә дә бер ел вакыт узып китте. Әйтүләренә караганда, Фатыйх Кәримович, пенсиягә чыгып, Казанда яшәүче кызы янына күчеп киткән. Сәламәтлеге нык какшаган булса да, мәчеткә йөри башлаган, ди. Ә Илсурга килгәндә, ул теге хәлләрдән соң ике айлап вакыт үткәч, өенә әйләнеп кайтып, колхоз умарталыгында эшли башлаган.

Менә без утырган машина Чишмәлегә килеп керде. Без дигәнебез, Гамил, мин, аннан үзегез сизәсездер инде, Оксана. Шулай итеп, без Оксана белән тормыш корып җибәрдек. Бәхетебезнең чиге юк. Бар кешегә яхшылык эшлисебез генә килеп тора. Чишмәлегә Илсурның туган көне уңаеннан кайттык. Әнисе, сездән дә якын кешеләрем юк, улымның туган көненә кайтмасагыз үпкәлим, дип чакырган иде. Ничек инде кайтмыйсың да яңа бал белән чәй эчүдән баш тартасың?! Өстәвенә гаҗәеп олы җанлы апа чакырып торсын да.

Безне Илсурның әнисе бик җылы каршы алды. Ул, килеп, мине кочаклап алса, Оксананы үбеп:

— Кайттыңмы, кызым, матурым минем, — дип сөйләнде. Аннан миңа карап:

— Рәхмәт, улым, кайтуыгызга, әле менә Илсур белән Айсылуның каберен барлап, чәчәкләр утыртып кайттык. Ярый, әйдә, түргә үтегез. Гел кайгырып яшәп булмый, — дип, бездән яшереп кенә алъяпкычына күз яшьләрен сөртеп алды.

Түр якта, өстәлдә Айсылуның зурайтылган рәсеме тора. Аның калын чәч толымнары күкрәгенә салынып төшкән. Күз карашы әйтерсең лә мин дә сезнең белән, ди кебек. Мин рәсемгә төбәлеп карап торган Оксананың иңеннән кочаклап алдым, аның күзләреннән эре-эре яшьләр тама иде.

# АЛЛО, ХӘЛЛӘР НИЧЕК?



## I

— Алло, алло, кем бу? Дамир, синме? Сәлам, туган! Хәлләр ничек? Яхшы инде алайса. Бик әйбәт! Малайлар ничек? Ну, әйбәт булгач, бик яхшы! Сәлам әйт егетләрнең барчасына да! Без иртәгә Казанга очабыз, әйе. Шул сәгать 11 ләрдә саунада күрешә алырбыз дип уйлыйм. Һава шартлары үзгәрмәсә. Билетын өч бәягә алдык инде Касап белән. Ну, Мәскәү хәлләрен үзең беләсең бит инде, монда һәрбер җирдә ыштаныңны салдырырга торалар. Ярар, черт с ним, ни генә булмасын, Яңа елны Казанда каршы алырга исәп. Сауннаны яхшылап җылытып куегыз. Күчтәнәчләре миннән. Безнең хәлләргә килгәндә, ярыйсы. Шул чеченнәр белән бераз аңлашу булып алды. Болай нормально бетте. Шул абхазлар өчен инде. Без бит аларга «крыша». Менә Яңа елга дип бераз гына эш өчен тәңкәләр дә ыргыттылар. Ашарга-эчәргә җитә. Сезне сыйларга да җитәр. Калганын — кайткач, телефоннан күп сөйләшеп булмый... Карале, Дамир, братан, минем белән тагын бер кунак кайта. Мәскәү егете. Ну, кирәк чакта безгә булыша торган малай. Шуны кешечә каршы алыйк әле, Казан турында яхшы фикердә калсын. Берәр мәткә әзерләп куегыз, диюем. Акчасын үзем түлим. Чибәррәк татар кызлары булса тагын да әйбәтрәк инде. Бу Мәскәү себеркеләреннән туйган. Казанның кара татаркалары сагындырды. Монда бит рыжий марҗалар да, бөтен тәнен җон баскан еврейкалар гына. Үзебезнекеләргә җитми инде. Марсикка да әйт. Аның кызлары күп бит. Ну, анысы сезгә кала инде, уйлагыз. Ярый, пока, братан. Иртәгә кадәр!

Дамир пип-пип-пип дип кенә тавыш бирә башлаган телефон трубкасын куйды. «Димәк, Кубинец кайта. Ну, молодец, Серега! Чын егет инде ул! Ул кайтса, беркайчан да буш кайтмый. Кочак тутырып кыйммәтле аракы, сыра, затлы балык алып кайта», — дип уйлады Дамир. Алар һәр елны шулай бергә Яңа елны бер, йә булмаса ике көн элек саунада каршы алалар. Һәр шимбә көн бу уку йортының саунасы алар өчен генә эшли. Тышта кармы, көзге пычракмы, карап тору юк, рәхәтләнеп башта футбол уйныйлар. Уйный-уйный бәхәсләшеп, ызгышып бетәләр, чөнки җиңелгән команда барысын да сыра, шифалы су, шоколад белән сыйлый. Бу исә уйнаучы командаларны кыздыра гына. Беркемнең дә җиңеләсе, икенче команданы бушка сыйлыйсы килми.

Шулай да иң күңелле сауна Яңа ел алдындагы шимбәнеке санала, чөнки Мәскәүдә эшләүче, дөресрәге, «эш итүче» дуслары кайта... Дамир, шушыларны уйлап, җиңел сулап куйды. Аннан тукта, тиз генә Марсикка шалтыратыйм әле. Сереганың заказын да әйтермен дип, телефон трубкасын алды.

— Алло, Марсик, сәлам! Әле генә Кубинец шылтыратты, иртәгә саунага кайтып җитәбез, — диде...

***

Серега чыннан да соңгы көннәрдә бик нык арыды. Физик яктан гына түгел, психологик яктан да. Соңгы «стрелка»да аңа чечен егете белән бик озак сугышырга туры килде. Бәрелешү үзе тик торганнан гына килеп чыкты кебек. Бәлкем, тик торганнан да түгелдер, кем белә. Бәлкем, чеченнәр махсус, менә бездә нинди нык йодрыклы егетләр бар, дип күрсәтер өчен китереп чыгарганнардыр. Йә, ярар, чукынып китсен чәчәннәре. Иртәгә, Алла боерса, Казанга кайтып, бөтен дөнья пычракларын онытып ял итәсе бар. Ичмасам, күбрәк шул турыда уйлыйм әле.

Кубинец ничек кенә унбиш көн элек булган бәрелешне онытырга теләмәсен, шул турыдагы уйлары калка да чыга, калка да чыга иде. «Вәт анасын сатыйм, ә. Бик әздән генә оятка калмадым. Үзеңнән ун килога җиңел чечен егетенә бирел инде. Лачын кебек җитез булып чыкты, шайтан. Аяклары белән вертолет пропеллеры кебек эш итә. Ничек сикереп-сикереп тибә», — дип уйлады Серега. Үзенең берничә мәртәбә шул тибүләрдән егылып китүен исенә төшерде.

Барысы да бер дә юктан башланган кебек булды, ләкин бу кул сугышының артында психологик киеренкелек тора иде, ярый әле кул сугышыннан атышуга күчмәделәр. Ике як та бу хәлне тыныч кына күзәтеп торды. Сугыш тукталгач, ике арадагы киеренкелек йомшарды. Чөнки ике егетнең берсе дә җиңмәде дә, җиңелмәде дә. Шулай да Серега Яруллинга күбрәк эләкте. Чечен егетенең аяк белән биткә тибүләре иренен ярып кына калмады, күз төпләренә күгәрекләр дә кундырды. Дөрес, Сереганың коточкыч кизәнүләре чечен егетендә көтелмәгән каушау уятты, аның үз-үзенә булган ышанычын киметкәннән-киметте, дошманына карата хөрмәт уятты. Кайбер сугулардан Аслан исемле бу егет чак кына аңын югалтмыйча калгалады.

Серега чечен егетен берничә мәртәбә күтәреп алып та бәргәләде. Ләкин теге мәче кебек аягына гына төшә иде. Кубинец каршы сугышучының гади генә йодрыклы түгел икәнлеген чамалап алды. Каршысында каратэдамы, кикбоксингтамы яхшы әзерлек алган сугышчы торганын сизү аны җиңелүдән саклап калды. Ул тагын да зур саклык белән сугышырга тотынды.

Сәгатьтән артык барган сугышу хәлләре бетеп икесе дә аяктан егылганчы дәвам итте. Ике якның берсенә дә җиңү бирерлек түгел иде. Шулай да Сереганың җәрәхәтләре күбрәк булып чыкты. Ул шуңа нык гарьләнде. Ә бит бәрелеш бер юктан башланып китте. Спорт залындагы бердәнбер телефонны Кубинец алуга, чечен егете, мин беренче шылтыратам, дип килеп ябышты. Бу провокация иде. Әгәр җиңелсә, «стрелка» ни белән беткән булыр иде икән? Ике як та шуннан соң гына бәхәсләшүдән туктап, уртак фикергә килә башладылар бит. Яруллинның җиңелмәве тиз кызучан чеченнәрнең өсләренә салкын су койгандай булды.

Шулай да соңыннан Казан егетенә бер атнадан артык урын өстендә ятарга туры килде. Иң кызыгы урын өстендә ятканда булды. Өченче көн дигәндә, алар фатирына коньяк белән шоколад тоткан чечен егете Аслан үзе килеп керде. Аны күреп ачуы кузгалса да, егетнең ачык йөзен, кулындагы күчтәнәчләрен күреп, бераз тынычланды. Чечен егетенең: «Теге көнге өчен гафу ит, туган, шулай килеп чыкты инде. Ну, син — молодец, татар малае... шәп сугышасың бит», — диюенә каршы, Серега: «Аллага шөкер, син дә төшеп калганнардан түгел, «истәлекләрең» әле дә бетми менә», — дип, сүзне шаяруга борды. Соңыннан Аслан ике стакан сорап алды да, аларны коньяк белән шыплап тутыргач: «Әйдә, туган, чечен белән татар дуслыгы өчен», — дип, үзенекен күтәрде. Озакламый алар арасында бернинди киеренкелек тә калмаган иде инде. Әңгәмә дустанә юнәлешкә күчте.

— Ну син, Аслан, аяк белән шәп эш итәсең. Әгәр дә аякларың булмасамы?..

— Әгәр синең дә кулыңдагы берәр тонналы ударларың булмасамы?.. Сер итеп кенә әйтәм, татарин, мин бит тегенди-мондый гына сугышчы түгел... Син хет кем белән сугышканыңны аңладыңмы соң? Синең белән бит кикбоксинг буенча беренче авыр үлчәүдәге дөнья чемпионы Аслан Мөбарәк улы сугышты.

Яруллин, алдашмый микән бу дип, тегенең күзләренә гаҗәпләнеп карады. Егетнең күзләре ялган сөйләми иде.

— Елки-палки, әле бит мин үз-үземә үпкәләп ятам. Синең кулдан җиңелсәң дә хурлык түгел икән бит, — дип, Серега егеткә кулын сузды. Аслан аның кулын кысып, шаркылдап көлеп җибәрде. Аннан Казан егетен кочаклап ук алды.

Алар шулай төрле хәлләр турында сөйләшеп бер ярты сәгатьләп утырганнардыр. Сәясәткә дә күчеп алдылар. Аслан

акыл ягыннан да сыек малай булып чыкмады. Ул үз халкы турында болай диде:

— Без бит, туган, тик торганнан гына шушы юлга басмадык. Безне бит Мәскәү түрәләренең изүе, баш ияргә теләмәвебез шушы юлга этәрде. Безнең бит бөтен халкыбызны хайваннар урынына төяп читкә сөргәннәр. Күпме туганнарыбыз авыр юлда, сөргендә вафат булган. Чын дию бит Мәскәүдә ул, Грозныйда түгел, туган. Мәскәү бит ул — иң караңгы угрылык, иң әшәке икейөзлелек оясы. Шуңа күрә бөтен кара көчләр биргә җыела да. Без дә шуңа биредә. Әгәр дә эшләп гаиләмне, туганнарымны карарлык акча алсам, мин биредә йөрер идемме? Бушка бу Мәскәү каракларына эшләргәме, тотсыннар менә!

— Шулай шул, — дип, аның сүзен Серега да хуплады.

Аерылышканда Кубинец Асланнан:

— Аслан, теге көнне бәрелеш алдан уйланылган эш идеме, әллә юкмы? — дип сорады.

— Хәзер бу нәрсәгә кирәк инде, иң мөһиме — без бит дуслар, — дип, Аслан ишеккә юнәлде.

Инде менә бу хәлгә дә ике атна үтеп киткән. Шулай да битендәге күгәргән эзләре бетмәгән иде.

Егет сөйләшү пунктының стенасына эленгән көзгегә күз салып алды. Сул күз төбендәге күгәргән эзе әз генә беленә иде... «Иртәгә Казанга очар алдыннан гримларга туры килер. Кара күзлекне дә алырмын», — дип уйлап куйды ул.

## II

Шимбә көнне иртән футбол уенын җидедә үк башлап җибәрделәр. Чөнки тугызларда Айнур белән Эдик Мәдәният һәм сәнгать Академиясенә барып кызлар алып килергә, калганнар ул арада табын әзерләргә килештеләр. Унберләрдә Мәскәү кунаклары кайтышка бар нәрсә дә әзер булырга тиеш иде. Табын өчен җаваплылыкны Марс үз өстенә алды. Ул үзенең «девяткасы» белән базарга барып казылык, катык, чәкчәк, өчпочмак, пәрәмәч, каклаган каз алырга тиеш. Мәскәү кунагын татарчарак сыйларга булдылар.

Футболдагы исәп 5:3кә җиткәч, оттырып баручы команда әгъзасы Айнур Дамирны аяк чалып екты. Тегесе, кар өстенә барып төшкәч, ачуы чыгып: «Син нәрсә эшлисең, мудак, шулай уйныйлармы?» — дип сикереп торып, җәберләүчене этеп җибәрде. Айнурга бу ошамады.

— Син нәрсә этенәсең, анаңны шулай итим, — дип, ул Да-

мир өстенә йодрыкларын йомарлап килә башлады. Дамир да бокс стойкасына басты. Айнурның тибәргә дип кизәнүе булды, кырыйга тайпылып калган Дамир уң кулы белән сугып җибәрде. Ләкин Айнур да төшеп калганнардан түгел иде. Ни әйтсәң дә, спецназда хезмәт иткән, әрмәннәргә каршы Карабахта сугышкан. Башына төбәлгән йодрык күкрәгенә генә эләкте. Шул чакны, эшне зурга җибәрмәс өчен, арага Марс килеп керде.

— Егетләр, бүгенге уен, кем генә җиңсә дә, зур роль уйнамый. Сәгать 11 дә малайлар кайта, табынны да уртакка әзерлибез. Әгәр инде көчегезне кая куярга белмисез икән, әйдәгез, алайса икегез дә мине кыйнагыз, — дип, тегеләргә чакыру ясады. Айнур гарьчел кеше булса да, Марстан шикләнә иде. Башта ул: «Нәрсә, Мөхәммәт Али мәллә син?» — дип, каршы дәшәргә уйласа да, тыелып калды. Чөнки Марс алты мәртәбә — Татарстан, ике мәртәбә Рәсәй чемпионы иде. Өстәвенә, бөтен калган боксчылар аңа буйсына, аны баш саныйлар. Айнур исә бирегә спорт мастеры Илнурга ияреп килеп, соңыннан гына боксчы егетләр арасында үз булып киткән кеше. Үпкәсен эченә җыеп, Айнур Дамирга кулын сузды. Ләкин барысының да кәефе кырылган иде инде. Шуңа күрә Марс болай диде:

— Менә нәрсә, егетләр! Хәзер бер туп керү белән уен бетә. Җиңелүче команда кертсә, ничья була, без кертсәк, җиңгән булабыз. — Аннан Дамирга борылды. — Яле, Дамир, баш киемеңне бир әле.

Тегесе аптырап калды:

— Ни пычагыма кирәк ул? — Шулай да салып бирде. Аның бокстанмы, әллә бик акыллы, йә бик акылсыз булуыннанмы пеләш калган башына Марс бер уч кар алып сипте дә:

— Кар, яңгыр суының чәч үстерергә файдасы бар дигәннәр иде, сынап карыйк әле, — дип, шаркылдап көлде. Бу шуклыктан башка егетләр дә көлеп җибәрделәр. Аптырап калган Дамир гына, исенә килеп:

— Син нәрсә эшлисең, козел, — дип Марсны куарга тотынды. Марс исә кушаяклап чаба торган ат кебегрәк итеп, мәзәк рәвештә чабып йөри башлады. Аны эзәрлекләүче, инде үзе дә бу күренештән көлеп, Марска кар йомрысы тондырды. Тегесе иелеп калып, кире чабып килде дә, бер читтә торган тупны көндәшләре капкасына тибеп кертте. Аннары:

— Булды, егетләр, футбол тәмам, — дип, мунчага таба йөгерде. Бер рәткә тезеп куелган машиналар арасыннан ян бе-

лән сикерә-сикерә үтеп, ишектән кереп тә югалды. Урамда калган малайлар әле һаман да тыела алмыйча көләләр иде...

Сәгать 11 тулып 10 минутлар үткәндә, урамда машина сигналы ишетелде. Бар да тышка юнәлде. Юл кырыена такси килеп туктаган иде. Аннан Кубинец, Касап һәм тагын бер чит егет төште. Серега егетләр янына килеп, барысы белән дә кочаклашып күрешеп чыкты. Касап та аны кабатлады. Чит егет кул биреп кенә исәнләште.

Таксист машинасыннан чыгып аларны күзәтеп тора иде. Кубинец моны күреп:

— Абзый, тизрәк бушат күчтәнәчләрне, нәрсә катып торасың? — дигәч, таксист каушый төшеп, багажниктан ике карбыз, ике кавын, биш шешә «Абсолют» аракысы, бер төргәк сыра, ике шешә коньяк, бер шешә шампан шәрабы һәм дә төрле сыйлар белән дыңгычлап тутырылган ике пакет чыгарды.

— Яле, егетләр, әйберләрне кертеп урнаштырыйк әле. Ә, онытып та торам, бу — минем кунак, Мәскәү егете Игорь Подольский.

Бар да кунак егет белән исемнәрен әйтеп кабат исәнләшеп чыктылар. Бер кырыйда таксист кына аптырап карап тора иде. Яруллин аны күреп:

— Абзый, мин сиңа күпме тиеш соң? — дип сорады.

Таксист шикләнеп кенә:

— Бер утыз сум булса җитә инде, — дип куйды.

Серега Яруллин кесәсеннән бер төргәк акча чыгарып, шуннан илле сумлыкны алды да, таксистка сузды.

— Рәхмәт, энекәш, рәхмәт. Егетләр, күңелле ял итегез! — дип, таксист машинасына юнәлде.

— Абзый, тукта әле!

Таксист, нәрсә булды икән инде тагын дигәндәй, гаҗәпләнеп, артына борылды. Аңа, зур гына кызыл балык сузып, Мәскәү егете карап тора иде.

— Бусы, абый, җиңгигә күчтәнәч.

— Ну, егетләр, бик зур рәхмәт сезгә. Куандырдыгыз. Телисезме, мин сезне соңыннан килеп алам?

— Кирәкми, абый, рәхмәт.

— Юк, егетләр, мин акчага түгел бит, анысын бушка эшлим. Бик толковый егетләр булып чыктыгыз, — дип егетләргә карады. Серега елмаеп:

— Абый, менә биредәге машиналарны күрәсеңме, алар барысы да безнеке. Сау булыгыз, — дип, кулына ике пакет алып, ишеккә юнәлде.

Эчтә, ял бүлмәсендә өстәлдә, нинди генә ризык юк иде. Мәскәү кучтәнәчләре дә менеп кунгач, табын патшаларныкына охшап калды.

Табынны барлап чыккач, Кубинец шулай да нидер эзли иде. Эзләгәне күренмәгәч, ул Марсны бер читкә дәште.

— Кара әле, Марсик, теге әйбер булмадымыни? Мин кунак егеткә барысы да булачак, рәхәтләнеп ял итәрсең, дип әйткән идем. Ул бик кирәкле егет. Әтисе блатной урында эшли, аның аша информация алып торабыз.

Тегесе исә, баш белән генә ымлап, үзе артыннан чакырды. Башта алар юыну, аннан соң чабыну бүлмәсенә үттеләр. Марс ишекне ачып җибәрүгә, Серега сызгырып куйды:

— Ну молодец, братан! Ну, булдыргансың, Марсик!

Сауна эчендә берсеннән-берсе гүзәл яшь кызлар утыра иде. Барлыгы алты кыз булып чыкты. Кайсын кунак егеткә бирергә икән? Берсе берсенә торырлык иде болар. Кызлар да үзләренең егеткә ошауларын аңлап көлеп җибәрделәр.

— Игорь туган, кил әле бирегә! — дип кычкырды Кубинец.

Кунак егет күренде.

— Менә, ичмасам, кызлар бу! — дип куйды ул.

— Кызлар, яле, кунак егетләрне үз янгызга алыгыз, — дип команда бирде Марс.

Кызлар кунакларны чишендерә дә башладылар. Аннан аларны ләүкәгә сузып салдылар да, яхшылап пешерелгән каен себеркеләре белән чабарга тотындылар.

## III

Озакламый ял итү бүлмәсенә Гүзәл исемле чибәркәйне кочаклаган Кубинец килеп чыкты. Бу атлет гәүдәле баһадирны кызлар әйбәт чабындырганнар, ахры, тәненә кызыл-кызыл тимгелләр чыккан иде. Аның ерылган авызына карап, кәефе бик күтәренке икәнен белергә була иде.

— Ну, егетләр, зурладыгыз. Шундый лафа, искиткеч! Ә кызлары ни тора, ә! Карагыз әле бу чибәркәйне! Мәскәүдә мондыйлар бар дип уйлыйсызмы әллә? Булса да, алары да татардан яралган аның, — дигәч, егет кызның «кабартмаларын» сыйпап алды. Гүзәл исә барыбер егетләрдән ояла иде. Ул үзе белән алып килгән пакеттан җилкәнле көймә төшерелгән сөлге чыгарып биленә урады. Шулчак Илмира исемле гүзәлкәйнең иреннәрен бертуктаусыз үбә-үбә икенче кунак егет тә күренде.

— Яңа ел белән котлыйм сезне, братцы. Кызларыгыз во-о! —

дип, баш бармагын күрсәтте. Мәскәү егетенең канәгать калганлыгын белгәч, казанлылар сөенешеп кул чаптылар. Барысының да кәефе күтәренке, һәм ул торган саен тагын да күтәрелә бара иде.

Марс сүз алды:

— Егетләр, соң, әйдәгез, күрешү һәм бәйрәм хөрмәтенә шампанскийларны ачыйк булмаса, Дамир, син бар, калганнарны да чакыр! Эдик, бокалларны өстәлгә куй! — дип әмер бирде. Бераздан бәллүр бокаллар чыңлаган, кыздырылган тавык, колбаса тураган, шоколад кәгазь чытырдаган тавышлар ишетелде.

Барысы да җыелып беткәч, Марс яңадан сүз алды, ул, кулына шәраб тутырылган бокалын күтәреп:

— Туганнар, дуслар! Инде менә без ничәнче Яңа елыбызны бергә каршы алабыз. Хәтерем ялгышмаса, бусы бишенчесе бугай», — диде.

— Юк, быелгысы алтынчы, Марсик, — дип, Дамир төзәтмә кертеп алды.

— Алты ел да булган икән алайса. Инде мин нәрсә әйтмәкче булам. Беренчедән, безнең Мәскәүдә эшләүче егетләребез, хәлләре нинди генә булмасын, Яңа елны ата-аналарының туган нигезенә кайтып каршы алалар. Бу безнең өчен бик зур шатлык, туганнар, Ходай Тәгалә безгә исәнлек-саулык бирсен. Башка беркемгә ышаныч юк. Хөкүмәткә без кол буларак кына кирәк. Ә без әти-әниләребез кебек кол булырга теләмибез, господа! Мондый гүзәл кызларны, сый-хөрмәт белән тулган өстәлне безнең әтиләр-әниләр күргәнме? Юк, әлбәттә. Күрмәячәкләр дә, соң инде. Вакытлары үткән. Алар иртәнге биштә эшкә китеп, кичке алтыда эштән кайтып, ашарларына көчкә җитәрлек хезмәт хакы алып, барак-шалашларда тараканнар арасында безне тәрбияләргә тырышканнар. Ат урынына эшләп, чебен хәтле хезмәт хакына яшәп буламы? Булмый, әлбәттә! Шуңа күрә без кечкенәдән көчле булырга тырыштык. Чөнки җиңәр өчен көч кирәк. Аллага шөкер, безне хөрмәт итәләр. Димәк, без коллар түгел! Ходай Тәгалә барыбызга да озын гомер бирсен! — дип, бокалын башкаларныкы белән чәкештереп чыкты. Шәраб эчелгәч, егетләр кызларга шоколад кисәкләре суздылар. Тегеләре исә, рәхмәт әйтеп, тыйнак кына кыланып, әз-әзләп каба-каба гына шоколад кимерергә тотынды. Бәйрәм дәвам итте.

Тагын бер ярты сәгатьтән кызлар-егетләр арасындагы тартыну, уңайсызлану кебек тойгылар беткән иде инде. Бар да шау-гөр килеп кызык хәлләр, мәзәкләр сөйләде. Марс кына

каядыр җыенган кебек тоелды Кубинецка. Ул аны читкә чакырып алды:

— Син нәрсә, Марсик, безне ташлап качмакчы буласыңмыни?

— Серега, китим мин. Өстәлдә ашау-эчү җитәрлек. Кызларыгыз яныгызда. Мин карт кеше бит инде. Өйдә әнә карчык көтә, — дип, Марс дус егетенә елмаеп карады.

— Гафу ит, Марсик, мин бит әле онытып та торам. Сез бит бәби алып кайтырга җыенасыз икән Ләйсәнкә белән. Дамир сөенче алды. Тәбрик итәм, туган!

— Әйе, Алла боерса! Алтынчы аен күтәреп йөри. Шуңа да өйгә кайтмакчы идем. Соңга калып кайтсам, көнләшә. Көмәнле чагында нервыландырасым килми. Бала гына сәламәт тусын.

— Туар, Алла боерса, туачак. Синең кебек егеттән разве башка төрле бала туарга тиеш. Бер генә секунд сабыр ит, Марсик. Мин хәзер, — дип, баһадир гәүдәле егет киемнәр эленгән якка китте.

Марс аның алып гәүдәсенә сокланып: «Да, моның кулына эләксәң, муеныңны шыртлатып сындыра инде. Беркемнән курыкмый бит. Мин менә ике мәртәбә Рәсәй чемпионы — мине дә уйлап та бирми ул», — дип уйлады.

Бераздан кулына нәрсәдер тоткан Серега күренде.

— Марсик, менә бу — миннән бүләк. Синең нәниең туарга күп калмаган икән. Ул тугач, йә кайтып булмас, бүләген биреп куям. Мә, туган. Үзеңә нәрсә ошый, ни телисең, шуны алырсың балага. Менә монда биш кисәк.

— Биш кисәк?! Син нәрсә, Серега! Шуның хәтле акчаны! Әле тумаган балага.

— Марсик, бала-чага булма инде. Ал яхшы чакта. Югыйсә алар барыбер уңга-сулга, хатын-кызга, чүп-чарга тотылып бетәчәк, — дип, акчаны Марсның чалбарына кыстырды.

— Рәхмәт, Серега. Шулай да, уңайсыз миңа.

— Дәшмә, булды. Акчаларыңны алып куй да, беркая да китмисең. Ләйсәнгә хәзер үзем шылтыратып әйтәм, бераз тоткарланабыз дип. Аннан ни, бу кызларыңа яртышар кисәк бирсәм, җитәме? — Марс аптырап калды.

— Күпме, күпме?!

— Син нәрсә, Серега,мин бит инде аларга ике йөзәрне биреп чыктым барысына да, — диде.

— Бирсәң соң. Тагын бирик. Икенче юлы алар безнең янга йөгереп кенә киләчәкләр. Өстәвенә кисәтеп тә куярбыз, безнең белән генә очрашсыннар.

— Син кайтканны алар айлар буе көтеп утырырлар дип уйлыйсыңмы? Ялгышасың, туган, синең белән миндә булган нәрсә бүтәннәрдә дә бар. Шуңа күрә, акчаларың белән бик ыргытынма. Кызларны аздырасың. Ике йөзәр бирелгән. Өстәл тулы сый. Алар бит үзләре белән укучы студентларга бушлай бирәләр. Бүген биш йөзгәияләшсәләр, иртәгә бер меңгә дә риза булмаячаклар. Горбачев абзый әйтмешли, «дәүләт көйләве» булырга тиеш.

— Аңлашылды. Алайса бу өч кисәкне сезнең «уртакка» салам.

— Менә анысын үзеңә кара. Ярый, алайса әйдә, кунаклар янына барыйк. Яхшы түгел. Мәскәүле дә бу якка еш карый башлады, — дип, Марс табында калырга ризалык бирде.

Тагын ике сәгатьләп утыргач, егетләрнең бер өлеше кайтып китте. Саунада алты пар гына калдылар.

## IV

Марс, иртәнге алтыларда уянып, тирә-юньгә карады. Тегендәмонда чәчелеп яткан кыз-егетләрне күреп, кайда ятканын төшенде. «И Алла! Ләйсәнгә, Серега Яруллин белән төнге 12 ләрдә кайтып җитәбез, дип сүз биргән идем бит. Вәт, шайтан алгыры, бу аракы нишләтә. Бөтен дөньяларны оныттырган», — дип уйлады. Ул тагын төнлә ниләр булып беткәнен исенә төшерергә тырышты. Чыгып эчтеләр дә, кереп чабындылар. Аннан кабат-кабат керделәр. Гүзәл белән Альбина ялангач килеш өстәл өстенә менеп биеделәр. Серега аларга ике йөзәр сум биреп чыкты. Аннан ул Тәнзилә исемле кыз белән йоклады. Соңрак тагын Альбина белән. Аннан Алсу белән. Аннан калганнары белән. Анасын гына сатыйм, бер төндә алты кыз белән!

Ул, торып, ял итү бүлмәсенә юнәлде. Өстәл өстендәге шешәдән зур бокалга шифалы су тутырып эчте. Битенә, тәненә салкын тир бөртекләре бәреп чыкты. «Бер төндә алты себерке белән йокла инде. Ләйсәнгә нәрсә дип җавап бирергә? Бала табарга йөрмәсә, шайтаныма олаксын иде дә...» — дип уйлап, юыну бүлмәсенә юнәлде. Башта марганцовка эремәсе белән оят җирләрен яхшылап юды, аннан трусигын сыгып, кайнар батарейга элде. Шәхси гигиена таләпләрен үтәгәч, сауна ләүкәсенә кереп ятты.

Бераздан Кубинец та килеп керде.

— Ну, Марсик брат, рәхмәт! Шәп ял иттек. Мәскәү егетенә

дә бик ошаган. Безнең кызлардан бөтенләй мөкиббән китте инде. Бот араларыннан чыкмады да диярлек.

Яруллинның авызыннан чыккан сасы аракы исе Марсның борынына килеп бәрелде. «Минекеннән дә тәмуг исләре киләдер инде. Чыккач, яхшылап авызны чистартырга кирәк булыр», — дип уйлап куйды. Соңыннан:

— Ярул, без бит кичә Ләйсәнгә төнге 12 дән дә соңга калмыйча кайтабыз, дип сүз биргән идек. Өйдә ышкыйлар инде безне. Нәрсә эшлибез? — дип сорады.

— Соң, әйдә, болай итәбез. Эчкән килеш машинага утырдың да, ГАИ туктатты. Алар белән бәйләнешкән идек, каталажкага яптылар. Иртә белән акча түләп праваңны да алдык, үзебезне дә чыгарттык. Билләһи, ышаначак. Хәзер кайтышлый, милициягә кереп, берәр кәгазь ясатабыз. Аннан хатыныңа зур букет роза, бер яхшы күлмәк алам.

Яңа елны өйдә каршы алгач, 2 гыйнвар көнне кызлар белән кабат күрешергә сүз куешылды.

Илнур белән Дамирның машиналарына утырган кызлар, тәрәзә аша кул болгап, китеп бардылар. Серега Марска:

— Әйдә, туган, башта Проспекттагы базардан бүләкләр алып, синең хатынны тынычландырып чыгыйк. Аннан без Игорь белән өйгә сызарбыз. Әнине котлап, бәйрәм көнен аның янында гына үткәрергә кирәк.

Айнып та бетмәгән Подольский борчыла калды.

— Ә кызлар? Аларны бүген күреп булмыймы?

— Әле арымадыңмыни?

— Арырга, нәрсә, вагон бушатмадым ич мин, әле хәл җитәрлек миндә, братцы, — дип, кунак егет күкрәк кагып алды.

— Ярый, алайса, бүген теге алты кызның берсен алып кайтырбыз. Әнигә йөргән кызың диярбез дә... Киттек, алайса, егетләр!

Өйдә корсагы колхоз рәисләренеке хәтле булган Ләйсән кара көеп каршы алды. Аның элек-электән зәңгәр күзләре тагын да зәңгәрләнгәннәр иде. Серега хатынны күрүгә биредәни көткәнен аңлап: «Кирәкми иде сиңа, Марсик, ул сержантка «пошел ты, козел» дияргә. Праваңны бирергә дә китәргә кирәк иде. Синең аркада бер төн ментовкада ятып чыгарга туры килде. Бераз салгач, бөтенләй әтәчләнеп китәсез, егетләр. Андый чакта сүз дәшәргә ярамый. Гафу итегез, фәлән-төгән, гаеп бездә инде дип бер-ике меңне төртә идек тә, котыла идек. Тәк, Ләйсәнүшкә, сине якынлашып килүче Яңа ел белән чын күңелдән котлыйбыз. Озын гомер, сәламәтлек һәм таза, матур

бер егет алып кайтуыңны телибез. Яле, Игорь туган, безнең гүзәлләрнең гүзәле Ләйсәнебезгә бүләкләрне бир әле», — диде.

Игорь Подольский, зур чәчәк букетын хуҗабикәгә тапшырып, икенче кулындагы пакеттан кыйммәтле костюм чыгарды. Әйбер, чыннан да, затлы иде.

— Рәхәтен күрергә язсын. Җылы өстегездә тузсын, — дип, Серега хатынны кочаклап алды. Башта ни әйтергә белмичә аптырап калган Ләйсән, бу бүләкләрнең үзенә икәнен төшенгәч, матур итеп елмаеп җибәрде.

— Соң, милициядән шылтыратып әйтергә була иде ич. Төне буе кайгырып чыктым, — диде ул.

— Ләйсән, анда кем безгә телефон бирсен инде. Беләсең бит андагы тәртипләрне. Ярый, әйдә, кунакларны ишек төбендә тотма, түргә узсыннар, — диде хуҗа кеше.

— Зинһар, гафу итегез, Серега! Әйдәгез, узыгыз! Үзе гаепле ул. Аның аркасында сезгә эләгә. Ай саен каядыр югала. Өйдә телефон булмаса бер хәл иде. Шылтыратып әйтергә була бит, Сергей! Менә син үзең шулаймы? Әлбәттә, андый түгел. Күреп торам, тәртипле егеткә охшаган син. Ә ул?! Әйт әле шуңа!

— Соң, Ләйсәнкә матурым, ир кеше өйдә утырса, тормыш бармый бит инде ул. Бераз өйдә тегесе-монысы булсын дисәң, чабарга, табарга туры килә. Кайсы вакытта юлда да куныла. Анда кая телефон табасың? — дип, Яруллин акыл сатарга тотынды. Хатын, ризасызлыгын сиздереп, тезеп китте:

— Алай гына булса ярар иде ул. Әллә ничә мәртәбә трусигын югалтып кайтты. Бер мәртәбә хатын-кызларныкын киеп кайткан иде. Инде пычранып кайтуларын әйтеп тә торасым юк. Шакшы тәре. Инде, балага узгач, туры өйгә кайта башлаган иде. Тукта, рәткә керде бу да, ниһаять, дип сөенгән идем...

— Ярар инде, Ләйсән, кеше янында хет лыкылдама. Берәрсе керсә гел килде-китте сүз сөйлисең син. Ташла әле шул гадәтеңне, — дип, Марс тавышын күтәрде.

— Син үзең килде-китте! Хайван! Әгәр балага узмаган булсам, бер секунд тормас идем мин синең кебек итәк колы белән.

— Ләйсән, дим! Әйдә, кунакларны сыйла. Алар синең вәгазеңне тыңларга түгел, Мәскәүдән Яңа ел каршы алырга, ял итеп китәргә дип кайттылар. Алар киткәч, үземә генә сөйләрсең, булдымы?

— Үзең гаепле. Инде кичә дә, тукта, болар кайтырлар дип

пилмәннәр бөгеп куйдым. Бүгенгә аның рәте дә калмагандыр инде. Алдакчы тәре. Милициядә дә булмагансыңдыр әле син.

— Менә штраф түләгән кәгазь, мә, кара ышанмасаң, — дип, Марс хатынына ниндидер квитанция сузды. Үзе тиз генә хатыны күрмәгәндә кунак егетләргә күз кысып алды.

— Кирәкми кәгазең дә. Зинһар, гафу итегез инде, әйдәгез, аш бүлмәсенә узыгыз, кунаклар. Менә гел шуның аркасында инде. Аның аркасында бер гаепсез кешеләргә дә эләгә. Паразит! — дип, хатын аш бүлмәсенә таба атлады. Аның артыннан егетләр иярде.

Бүлмәгә кергәч, Марс кесәсендәге бүләк акчаларны чыгарды:

— Ләйсән, менә бу акчаларны бала тугач бүләкләр алырга Кубинец бирде. Мә, җыйнап куй әле. Югыйсә минем кулга эләксә тотып бетерәм.

Ләйсән, күп акча күреп:

— Кит әле, шуның хәтлеме?! Серега, ә үзеңә калдымы соң? Бигрәк күп бит бу. Әниеңә бүләк алырга кирәк булса? — дип гаҗәпләнеп, егеткә күз сирпеде.

— Җитәр, Ләйсән, кайгырма. Бүләкне алдан биреп куйдым. Йә кайтып булмас. Мине дә искә алырсыз шунда. Сөйләштекме?

— Ой, юмарт та кеше инде син, Серега. Рәхмәт, сиңа, — дип, Ләйсән егетне үбеп алды.

— Кара, кара, чит ирләрне ничек үбә. Мине — юк, — дип, Марс юри турсайган булды.

— Син тәрбиясезне кичкә инде. Хәзергә башкаларны яратып карыйм әле. Сиңа яраган миңа ярамыймы әллә? Утырыгыз, әйдә, егетләр, — дип, яшь килен бер шешә коньяк чыгарып утыртты. Аның кәефе баштагыдан бик күпкә яхшырак иде инде. Озакламый өстәлгә пилмән дә чыкты. Марс өч рюмкага коньяк салып, урыныннан торды.

— Егетләр, олылап килгәнегезгә бик зур рәхмәт. Минем хатын сүзләренә колак салмагыз инде, хатын-кызны үзегез беләсез, — дип, Ләйсәнне кочаклап үбеп алды. —Барыгызны да якынлашып килүче Яңа ел белән тәбрик итәм. Озын гомер, исәнлек, бәхет телим. Шуның өчен, дуслар, — дип, рюмкасын чәкештерде. Егетләр күтәреп эчеп тә бетерделәр. Хатын исә аларның эчүенә карап чыраен сытып куйды. Бераздан ул, көтмәгәндә:

— Алла, Алла, нишли ул? — дип кычкырып җибәрде. Бар да

аптырап аңа текәлделәр. — Типте! Әле болай нык типкәне юк иде. Йа Алла! Әллә сезнең эчеп утырганны сизә инде.

Марс, хатынының корсагына башын куеп, тыңларга тотынды.

— Нәрсәдән риза түгел икән ул? — дип, Сереганың шаяртып соравына, Ләйсән:

— Атасының әллә кайда йөргәненә риза түгелдер, — диде.

## V

Марс егетләрне озатып, машинасын куйгач, яңадан базарга кереп хатынына чит ил косметикасы алды. Розалар бәйләме инде булганга, канәфер чәчәкләре бүләк итәргә булды. Базарда эше беткәч, кайтышлый супермаркеттан «Татарстан» торты һәм җиңел вино да эләктерде. «Бүген Яңа елны өйдә каршы алып, беренче гыйнварны да өйдә генә уздырырга кирәк. Икенче көнне Чаллыга барып кайтасыбыз бар, дип чыгып таярмын инде. Чөнки Мәскәүдән кайткан duслардан яхшы түгел», — дип уйлады ул.

Хатынына табын әзерләшкән арада да, әллә ничә мәртәбә телефон шылтырап, Яңа ел белән котладылар. Кайсыберсе кунакка чакырды.

Егет пилмәнен дә бөкте, тавыгын да турады, салатка кишер дә кырды, сарымсагын да ваклады. Залдагы өстәл өстенә өч төрле салат, балык, казылык, хуҗа кешенең яратып ашый торган пәрәмәчләре менеп утырды. Кыл уртага гранат, алма, груша, йөзем тәлгәшләре тезелгән зур ваза, аның янына «Татарстан» торты куелды. Марсның бу иң яраткан ризыкларының берсе иде. Кыздырылган тавык ботлары да күренгәч, егетнең түземлеге бетте: «Әллә, дим, карчык, берәр тавык боты кимереп, бер йөзәр граммны төшереп куйыйкмы? Мин сиңа «сухойны» алдым. Әпитит кузгалып китте әле минем», — дип, өстәлгә тәлинкәләр урнаштырып йөргән Ләйсәненең артыннан кочып алды. Хатын да аңа арты белән сыланды: «Бераз гына түз инде, пилмәннәрне салган идем, ун минуттан әзер булалар». Марска эш беткәнлектән, ул телевизорны җибәреп үзенә ошарлык программа эзләде. Казаннан татарча концерт бара иде. «Тукта, Салават та җырлар әле, бәлкем», — дип, егет шушы каналга тукталды. Озак көтәргә дә туры килмәде — Салават үзе күренде. Хуҗа да җырчыга кушылды:

Тормыш бит ул, бер карасаң, елмаеп көлгән кебек,
Икенче яктан карасаң, шәмнәре сүнгән кебек.
Килә ява, килә ява ияләшкән бер болыт,
Очар канатларым булса, тормас идем бер минут.

— Ну, молодец, Салават! Ярый әле син бар күңел юатырга!

Залга Ләйсән кереп өстәлгә кечерәк кенә савытны куйгач, кәнәфидә утырган ире алдына килеп елышты:

— Марсик, дим, кайчан алып барасың инде шуның концертына? Инде ничә ел алдалап йөрисең. Әйдә, барыйк инде. Гыйнвар ахырында тагын була ди.

— Чынлапмы? Әлбәттә, барабыз, карчык. Таш яуса да бу юлы барабыз, — дип, хатынының җилкәсеннән кочып алды. Салават җырлап бетергәч, яшь гаилә өстәл артына утырды. Төн уртасы җитәргә биш-алты минут калган иде. Марс хатынының бокалына шәраб, ә үзенә коньяк салгач:

— Әйдә, карчык, Яңа еллар котлы булсын! — дип, тост тәкъдим итте.

## VI

Яруллиннар Мәскәүгә очканга да биш көн булды. Аңа ияреп кайткан кунак егет бик разый булып китте. Дүрт көн буе чибәр-чибәр кызлар кочагында ятып балда-майда йөзү аңа чыннан да ошаган иде. Бөтен чыгымнарны диярлек Кубинец үзе каплады. Аның хәтле акча туздырма инде дигәннәргә: «Дөньяда бер генә яшибез, дөнья малы — дуңгыз каны ул, булганда типтереп яшәп калырга кирәк», — дип кенә җибәрде...

Егетләр киткәннән бирле Марсның бер тамчы да хәмер капканы булмады. Хәл керсен өчен ике мәртәбә спорт залына барып капчык кыйнап, соңыннан сауна кереп кайтты. Көн саен өенә туры кайткач, хатыны белән дә аралары әйбәт иде. Вакытында ашарга пешкән, ятса — мендәр кабартылган. Гаиләдә тынычлык урнашты.

Шулай да Марсның күңеле тыныч түгел иде. Ул берәр венерик авыру эләктердем, ахры, дип шикләнде.

Борчылу башланганның бишенче көнендә Марс түзмәде, спорт залына китте. Чөнки бирегә диспансерда эшләүче бер табиб ир дә йөри иде. Ләкин ул бүген залда юк иде. Кайберәүләр соңга да калып килгәли. Инде тренировка вакыты үтсә дә, көткән кешесе күренмәде. Аның бертуктаусыз кемнедер көткәнен сизеп алган тренер Андриянов:

— Марсик, син бүген шулай кемне көтәсең соң? — дип сорады.

— Миңа Женя кирәк иде. Бер малайның проблемалары бар, ул ярдәм итә алмасмы дигән идем.

— Әгәр шылтыратырга теләсәң, телефоны бар бугай миндә, — дип, тренер кабинетына юнәлде. Марс шундук шылтыратырга булды.

Женя башта кем шылтыратканны аңламый торды.

— Алло, алло, кем бу? Марсик дисеңме? Кайсы Марсик? Ә, Марсик. Син каян шылтыратасың соң? Спорт залыннан? Нәрсәгә шылтыратуың иде? Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел дисеңме? Аңлашылды. Давай, көтәм. Пока.

Икенче көнне иртән Марсны иске танышы Женя:

— Молодец, вакытында килдең, — дип каршылады. — Менә Арнольд Львович үзе дә биредә. Арнольд Львович, менә бу егет кичә мин сөйләгән танылган боксчы инде. Зинһар өчен, карагыз әле шуны, — дигәч, баш табиб урыныннан торып егет янына килде.

— Инде Евгений Александровичның да дусты булгач, карамый ярамас. Әйдә әле, дустым, утырыйк бирегә! — Табиб зур авызын мул итеп ерып җибәрде. Аның күзләреннән бик хәйләкәр, мут һәм акыллы да икәнлеген сизеп була иде.

Табиб егетнең борчыган әйберен тотып-тотып карады. Зурайткыч пыялалар аша тикшерде. Үзе бертуктаусыз:

— Тәк, тәк, тәк, — дигәләде.

— Бүген үк анализларыңны тапшыр әле, иртәгә иртүк яңадан килерсең.

Икенче көнне төштән соң Марсларда телефон шылтырады. Хатыны Ләйсән залда телевизор каршында күңелсезләнеп утырган иренә:

— Марсик, сиңа! — дип кычкырды.

— Кем ул?

— Каян белим инде мин синең бар дусларыңны, кил дә сөйләш.

— Алло, кем бу? Женя?! Евгений Александрович, исәнмесез! Эш бар, дисезме? Яхшы, кичке сигезләрдә кереп чыгармын, — дип, Марс трубканы элде. «Анасын гына сатыйм, димәк, нидер бар. Тик торганнан гына өйгә шылтыратып чакырмас иде. Бетте баш», — дип уйлады ул.

Йөзе кәгазь кебек агарган Марс кабинетка килеп кергәндә, табиблар икесе дә шунда иде. Марс алардан җавап көтеп әле берсенә, әле икенчесенә карады.

— Эшләр шулай, туган, анализлар шәптән түгел. Бәхетең, вакытында килгәнсең. Сифилис синдә. Кайгырма, бер атнадан бернәрсә дә калмаячак, — диде Арнольд Львович. — Бездә кыйммәтле дару бар. Ике-өч прием, эзе дә калмаячак. Аннан

тагын шул. Кем белән йоклаганыңны беләсеңме? Ул кешене дә табып алып кил.

— Без унике кеше идек. Алты малай, алты кыз.

— Унике?! — Табиб күзен акайтты. Женя исә сызгырып куйды. Марсның гына ачудан күзләрен кан басты:

— Ну, мин ул сукаларга күрсәтәм әле! Ник туганнарына үкенәчәкләр! Проституткалар! — диде.

— Ә сез алар белән ничек соң, парга-пармы, әллә алышыныпмы? — дип, бу юлы Женя сорады.

— Бөтен бәла дә шунда шул... — Марс эшнең ничек булганын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Арнольд Львович урыныннан торып арлы-бирле йөреп алды да, Марсик каршына килеп утырып сүз башлады:

— Беләсеңме, энекәш, хәзер үтерәм-суям дип йөреп булмый. Хәзер сезгә тиз генә дәваланырга кирәк. Аннан, кем белә кемнән кемгә эләккәнен. Бәлкем, Мәскәү егетләре күчтәнәчкә алып кайтканнардыр? Кем белә, үзеңнең егетләреңнән йокмаганмы? Әле кайчак бер кеше белән йоклагач та куркып йөрисең. Сез бит бередә 12 кеше. Шуңа күрә, хәзер сезгә шым булырга кирәк. Органнар белсә, шундук ябып куячаклар барыгызны да. Беркем сизмәслек итеп әкрен генә үткәреп җибәрербез. Хәзер һәрберсен күреп кисәтеп чык. Мәскәүләрең дә тизрәк бирегә кайтсын.

— Яхшы. Ә теге чит ил даруына күпме акча кирәк була соң? Без җыеп алып килер идек.

— Турысын әйтим, бик кыйммәт тора ул. Әмма ике-өч көндә сезнең чирдән берни калмаячак. Икенче юлы да бар, дүрт айга хастаханәгә салабыз. Үзегезгә карагыз, йә дүрт ай стационарда, йә бирегә, миңа килеп кенә дәваланырсыз, менә шул, туган.

— Күпме тора соң ул дару?

— Биш мең сум.

— Барыбыз өчен биш меңме? — дип сорады Марс.

— Гаҗәпләндерәсез сез мине, егетләр! Үзегезнең тиз генә беркемгә сиздермичә сәламәтләнәсегез дә килә, үзегез бәясен әйткәч, аптырап каласыз. Әгәр сезне яшереп кенә дәвалаганымны белсәләр, беләсеңме мине күпмегә тыгып куячаклар? Женя, әйт әле күпмегә? — дип, табиб акай күзләрен ярдәмчесенә төбәде.

— Дүрт елдан сигез елга хәтле.

— Менә шулай, энекәш! Иң яхшысы, әйдәгез, мин сезне стационарда дәвалыйм. Ул сезгә ике меңгә очсызгарак төшә-

чәк, минем дә проблемалар булмас. Женя, тутыр кәгазьләрне! — дип, Арнольд Львович өстәле артына барып утырып нидер яза да башлады.

— Туктагыз әле, туктагыз, Арнольд Львович, язмый торыгыз! Мин кайтып малайлар белән сөйләшәм дә, иртәгә иртүк сезгә киләбез, килештекме? — дип, Марс үтенеч белән табибка карады. Женя да өлкән коллегасыннан:

— Арнольд Львович, зинһар, иртәгә хәтле генә түзик инде, — дип үтенде.

— Ярый, Женя, синең хакка гына...

Марсның хәзер аяклары өйгә кайтырга да тартмый иде. «Ничек Ләйсән күзенә күренергә, ничек аңлатырга? Бетте, бөтен дөнья челпәрәмә килде! Карындагы баланы чирдән дәвалап була микән? Ничек Ләйсәнгә аңлатырга, ничек? Бүген үк Кубинецка да шылтыратырга. Ну, сукалар, бүләк ясадылар Яңа елга! Без дәваланып котылырбыз, менә хатын нишләр?» — дип уйлады ул.

## VII

Марс кичекмәстән Мәскәүгә шылтыратырга булды.

— Ярул, елки-палки, монда проблемалар бар бит әле. Теге фахишәләр чирле булып чыктылар. Нәрсә, нәрсә? Сифилис! Әйе! Срочно кайтыгыз, икегез дә. Мин монда таныш табиблар белән сөйләштем. Әле башланган гына икән, әгәр акча таба алсагыз, кыйммәтле дару белән ике-өч көндә бетерәбез диләр. Ләкин бик кыйммәт тора икән бер лечение — 5 мең ди. Беркая да барып булмый. Без черт с ним, минем бит әле хатын белән балага ни булыр? Нәрсә эшләргә дә белгән юк инде. Ну, эләктем мин капкынга. Хәзер Ләйсәнгә ничек әйтергә дә белгән юк. Менә шундый хәлләр. Күпме дисең? 30 мең булса ярыйсы була инде ул. Рәхмәт. Кайчан җибәрәсең? Яхшы. Ярар, пока, — дип трубканы куйды.

Серега Марс белән сөйләшкәннән соң «Тизрәк егетләрне күреп, «общак»та булган акчаларны җибәрергә кирәк. Тәк, утыз меңләп акча гына җыеп булыр әле. Үзебез биредә Игорь Подольский аша дәваланырбыз. Ничек килеп тора бит гел неудача! Хәзер ничек Марсик күзенә кайтып күренергә инде? Хатыны белән балага да эләккән булса, шайтан!» — дип уйлады.

Ул кайтып керүгә, Касапка эшнең нидән торганын аңлатты: «Бүген үк кичке поезд белән ычкынасың. Миңа кайтырга ярамый. Син шунда бер биш көн торып килсәң дә ярый. Кайткан-

кайткан инде, торып кил. Миңа китәргә ярамый, бу грузиннар белән бүлеш бетмичә, берни эшләп булмый, син хәзер Крылатскийга барып Әхмәтне күр, күпме акчасы бар, барсын да җыеп ал. Мин Французны табармын. Кич белән тимер юл вокзалында очрашабыз», — дип ничек керсә, шулай ашыгып чыгып та китте.

Икенче көнне Казан егетләре Касапны каршы алдылар. Ул үзе белән 32 мең җыеп кайткан иде. Алар туп-туры хастаханәгә юл тоттылар.

Табиблар янына Марс үзе генә кереп китте. Башкалар машинада көтә калдылар. Арнольд Львович урынында иде.

— О, әйдә, әйдә, дускай, кер! Хәзер Женя да килеп җитәр. Иптәшләрең кая соң?

— Алар машинада калды. Дүртәү генә без әлегә. Икесе Мәскәүдә, әлегә кайта алмыйлар, эшләре күп.

— Эшләре? Нинди эш?! Вакытында дәваланырга кирәк. Сифилис белән шаяру уен эш түгел, туган! Тирәнгә китсә, мәңге бетми ул аннары. Иртәгә үк кайтсыннар. Арнольд Львович шулай дип әйтте, диегез. Эш узгач соң була ул.

— Яхшы, хәбәр итәрмен. Арнольд Львович, мин дүртебезгә акча алып килдем. Безгә нишләргә?

— Тәк. Акчаңны калдыр миңа. Кич белән сәгать сигезләргә икешәр-икешәр керерсез. Аракы эчәргә ярамый дәвалау чорында, шуны онытмагыз. Теге кызларыгыз да килеп китте бүген. Елашалар. Агарынып калганнар куркудан. Икесенең бишәр мең акчасы бар икән, калган дүртесе җитмәгән суммаларын эзләргә киттеләр. Сез, энекәш, тавыш чыгарып йөрмәгез инде алар белән.

Болай да кыйнап киткәнсез бит инде сез аларны. Милициягә хәбәр итсәләр, тагын да начаррак була, аңладыңмы?

— Әйе, ярый, без кичкә килербез. Менә монда төп-төгәл 20 мең. Кичкә кадәр, — дип, Марс чыгып китте.

Марсның хәле башкаларныкыннан бик күпкә начаррак иде. Аның тойгыларын сизгән иптәшләре ул машинага кергәч тә бер сүз дәшмәделәр. Марс үзе генә:

— Бүген кичке сигездә уколлар ала башлыйбыз, — диде.

Кич белән башта Касап белән Марс үзе керде. Арнольд Львович башта аларга кызгылт сары төстәге капсулалар каптырды да:

— Йотыгыз, егетләр! — дип, бер стакан су сузды. Бу эш беткәч, Марска агач караватка ятарга кушты. Табиб аның йомшак җиренә укол кадады. Озакламый аның белән эш беткәч,

бушап калган урынга Касап менеп ятты. Эш беткәч, баш табиб:

— Егетләр, һәр көнне шушы вакытта. Биш көн укол аласыз. Алтынчы көнне страховочныйны өстибез дә, вәссәлам. Шуннан соң кесәгездә презерватив йөртә башлагыз, кабат минем янга килергә теләмәсәгез, әлбәттә. Сөйләштекме? Ә хәзер теге иптәшләрегез рәхим итсеннәр. Сау булыгыз, — диде.

Марс табибка соңгы көнне генә хатыны белән йоклаганын, аның йөкле булуын әйтте. Башта Арнольд Львович аптырап калды. Соңыннан күзләрен акайтып:

— Да ты что, старик! Син нәрсә эшлисең, нәрсә эшләгәнеңне аңлыйсыңмы син? Ник башта ук әйтмәдең? Иң беренче бит син аны дәваларга тиеш идең. Разве сифилислы килеш бала табарга ярый аңа! Гомерең буе гарип бала карамакчы буласыңмы әллә? Ничә айлык йөге бар соң? Вәт җүләр баш син! — дип дулады баш табиб.

— Алты ай була.

— Алты ай! Елки-палки. Беренче генә баламы әле?

— Әйе, — дип, Марс башын гына селкеп куйды. Баш табиб та сүзсез калды. Шулай күпмедер уйланып утыргач, ниһаять:

— Бар, кайт та алып кил. Срочно аборт ясарга туры киләинде аңарга. Бернишләп тә булмый. Бар, бар. Баласын да үземә төшертергә кала. Каян башка бәла булдыгыз сез! Барыгыз! — дип кычкырды.

— Мин әйтә алмыйм аңа, Арнольд Львович, йөрәгем җитми, аңлыйсыңмы? Булдыра алмыйм, — дигәч, егетнең күзләреннән яшь бөртекләре бәреп чыкты.

— Чир эләктерә белгәнсең бит, дәваларга йөрәгең җитмиме, куян йөрәк? Белмим, рингта ничек сугышасың икән син?! Бир телефоныңны үземә! — дип кычкырды баш табиб.

Марс, бөкрәеп кенә өстәл янына килеп, телефон номерын язды да, башын иеп бүлмәдән чыгып китте. Ул бүген өенә кайтмаска булды. Хатыны Ләйсәннең күзенә күренергә йөрәге җитмәде.

Өч көн үткәч Марс бар кыюлыгын җыеп өенә кайтырга булды. Ишек кыңгыравына күпме генә басса да, ачучы булмады. Үзе ачып керде. Өйдә беркем дә юк иде. Йокы бүлмәсенә кереп, караватка утырды. Туачак балага алынган киемнәргә, тасмага карап үксеп елап җибәрде. Шулай күпмедер гасабилангач, торып, аш бүлмәсенә чыкты. Суыткычтан башланмаган аракы алып ачты да, тутырып салып, бер стаканны эчеп тә бетерде. Шулчак телефон шылтырады.

— Алло, бу кем әле? Марсик, синме? Кая йөрисең син?! Хатының авыр хәлдә республика хастаханәсендә ята, син качып йөрисеңме? Ярый әле, бәхетеңә мин очрадым, мин булмасам, хатыныңнан да колак кага идең, мәгънәсез! Биш мең ал да минем янга кил. Килешли хатыныңа кагор, виноград согы ал. Бик күп кан югалту сәбәпле, аңа глюкоза кирәк. Хәзер үк килеп җит. Хастаханәгә икәү барырбыз. Мин белгән врач карый аны. Хатының терелеп чыккач, бер коньяк та бер бүрекме шунда бүләк итәрсең. Тиз бул, вакытым санаулы минем, — дип, Арнольд Львович трубканы куйды.

Марсның кара «девятка»сы хастаханәнең тимердән бизәп эшләнгән рәшәткәсе кырыена килеп туктады. Кулына пакет тоткан Арнольд Львович төште. Машина ишеген бикләп, егет тә хастаханә бакчасыннан барган баш табиб артыннан иярде.

Шапироның биредә дә танышлары күп иде. Аскы этажда да әллә ничә ак халат кигән кеше очрап, кул биреп исәнләштеләр. Ул берсеннән:

— Әнвәр Бакирович үзендәме? — дип сорады. Уңай җавап ишеткәч, ишеккә юнәлде. Алар өченче катка менеп, коридор буйлап атладылар. Сирәк-мирәк шәфкать туташлары, авыру хатын-кызлар очрады. Борынны ярып дару исе аңкый иде.

Дежурный янына килеп, Әнвәр Бакировичны сорадылар.

Кыз бүлек мөдиренең исемен ишеткәч:

— Сез кемнәр буласыз аңа? — дип сорады.

— Без аның коллегалары, гүзәл туташ, — диде Арнольд Львович. Туташ барып ишек шакыды да: «Әнвәр Бакирович, сезгә килделәр», — дип вак-вак атлап эшлекле кыяфәт белән үз урынына килеп утырды. Аның артыннан таза гәүдәле, озын буйлы ир кеше күренде.

— О-о-о, Арнольд Львович, сезне күрүемә бик шат, рәхим итегез, әйдәгез, кабинетка керик! — дип, кул биреп исәнләште.

— Менә шушы егетнең хатыны инде ул, Әнвәр Бакирович.

— Ну син, егет! Ярыймы инде хатыныңны шул хәлгә төшерергә? Көчкә исән калды бит. Дөресен генә әйткәндә, әле дә терелүенә шикләнәм. Алты айлык баланы төшерттерәләрме инде? Үз балаң бит, — дип, егетне сүкте.

— Әнвәр Бакирович, аның сәбәпләре бар инде, егетне алай бик бетереп ташлама, болай да аның хәле яхшыдан түгел, — дип, Арнольд Львович Марсны яклады.

— Мин сезнең серләрне белмим, ләкин алты айлык баланы

төшертү... Хатыныгыз яңадан бала таба аламы әле, юкмы. Әйдә, хатыныңны күреп кит. Әле менә беренче генә тәүлек рәтләп йоклый башлаганына да.

Алар Ләйсән яткан палатага керделәр. Марс система куелган хатынын күргәч, кулъяулык чыгарып, күз яшьләрен сөртеп алды. Бер биш-алты минут басып торгач, ишеккә юнәлде. Үзе эчтән: «Кичер мине, зинһар, кичер», — дип кабатлады.

Әнвәр Бакирович аларны: «Тагын бер атнадан аякка бастырам хатыныңны, Алла боерса», — дип озатып калды.

## VIII

Юлда Арнольд Львович ничек аның хатынына шылтыратканын, Ләйсәннең үксеп-үксеп елаганын, соңрак тынычлангач, анализлар тапшырырга риза булганын сөйләде. Әле операциягә керер алдыннан да Марсны сораган икән. «Юк» дигән җавапны ишеткәч, күзеннән яшьләре тамган килеш, башын иеп операция бүлмәсенә кереп киткән. Бу хәбәр Марсның йөрәген телгәләде. Алар бит яратышып өйләнешкәннәр иде. Очрашулары да очраклы гына булды аларның. Алла Пугачева концертында. УНИКС залына егет үзе белән кереп баручы кызга: «Бары тик сездән соң гына», — дип, шаяртып юл биргән иде. Кыз исә: «Рәхмәт», — диде дә кереп китте. Нишләптер әлеге кызның аяк атлавына кадәр аңа рәхәтлек бирә иде. Марс иптәш егетләренә ияреп, башка кызларга сүз каткаласа да, бары тик баягы кызны гына эзләде. Һәм ул аны тапты да. Чөнки зәңгәр күлмәген хәтерләп калган иде. Арада зәңгәр күлмәклеләр күп булса да, ул кызныкы бигрәк тә ачык зәңгәр иде. Концерт барышында да ул гел аны гына күзәтте. Аңа кызның бирелеп концерт каравы да, шатланып кул чабулары да ошады. Янындагы иптәш кызы белән ни турындадыр сөйләшеп алганда, егеткә ярты бите дә күренеп киткәләде.

Марс тәнәфескә чыккач, бер бәйләм розалар алды да, теге кызлар чыкмады, ахры, дип уйлап кире кереп китте. Дөрестән дә, ахирәтләр нәрсә турындадыр бик тәмләп сөйләшеп утыралар иде. Марс, кызлар каршына килеп:

— Матурым, менә бу чәчәкләрне икебез исеменнән Алла Пугачевага тапшыра алмассыз микән? — диде.

— Аңа дип алгач, үзегез тапшырыгыз инде, — дип җавап бирде туташ. Иптәш кызы белән бер-берсенә карашып көлешеп тә алдылар. Аның чиядәй иреннәре ачылып, тигез матур тешләре чагылып китте.

— Алуым сезнең өчен иде дә, ләкин чит кешедән чәчәк алмаячагыгызны сизеп, җырчыга тапшырырга риза булырсыз дип уйлаган идем.

Кызлар тагын көлеп җибәрделәр.

Соңыннан Марс аларны машинасы белән Татар бистәсенә озатып куйды. Саубуллашканда туташларны атна ахырында булачак бокс ярышына чакырды. Кызлар килергә тырышырбыз, дип вәгъдә бирделәр.

## IX

Ләйсән ярышка барырга микән, бармаска микән дип икеләнеп йөрде. Егетнең үз-үзен тәртипле тотуы, кыланмавы ышаныч уяткан иде. Өстәвенә, төскә-биткә дә күркәм күренә. Дус кызы Сөмбелә белән киңәшкәч, барырга булдылар. Ләйсәнгә килгәндә, ул бокс ише уеннарны өнәп бетерми, күбрәк аңа чаңгы, тимераякта шуу кебек уеннар ошый иде. Ләкин, нишлисең, барырга туры килә.

Алар килеп кергәндә зал шыгрым тулы булып, ярышны тантаналы ачу тәмамланып килә иде. Кызлар кешеләр арасыннан эчкәрәк үтәргә тырыштылар. Кая соң әле аларны чакырган егет? Трусик-майкадан гына калган ярышчылар арасыннан үзләренә кирәкле кешене эзләп табуы кыен иде. Өстәвенә, моңа кадәр бер генә мәртәбә күреш тә... Әнә икән бит ул, иң беренче басып тора. Төз гәүдә, кояшта янган бронза тән. Чынлап та ару егет икән бит. Сөмбеләнең күңелендә дә шундый ук уйлар иде, күрәсең, ул:

— Кара, нинди чибәр икән, — дип куйды. Ләйсән бер сүз дәшмәде, елмаеп кына алды.

Ниһаять, уен башланды. Башта иң җиңел авырлыктагылар көч сынашты. Менә Марс Хисмәтуллин белән Игорь Субботин рингка чакырыла, дигән хәбәр яңгырады. Кызның йөрәге сикерә башлады. «Җиңә алса гына ярый инде», — дип уйлады ул. Менә рингка Марс чыкты. Комментатор:

— Кызыл почмакта Татарстанның — алты, Рәсәйнең ике мәртәбә, Казанның биш мәртәбә чемпионы Марс Хисмәтуллин. Зәңгәр почмакта Чаллы, Туймазы, Татарстан чемпионы Игорь Субботин, — дигәч, тамашачылар гөр килеп кул чаптылар.

Ниһаять, гонг яңгырады. Егетләр көч сынаша башладылар. Ләйсән, егет өчен борчылып, Сөмбеләгә елышты. Марска эләккән саен, иптәшенең беләген кысып-кысып куя иде ул. Тирә-

юньдәге ир-егетләр сугышка бәя биреп бардылар. Берзаман Субботин атакага ташланып Марска бер-бер артлы суга башлады. Егет ике бияләе белән битен каплады. Ләйсән куркып, күзләрен йомды. Яңадан караганда киресенчә, Марс дөмбәсли иде инде. Озакламый гонг тавышы ишетелде. Беренче раунд бетте. Марс кызыл почмакка барып утыруга, аның битенә су сибеп, сөлге белән җилләтә дә башладылар. Битләрен сөрттеләр. Ул авызына су кабып чайкады да, чиләккә төкергәч, торып сикергәли башлады. Тренеры аңа нидер аңлатуын дәвам итте. Яңадан уен башланды. Ике егет тә арыслан кебек гайрәтле, җитез иде. «Тукта, нишләп каршы сугышучы егет егылды?» — дип уйлап куйды Ләйсән. Егет торып маташты, ләкин тагын авып китте. Судья аны тотып алып, башы белән бәрелмәсен, диптер инде, әкрен генә идәнгә яткырды да саный башлады. Кыз тагын баягы егетләр сүзенә колак салды. Аның берсе: «Әйттем бит, Марсик эшне озакка сузмаячак», — диде. Шулай итеп сугышны туктаттылар. Судья Марсның кулын өскә күтәргәч кенә, кызлар җиңел сулап куйды. Таныш егетләре җиңгәнгә икесе дә бик шат иде алар.

Кызлар икенче көнне дә, өченче көнне дә бокс ярышларын карарга килделәр. Ләйсән инде Марска баш-аягы белән гашыйк булып бара иде. Соңгы көнне чемпионнарны бүләкләделәр. Муенына медаль таккан, кулына диплом тоткан Марс үзенә биргән чәчәкләрне кызларга сузып:

— Рәхмәт сезгә, кызлар, сез килеп минем өчен кайгырып тормасагыз, җиңү юк иде миңа, — диде.

Ул арада берничә яшүсмер чорнап алып, Марстан автограф сорый башладылар. Алардан соң иптәшләре җыелып, берсе Марсның муенындагы медален салдырып үзенә тагып куйды. Икенчесе дипломын укырга тотынды. Өченчесе:

— Марсик, без сиңа шампан шәрабы алдык, әйдә, киенеп чык та, синең җиңүне юарбыз, — диде. Шул арада егетләр кызлар белән танышырга да өлгергәннәр иде инде.

Шул көннән башлап Марс белән Ләйсән очраша башладылар. Егет йөргән саен кызның тәртиплелегенә инана барды. Моңа хәтле ул кызлардан ләззәт алырга гына күнексә дә Ләйсәнгә карата мөнәсәбәте башка иде. Чибәр һәм акыллы бу кызны Марс кулдан ычкындырмаска тырышты. Алар икесе дә бәхетлеләр иде.

Шушы үткәннәрне уйлап хастаханә караватында яткан хәлсез Ләйсәннең күзләреннән рәнҗеш яшьләре акты. «Нинди бәхетле көннәр булган икән! Ни өчен, Ходаем, шулай бәхетсез

иттең мине?! Кем каргады икән мине? Беркемгә дә начарлыгым тимәде бит», — дип, тавышсыз гына елады да елады Ләйсән. Фаҗига булырга ике көн кала карынындагы баласының ярсып-ярсып тибүе исенә төште. «Йа Ходаем, каян сизгән икән ул? Икенче көнне дә бала нык тыпырчынды. Йа Ходаем, нишләп минем нарасыемны хараплар иттердең? Аның ни гаебе бар иде?!» — дип өзгәләнде ул.

Ләйсәнне хастаханәдән тагын бер атнадан соң гына чыгардылар. Марс аңа дип чәчәк бәйләме дә алган иде. Хатынының каршысына килеп: «Зинһар, кичер мине, кичер», — дисә дә, Ләйсән бер сүз дәшмәде. Дәшмәде дә, чәчәкләрне дә алмады...

## X

Кубинец көтмәгәндә генә кайтып төште. Кыяфәтенә караганда бик сәер күренә. Нидер әйтеп бетермәгәне сизелә. Тик нәрсә икән? Әле беркем дә аның уйларын аңлый алмый иде. Бар да Марсны көткән арада, Мәскәүдән кайтучының яңа машинасы тирәсендә әйләнделәр. Яңа «БМВ»ның эчләренә кереп утырып-утырып та карадылар, ялтырап торган буявын да сыйпаштыргаладылар.

Ул арада Марсның кара «девятка»сы мәйданчыкка килеп керде. Ул машинасын кырыйга куеп, егетләр белән күңелсез генә күрешеп чыкты. Сүз озакка сузылмады. Кубинец үзе белән Марс та Касап кына китәсен аңлатты да, иртәгә кич белән яңадан бирегә җыелачакларын әйтеп, машинасына юнәлде. Бар да аптырашып торганда, Дамир түзмәде:

— Серега, нәрсә бернәрсә әйтмисез инде, нинди сер ул безгә әйтмәслек? Әллә ышанычны югалттыкмы барыбыз да? — дип сорады.

— Егетләр, бернинди сер юк. Сезгә әйткәнче ачыклыйсы мәсьәләләр бар. Соңыннан... — дигәч, Серега машинасына кереп утырды.

...Евгений Александрович медицина институтын уртача билгеләргә тәмамлады. Аның ай буе эшләп алган хезмәт хакы тамагын туйдырырга да көчкә җитә иде. Киенү турында уйлама да. Ярый әле әнисе бар. Ул кайсы вакытта чалбарын да, костюмын, күлмәген дә алып биргәли. Ләкин пенсиядәге карчыкның акчасы гына күпмегә җитсен инде. Егет әтисеннән калган иске «Жигули» белән буш вакытында пассажирлар ташып акча эшләргә чыга иде. Менә шундый кичләрнең берсендә ул Арнольд Львович Шапиро белән танышты.

Озакламый егеткә, чыннан да, бу кеше кирәк булып чыкты. Бер йортта торучы иптәш егете венерик авыру эләктергән иде. Алар Арнольд Львовичка барып карарга булдылар. Баш табиб яхшылыкны онытмаган икән, бәлагә таручыны берсүзсез дәваларга булды. Теге егет сәүдә системасында эшли иде. Терелгәч, үзләрен өстәл тутырып сыйлап кына калмады, баш табибка сумка тутырып кыйммәтле коньяк та, затлы колбаса, конфетлар да бүләк итеп китте. Бар як та канәгать иде. Озакламый Арнольд Львовичның тагын кирәге чыкты. Бер мафиози бәлагә тарыган иде. Өстәвенә әле үзе бөтен Рәсәй буенча эзләнелә торган җинаятьче дә икән. Егетне баш табиб яшереп кенә дәвалады. Теге өлгер егет тә буш итмәде. Баш табибка карандаш калынлыгы алтын чылбыр бирсә, Женяга булышканы өчен күн куртка бүләк итеп, каядыр китеп югалды. Соңыннан Арнольд Львович Женяны үзенә ярдәмче итеп чакырды. Алар икәүләшеп уңышлы гына эшли башладылар. Кем килсә дә ярдәм кулын сузарга, дәваларга тырыштылар... Евгений Александрович күзгә күренеп үзгәрде. Иске «Жигули»ен сатып, яңа «восьмерка» алды. Өс-башын карады, гаражлы да булды. Электән калын гәүдәсе күзгә күренеп тагын да юанайды. Аның кечкенәдән килгән Винни Пух дигән кушаматы хәзер үзенә бөтенләй дә килешә иде.

Евгений Александровичның күптәнге хыялы да тормышка ашты. Ул гомере буе иске җимерек өйдә әти-әнисе белән яшәде. Бергә укыган иптәшләренең бөтен уңайлыклары булган фатирларына сокланып: «Их, кайчан да булса миңа да шундый өйләрдә яшәргә туры килер микән?» — дип хыяллана иде. Бу эштә дә аңа өлкән коллегасы ярдәм итте. Тагын ике еллап вакыт үткәндерме-юкмы, ул коттедж салып керде. Иртән машинасы белән эшкә китә, кайтышлый спорт залына барып, боксер егетләр белән аралаша. Алар аша «крутойлар» белән күпме таныште. Кайчакларда абруйлырак боксчыларны ял көненә үзенә мунчага да чакыра иде.

Менә, ниһаять, аңа да күк капусы ачылды. Хәзер ул ничек яшәргә икәнен белә. Суыткыч тулы тәмле ризык. Кыйммәтле аракы. Мунчасы ягылган. Төсле музыка. Теләгән хатын-кызын алып кайта. Ашата-эчертә. Һәм алар төне буена анықы.

...Икенче көнне Марс егетләре саунага җыелдылар. Озакламый Кубинец килеп туктады.

— Менә нәрсә, егетләр. Кичә Марсик, Касап һәм мин анализлар тапшырган идек. Өчебезнең беребездә дә сифилис эзе табылмады, — диде Яруллин.

— Соң, без кыйммәтле чит ил дарулары белән дәваландык бит. Каян булсын инде ул хәзер? — дип, Дамир сүзгә кысылды. Кубинец исә ирония белән авызын кыегайтып елмаеп алды да:

— Ә син беләсеңме соң сифилистан дәваланганнан соң да канда эзе калганны? Белмисеңме? Ә мин беләм. Сезнең берегез дә бу чир белән авырмаган!

— Нәрсә, триппер гына булганмы? — дип сорады Марс. Серега кулы белән ияген сыпырып алды да, канәгатьсезлек белән:

— Абсолютно бернинди чир дә булмаган сездә дә, бездә дә һәм теге кызларда да.

— Не может быть... — диде Марс ышанып бетмичә. Яруллин машинасына таба китте. Кулына бер кәгазь тотып, яңадан егетләр янына килде.

— Менә монда теге алты кызның, аннан Марсик, Касапның анализлары. Алар чип-чиста. Бернинди чирне дә күрсәтмиләр. Берәрегез медицина телен аңлыймы? Аңламыйсызмы? Аңламасагыз, аңлатам. Менә нәрсә диелгән: «Канда һәм сидектә йогышлы бактерияләр күзәтелми» диелгән.

Марсның башы әйләнеп китте. Ул аяктан егылмас өчен баскычка утырды. Димәк, аны алдаганнар! Мөмкин түгел! Юк, юк, мөмкин түгел! Кемне-кемне, аны алай алдарга тиеш түгелләр. Өстәвенә, бернәрсә белән чирләмәгән хатынның алты айлык баласын ничек инде төшертергә була?! Ул бит хәзер гомерлек чирләшкә булып калды. Йа Алла! Башка бала таба аламы әле ул, юкмы. Марс көчкә урыныннан торды. Хәлсез тавыш белән:

— Дөресме бу хәл, Ярул? Алдашмыйсыңмы, әйт дөресен? Гаепне үзеңнән төшерер өчен генә эшләмисеңме син моны? — дип сорады.

— Марсик, мин сине кайчан да булса алдаганым бар идеме? Телисеңме, әйдә, бөтенләй икенче җиргә, юк, башка шәһәргә барып яңадан тикшереләбез. Телисезме?

— Йа Алла! Миңа мондый кабахәтлекне беркемнең дә эшләгәне юк иде. Хәтта дошманнарымның да! Минем хатынымны, тумаган баламны нишләттеләр. Шушы эшләрдән соң алар исән калырга тиешләрме? Юк! — дип, ул урыныннан торды. — Дамир, син теге пушканы кая куйдың? Хәзер үк алып кил, хәзер үк! Бу эшкә беркем дә кысылмый. Сез мине белмисез, мин сезне. Барысын да үзем эшлим. Барысы да үземнең аркада! Нindидер падлоларга ышандым бит! Җүләр баш. Дамир, мин

синә әйтәм, мә минем машина ачкычын, алып кил пистолетны! Минем кеше үтергәнем юк иде, бүген икене үтерәм, — дип, егет куркыныч тавыш белән улап җибәрде.

— Марсик, тынычлан әле. Ашыкма, — диде Ярул сабыр тавыш белән. — Хәзер акыл белән эш итәргә кирәк. Эш эшләнгән инде, кире кайтарып булмаячак. Калганын миңа калдыр!

— Сиңа?! Син кем соң? Синең хатының белән балаңа зыян килдеме? Минем эшкә кысылма. Барысын да мин үзем эшләргә тиеш.

— Марсик, син хәзер ярсыгансың. Тынычлан. Минем үземнең план бар. Әгәр син болай эмоциягә бирелсәң, бөтен эшне бозып куясың, аңла, тынычлан да мине тыңла!

— Син биредә беркем түгел, Ярул, аңладыңмы? Мине өйрәтергә кирәкми. Әлегә мин биредә хуҗа. Нәрсә эшләргә икәнен мин үзем дә яхшы беләм, — дип, Марс машинасына таба атлады. Ләкин Серега аның юлына аркылы төште.

— Югал, югыйсә үзең беләсең, югал, Ярул, каршымнан, — дип, егет йодрыкларын йомарлап дустына ташланды. Тегесе каршы сугарга уйламый да иде. Кулларын куеп сакланды гына. Читтә карап торган егетләрнең икесе — Дамир белән Касап, арттан килеп, Марсны тотып алдылар. Теге исә алардан котылырга теләп боргаланды, аяклары белән типкәләде. Шулай да егетләр аны ычкындырмадылар. Җиргә егып салып, тынычланганчы тотып тордылар. Бу вакытта Яруллин, кесәсеннән кулъяулыгы чыгарып, канаган иренен сөртә иде.

## XI

Кунак бүлмәсендә өстәл әзерләнгән. Уртасында горур кыяфәттә шампан шешәсе басып тора. Янында ике шешә аракы. Ике бокал, ике рюмка, салат тәлинкәләре куелган. Женя ваннадан кырынып чыкты. Хушбуй сиптереп битен чәбәкләп алды. Үзе: «Тәк-тәк, һем, тәк, тагын нәрсә эшлисе бар әле? Тәк. Яле, бүлмәгә дә хуш ис кертик әле, тәк. Булды бу. Вакыт күпме икән әле? Әһе. Тагын биш минуттан духовкадан тавыкны да алырга кирәк. Тукта, чәчәкләрне журнал өстәленә алып чыгып куйыйм әле», — дип ванна бүлмәсенә кереп, чәчәк күтәреп яңадан килеп чыкты. Аны урнаштыргач, аш пешерү бүлмәсенә юнәлде. Евгений Александровичның хәрәкәтләренә караганда, аның кемнедер каршы алырга җыенып йөргәне һәм киләчәк кешесенең хатын-кыз булырына шик калмаган иде. Тәрәзәдән

аны күзәтеп торучы егетләрнең берсе нәфрәт белән сүгенеп куйды. Ә эчтә теге йомран һаман өстәл янында бөтерелә иде. Ул, көзге каршына килеп, үзенең көзгедәге сурәте белән бокс уйнап алды. Мускулларын катырып атлетлар булып та кыланды. Аны күзәтеп торган егетләрнең берсе: «Урод», — дип куйды. Куллары белән төрле хәрәкәтләр ясап, аяклары белән тибенгәләде. Соңгы тибү кресло чатына эләкте, ахры, теге сүгенеп куйды да аягын уа башлады. Бу кәмиттән егетләр чак кына көлеп җибәрмәделәр. Дамир көчкә тыелып:

— Аңа бу гәүдәсе белән циркта клоун булырга кирәк, ә ул табиб булып йөри, — дип, сүзен сүгенү белән бетерде. Ярул пышылдап:

— Егетләр, дүртебезнең беребез тышта кала. Хәзер аңа хатын-кыз килергә тиеш. Каршы алып, гафу үтенеп, срочно эшенә чакырып алдылар, иртәгә үзем шылтыратам, дип әйтте, дип кире озатырга. Дамир, син сүзгә оста, син каласың. Ә син, Марсик, хәзер ишекне ачтырасың. Без качып торабыз. Үтеп барышлый гына кергән идем, хәл белергә диярсең. Ишекне ачуга барыбыз да бәреп керәбез. Калганын миңа калдырыгыз, сөйләштекме? Марсик, зинһар, кызып китмә. Югыйсә эшне бозачаксың. Сөйләштекме? — диде.

— Сөйләштек, — дип куйды Марс.

Бераздан ул Женя яшәгән фатирның кыңгырау төймәсенә баскач, эчтән:

— Кем ул анда? — дигән тавыш ишетелде.

— Бу мин әле, Евгений Александрович, Марсик. Үтеп барышлый гына. Иптәш малайга килгән идем дә, өйдә булып чыкмады. Тукта, мәйтәм, уты бар, өйдә, ахры, дип сиңа сугылдым.

Озакламый ишек ачылып, Винни Пух үзе дә күренде.

— О-о-о, Марсик дус! Әйдә, әйдә, кереп чык инде килгәч. Дөресен генә әйткәндә, бүген мин бер чибәр туташны көтә идем, әле ярты сәгатьләп вакытым бар, — дип, егетнең бик озакка туктала алмаячагына басым ясады. Шулвакыт качып торган ике егет өйгә бәреп керделәр. Хуҗа әле эшнең нидә икәнен дә аңлап бетерә алмады.

— Сез нәрсә, егетләр? Шаярасыз мәллә? — дип аптырап сорады. Ярул аңа:

— Кер һәм үзеңне тыныч тот. Син әле үзеңнең шакшы гомереңне саклап кала аласың, урод. Аның өчен сиңа минем дусларны ничек дәвалаганыгызны сөйләргә туры киләчәк. Нинди дару биреп, нинди уколлар кадаганыгызны сөйлә. Дөресен

сөйлисең икән, исән каласың. Сайла. Шаярып торырга безнең вакыт юк.

— Сез нәрсә, егетләр?! Без бит аларны импорт дарулар белән дәваладык. Шуңа күрә кыйммәтрәк булды инде. Ну, әгәр сез бик күп дип уйлыйсыз икән, яртысын кире кайтарып бирербез. Без бит үзебезне куркыныч астына куеп дәваладык. Сизсәләр, беләсезме безне нишләтәләр?

— Сез аларны нидән дәваладыгыз инде? — дип, Ярул өстәл янына килде дә бер тавык ботын алып ашый да башлады. Үз өстәленә кемнеңдер хуҗа булуын ошатмаган Винни Пух:

— Сифилистан, әлбәттә. Сезгә яхшылык эшлисең, ә сез өйгә килеп мыскыл итәсез. Марсик, бу нәрсә бу?! Син бит мине күптән беләсең.

— Әйе, беләм мин сине, уродны. Ләкин син әле мине белмисең икән, — диде Марс, ярсуын көчкә тыеп.

— Туктагыз әле, егетләр, бу нәрсә соң?! — диде хуҗа.

— Син шуны әйт әле, анализлар бармы сифилисны күрсәткән? Әйт әле дөресен, — дип, йомшак кына сорады Кубинец.

— Бар, бар. Иртәгә килегез, әзерләп куям.

— Мин сиңа нәрсә дидем, мин сиңа ялганлама дидем, падло.

— Мин ялганламыйм, ант итәм менә, — дип, Женя чукынып алды.

— Ялганламыйсың, да? — дип, Яруллин тегенең борынын кысып торткан килеш, кесәсеннән кәгазьләр чыгарып икенче кулы белән битенә тәрәде. — Менә кара, дебил, менә биредә нәрсә дип язылганны аңлыйсыңмы? Нәрсә диелгән? Бусы сезнең хастаханә анализлары. Болары — чит җирнеке. Бусы — Мәскәү каласыныкы. Борыны авыртудан Женяның ике күзеннән яшь ага башлады. Аның баш миенә барысы да барып җитте. «Беттем. Болар бөтен эшне белгәннәр, исән калдырмаячаклары көн кебек ачык. Нәрсә эшләргә? Чыгып качып булмаячак. Сугышып карасаң, бер сугуда аударачаклар. Беттем», — дип уйлады ул. Шулчак урамда машина туктаган тавыш ишетелде. Тукта, теге кыз килде бугай. Ничек булса да ычкынып, тәрәзәне ватарга кирәк. Бәлкем, милиция чакыртырлар дип, Женя тәрәзәгә ташланмакчы иде, егетләр аны бик тиз туктатты... Битенә шампан шәрабы сибүдән генә аңына килде ул. Үзенең кая ятканына төшенеп, тирә-юненә күз салды. Өстәл артында үч алырга килгән егетләр сыйланып утыра иде. Ярул, аның аңына килгәнен күреп:

— Йә, клоун, дөресен сөйлисеңме инде? Тагын биш минут сиңа, — дип, тимерчыбык белән Женяның муенын урап алды. Аның куркудан күзләре акаеп чыкты, үзе бертуктаусыз:

— Зинһар, үтермәгез, сөйлим. Барысын да сөйлим. Минем гаебем юк. Шул кабахәт аркасында гына. Башта мин каршы идем. Ләкин ул баш врач булгач, буйсынырга туры килде. Әйе, шулай туры килде. Марсик, зинһар, кичер мине!

— Син, падло, мине алдый аласың. Нишләп хатын белән баланы шулай эшләттегез, ни өчен? — дип, Марс йодрыгы белән аның башын төйде. Ярул аны тыеп:

— Булды, булды, Марсик, тынычлан! — дип, егетнең ярсуын басты.

— Чөнки Арнольд курыкты. Әгәр шулай эшләмәгән булса, иртәме-соңмы син бернәрсә белән дә чирләмәгәнеңне сизә идең. Шуңа бу кара эшкә барырга туры килде.

— Элек тә бу эш белән шөгыльләндегезме, әйт дөресен? — дип, Яруллин тимерчыбыкны кысып алды. Теге йөткерә-йөткерә:

— Әйе, булды. Булгалады. Мин хәзер күпме икәнен хәтерләмим. Арнольд Львович миңа хәтле үк шөгыльләнгән бу эш белән. Үзегез аңлагыз табибларның хәлен. Ул акча ашарга да җитми. Ә сез Шапироның йорт-җирен карагыз. Джипта гына йөри. Врач акчасына аның уенчыгын да алып булмый, — дип сүзен бетерде. Яруллин, кесәсеннән диктофон чыгарып, кирегә әйләндереп алды да икенче төймәсенә басты һәм:

— Чиста язылган, — дип куйды.

## XII

Арнольд Львович Шапироның Израильгә китәргә дип җыйган байлыгы юкка чыкты. Аны бар әйберен сатарга Казан бандитлары мәҗбүр итте. Коттедж, машина, өйдә булган бар байлыкны сатканнан килгән акча туп-туры егетләр кулына күчте. Бар әйбер ашыгып, ярты-йорты бәягә сатылса да, шактый акча җыелды.

Шапирога, әйберләрен сатып акчасын биргәч, Татарстаннан чыгып китәргә егерме дүрт кенә сәгать бирделәр. Екатеринбургка оча торган самолетка аны Ярул белән Марс озатты. Егетләр, аэропортның икенче катына менеп, явыз табибның самолетка утырганына кадәр күзәтеп тордылар. Ул трапның өске баскычына күтәрелгәч, борылып, аэропорт бинасына карады. Аның карашыннан чәчелгән зәһәрлек тәрәзәгә килеп бәрелгәч, тәрәзәләр дә зеңгелдәп куйган кебек булдылар.

Самолет өскә күтәрелеп, курс алгач, Шапиро пиджак кесәсеннән алтын балдак, алтын йөзек чыгарып бармакларына киде. Икенче кесәсеннән йомарлап төрелгән долларлар чыгарып, документлар тутырылган сумкасына салды. Үзе нигәдер шатланып хихылдап көлде. Ул көлгәндә авызында бер теше калмаганлыгы күренә иде. Сынган борыны да әрнеп куйды. Үзе эчтән: «Иң мөһиме, баш исән булсын, баш исән булса, калганы табыла аның», — дип уйлады.

Арнольдтан алынган акчаларның барысын да Ләйсәнне дәвалауга бирделәр. Елга бер-ике мәртәбә булса да Кубинец үзе дә кайткалап китә иде. Алар элеккечә саунада көрәшәләр, футбол уйныйлар, ызгышалар. Әлбәттә, кызларны да яраталар. Марс та хәзер элекке фаҗигаләрне онытып бара иде бугай. Өстәвенә, табиблар да: «Хатының бала таба алачак», — дип өметләндерделәр.

Менә тагын бер ел үтеп китте. Егетләр һәр шимбәдәгечә саунага килделәр. Инде Яңа ел саунасына да ерак калмады. Ике атна элек чит шәһәргә эш белән киткән Дамир кайтып төште. Аның егетләргә әйтер яңалыгы бар иде.

— Үз күзләремә ышанмадым. Беләсезме, Сургутта Шапироны очраттым. Тешләр куйдырган, яңа «Мерс»та утыра. Мине күргәч, күзләре чак кына орбитасыннан чыкмады. Машинасын кабызып, бар көченә газга басып ычкынды бу. Эзләп табып, акча сорарга килгәннәрдер дип уйлагандыр, козел, — диде ул. Марс аңа:

— Беләсеңме, Дамир, мине тәбрик итә аласың. Ләйсән тиздән бәби табачак бит, — дигәч, Дамир сикереп торып:

— Ну, котлыйм, туган, чын күңелдән котлыйм, — дип, аны кочаклап алды.

## ЭЧТӘЛЕК

Уяу бул, адәм баласы! *В.Нуриев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

### Роман

Кыйммәтле килешү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

### Повестьлар

Канга буялган алтыннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Каргыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Алло, хәлләр ничек? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

Литературно-художественное издание

Радиф Сагди

(Сагдиев Радиф Назипович)

Роман и повести

**ОКРОВАВЛЕННОЕ ЗОЛОТО**

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *М.Ш.Хәйруллина, С.Н.Мифтахова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.09.2003. Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 10,08 + фор.0,21. Шартлы буяу-оттиск 11,34.
Нәшер-хисап табагы 11,44 + фор.0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Я-580.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

**Кадерле укучыбыз!**

Татарстан китап нәшрияты 2003 елда сезгә түбәндәге китапларны тәкъдим итә:

| | |
|---|---|
| *Мөдәррис Вәлиев* | Гамәл дәфтәре |
| *Тәлгат Галиуллин* | Шәхесне гасырлар тудыра |
| *Рөстәм Мингалим* | Дәрт чүлмәге |
| *Зиннур Мансуров* | Җәрәхәтле йөрәк җылырак |
| *Марат Әмирхан* | Тәкъдир |

Бу китапларны китап кибетләреннән һәм Татарстан китап нәшриятының реализация бүлегеннән сатып алырга мөмкин.

Белешмәләр өчен телефоннар:

92-37-05
92-38-46
92-27-62